Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 22 (1387) 10 июнь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

12

Актаныш төбәгендә әдәбиятка һәм сәнгатькә игътибар киметмәүнең куанычлы нәтиҗәләре бик тиз күзгә ташлана.



14

Композитор Ренат Еникиевкә халыкчанлык, миллилек, шул ук вакытта җитди темаларга омтылыш һәм новаторлык та хас иде.

16

Гаяз Исхакыйның Зәки Вәлиди хакында мәкаләсе бу каршылыклы шәхеснең тормышы һәм карашлары турында бай мәгълүмат бирә.

Идел-йортыбызны, кошлар кебек, Бер күзәтик әле күктән дә!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Әлмәт театрының «Җил артыннан» спектакле «Кече шәһәр театрлары» фестивалендә «Иң яхшы спектакль» номинациясендә җиңеп чыкты.

● Башкортстан Корылтае Россия Дәүләт Думасына мәгариф турындагы законга туган телләрдә урта белем алу мөмкинлеген күздә тоткан үзгәрешләр кертү тәкъдиме белән чыкты.

● Казанда композитор Салих Сәйдәшев истәлегенә багышланган «Халык мәхәббәте лауреаты» музыкаль сәнгать фестивале узды.

● Республика балалар клиник хастаханәсенең Онкология, гематология һәм хирургия үзәгендә намаз уку бүлмәсе ачылды.

● Киров өлкәсенең Малмыж районында урнашкан Яңа Йөрек татар авылында Рязаньда яшәүче эшмәкәр Рамил Хәлиуллин акчасына клуб һәм китапханә ачыла.

● Казан мэриясе тарафыннан ачылган «Апуш» балалар татар театр студиясе «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә беренче спектаклен күрсәтте.

● Республика балалар китапханәсенә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин исеме бирелә.

● Башкортстанның Нефтекама шәһәрендәге «Мирас» картиналар галереясында Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы фондларыннан «Ике канат» күргәзмәсе ачылды.

● Мамадыш районының Кече Кирмән авылында шагыйрь һәм прозаик Рафаил Газизовка 75 яшь тулу уңаеннан әдәби бәйрәм оештырылды.

● Татарстан китап нәшриятының өч китабы Мәскәүдә «2021 елның иң яхшы китаплары» рәтенә керде.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Фәрит МӨХӘММӘТШИН, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе:

«45 яшемә кадәр (татарча) «исәнмесез, сау булыгыз», дигәнне генә белә идем. Фәүзия Бәйрәмова берсендә утырышны ике дәүләт телендә алып бару турында тәкъдимне тавышка куюны сорады. Хәзер тавыш бирсәләр, сәяси бәхәскә, сөйләшүгә кереп китәсе булса, ничек сөйләшермен, сүз запасы юк бит, дип борчылдым. Шунда үземә әти-әнием туган телен өйрәнергә сүз бирдем».

СЫНАМЫШЛАР

10 июньдә тыныч һәм җилсез булса, игеннәр уңа ● Шөпшәләр күп очса, көн аяза ● 11 июньдә карабодай чәчәләр ● 14 июньдә болытлы йә яңгырлы булса, киндер һәм җитен уңа ● 16 июньдә җил көньяктан иссә, сабан ашлыклары уңа, төньяк-көнбатыштан иссә, җәй яңгырлы була ● Яңгырдан соң салават күпере чыкса, көн аяза.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **2 сәгать 59 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 26 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 27 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **7 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **17 июньдә 17 сәгать 34 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

10 июнь – мәгърифәтче, педагог, Казанда Шәрык клубын оештыручы һәм беренче рәисе Ибраһим Вәлиулла улы Терегуловның тууына 170 ел (1852-1921).

13 июнь – композитор, Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Ренат Әхмәтгәрәй улы Еникиевнең тууына 85 ел (1937–2020).

15 июнь – шагыйрь Шамун Фидаинең (Касыйм Хәсән улы Шакирҗанов) тууына 120 ел (1902–1920);

– режиссер, Үзбәкстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Гомәр Гыймран улы Исмәгыйлевнең тууына 115 ел (1907–1983).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июньнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(7-14 июнь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 майдан 27 июльгә кадәр** йөрәк һәм нечкә эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген зөлкагдә аеның 11 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ

Нишләп саныбыз кими?

Табибләр исәпләвенчә, Татарстанда онкологик авыруларның күбесе Азнакай районында яши – 100 мең кешегә 530 очрак туры килә. Бу хакта матбугат конференциясендә Республика клиник онкология диспансерының баш табибе хәбәр итте.

Әлеге мәгълүмат игълан ителгәннән соң байтак вакыт узды. Хәлне җайга салу өчен ниләр эшләнде соң? Уйлап карасаң, район белән озак еллар буе әлеге өлкәдә уңышка ирешүне тәэмин итәрлек мөмкинлекләргә ия булган кешеләр җитәкчелек итә: район башлыгы М.З.Шәйдуллин – белеме буенча ветеринария табибе, райбашкарма комитеты җитәкчесе А.Х.Шәмсетдинов – район үзәк хастаханәсенең элеккеге баш табибе.

Нефть чыга торган район өчен аеруча борчу тудыра торган, беренче чиратта хәл ителергә тиешле көнүзәк мәсьәләләрнең иң әүвәлгесе шундый: бораулау эшләре барышында барлыкка килә торган калдык шлакларны нишләтергә? Бу хакта белгеч фикерен беләсем килеп, «Көнбатыш Себердә җир асты байлыкларын үзләштерүгә һәм нефть-газ комплексын үстерүгә керткән өлеше өчен» медале белән бүләкләнгән геолог Р.Ф. Лотфуллинга мөрәҗәгать иттем. Аның җавабы бик төгәл һәм ачык булды:

– Шундый технология бар: бораулау эшләре барышында барлыкка килә торган калдык шлакларны бик югары температура тәэсирендә тулысынча яндыралар. Нәтиҗәдә көл шикелләрәк бер продукт килеп чыга. Бу эшләр вакытында бүленеп чыга торган газларның санэпидемстанция тарафыннан рөхсәт ителгән микъдарын, дәүләт тарафыннан расланган нормаларны саклый алырлык көчле фильтрлар куелган булу шарт. Ә яндырыласы җитештерү калдыклары исә аерым технологияләр буенча төзелгән махсус амбарларда җыеп саклanырга тиеш. Ул корылмаларны салу өчен рөхсәт, амбар төзеләсе мәйданда җитди тикшерү эшләре башкарылганнан соң гына, Экология министрлыгы тарафыннан бирелә. Бораулау эшләре барышында барлыкка килә торган калдыкларны саклау чорында, алардан табигатькә дә, кешегә дә зыян килмәслек дәрәҗәдә итеп, куркынычсызлыкны тәэмин итә алырлык амбар-корылманың проекты эшләнә. Әлеге корылма үзе чокыр рәвешендә була: аның киңлеге, тирәнлеге һәм озынлыгы, башкарырга планлаштырыла торган эшләрнең күләменә, җиһазларның җитештерүчәнлек дәрәҗәсенә карап, махсус исәпләнә. Андый чокыр-корылмалар кимендә икәү булып, җыела торган яңгыр-кар суларын агызу өчен алар арасында торбалар да куелган булырга тиеш.

Әлеге корылмаларны әзерләгән вакытта төзелешне алдан билгеләнгән нормативлардан тайпылмыйча алып бару таләп ителә. Мисал өчен, башта чокырга җиргә ком түшәлә һәм ул каток белән тыгызлана, аның өстенә арматура белән ныгытылган тиешле калынлыктагы изоляцияләү материалы җәелә, аннары өскә тагын ком салына һәм инде аның өстенә генә тимер-бетон плитәләр куела, ул плитәләр арасы сыеклык кына түгел, хәтта газ да чыга алмаслык итеп томалана – герметиклаштырыла. Корылмаларның икесендә дә, чокырларның бораулау калдыклары белән ни дәрәҗәдә тулганлыгын тәгаен белеп тору өчен, махсус үлчәгечләр урнаштырыла. Өстәге сыеклыкны суыртып тору өчен насослар да куела. Алга таба яндырып юк итү өчен бораулау калдыкларын аерып алуның махсус технологиясе эшләнә. Ул калдыкларны подрядчының лабораториясе тикшереп тора, ә лаборатория эшчәнлеге исә үзе даими дәүләт контролендә тотыла. Мәгълүматлар барысы да аерым журналга язып барыла. Ул журналларга тиешле тәртип саны куела, алар тегелә, барысына да мөһер сугыла, тиешенчә дәлилләнә. Калдыкларны саклау урыннарына герметик ябулы махсус машиналарда гына йөртәләр.

Бу эш-гамәлләрнең тәртибе барысы да эш башкаручы подрядчы белән дәүләт арасында төзелә торган килешүләрдә тәфсилләп языла. Мондый төр эшләрне алып бару өчен, алда әйтелгәнчә, махсус төзелгән проект булу мәҗбүри. Агулы калдыклар бары тик шулай махсус урыннарда гына саклана ала, – дип сүзен тәгәлләде нефть тармагы ветераны Р.Лотфуллин.

Ютазы тимер юл станциясе ягына илтә торган автомобиль юлы буенда, Азнакай шәһәреннән биш чакрым ераклыкта, гадәти көнкүреш калдыклары полигонына охшаш урын бар. Гадәти диюнең сәбәбе шунда – бу полигонда әңгәмәдәшем югарыда әйтеп узган таләпләр үтәлүнең бер генә билгесе дә юк. Әмма әлеге территориядә кизү торучы каравылчылар анда теләсә-нинди чүп-чарны кабул итми, ә тиешле документлары булган, ягъни радиациягә калдыклар төялгән йөк машиналарын гына уздыра. Бирегә куркыныч йөк төялгән транспорт чаралары Самара өлкәсеннән, кайчакта исә Алабугадан – үзебезнең Татарстаннан да килә!

Бу шомлы ситуациягә битараф булмаган затлар белән без радиация калдыклары саклана торган әлеге урынның капкасы янында берничә фотосурәт тә төшереп алдык. Койма белән уратып алынган территория эчендә бораулау эшләре барышында барлыкка килә торган зарарлы калдыкларны саклау өчен зур гына амбар бар. Ул тиешле таләпләрне бозып төзелгән, җитмәсә, өскә чаклы тулып та өлгергән. Көнкүреш дозиметры радиация фонының сәгатенә 0,16 мкЗв тәшкил итүен күрсәтте. Бу, әлбәттә, рөхсәт ителә торганнан күпкә артык доза! Ә бит кешегә тәэсир иткән төрле чыганаклардан җыела торган еллык радиация дозасының рөхсәт ителә торган күрсәткечен исәпләгәндә, техноген радиация йогынтыларының барлык эпизодлары да исәпкә алынырга тиеш. Монда хәтта барлык төр медицина тикшерүләре (флюорография һ.б.лар), төрле дәвалау процедуралары вакытында алына торган нурланыш микъдары да керә.

Халык арасында актив тормыш позицияле кешеләр хәзер бик аз. Азнакай кебек кечкенә шәһәрләрдә – бигрәк тә. Шундый санаулы гына булган актив затларыбызның берсе – нефть-химия сәнәгате инженер-технологы, хезмәт ветераны Расих Шакиров районда экологик хәлнең бик тә хәвефле булуы турында җирле түрәләрнең барысына да диярлек сөйләп чыкты. Алар арасында Татарстан Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Ык буе территориаль идарәсе җитәкчесе, атказанган эколог Хәлил Мөстәкыймов, «Роспотребнадзор» территориаль идарәсе җитәкчесенең Азнакай районы буенча урынбасары Илдар Дружков һ.б. бар. Тик 80 яшьлек пенсионерга алар һәммәсе дә беравыздан төксе генә җавап кайтара: имеш, радиация белән бәйле эшләргә тыкшынырга берсенең дә вәкаләте юк. Чиновник статусына ия булгач, әлеге нурланыш аларның үзләрен урап узачак диярсең! Алар фикеренчә, әлеге сораулар «югары инстанцияләрдә генә карала» икән. Ә кешеләр онкология авыруларыннан кырыла! Бу зәхмәт аркасында пенсионерлар гына түгел, җир җимертеп эшләр яшьтәге кешеләр дә еш китә арабыздан. Әле апрель аенда гына шәһәр Советы депутаты Элеонора Алчина вафат булды. Аңа нибары 58 яшь иде! Халык саны бер Азнакай шәһәрендә генә дә соңгы 20 елда 4 меңнән артыкка кимеде.

Куркыныч калдыклар «чүплекләре» проблемасы белән ныклап торып шөгыльләнергә вакыт җитте түгелме соң инде?! Афәт каршыбызга килеп терәлде ләбаса. Тик менә ваемсыз түрәләр генә моңа бармак аша каравын дәвам итә. Болар хакында «Советская Россия» газетасында мәкалә дә чыгардым (21.05.2022). Шуннан соң Дәүләт Думасы депутаты А.Прокофьев Саратов шәһәрендә узган семинар-киңәшмәдә Азнакайдагы хәлне үз контроленә алуы турында белдерде. Хәлләр үзгәрерме? Көтеп карыйк.

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

КЫТАЙ ГЕГЕМОНЛЫГЫ

Күпләр кешелек дөньясының киләчәген Кытай гегемонлыгы, бу илнең алдагы чорда демография, икътисад һәм социаль яшәештә генә түгел, югары технологияләр, глобаль сәүдә, геосәясәт һәм заманча хәрби куәт өлкәсендә дә өстенлеккә ирешәчәге белән бәйләп карый. Мәгълүм булганча, ул дөньяда иң борынгы цивилизацияләрнең берсе санала һәм аның тарихы дәүләт буларак та бик тирәнгә китә. Ә ул тарихта төрле чорлар булган. XIII гасырда Кытай хәтта Бөек Татария (Great Tartaria, соңгы сүзенең язылышы: рус. Татария, лат. Tartaria, фр. Tartarie, ингл. Tartary, алманча Tartarei) протекторатына да эләгә. Аның киң колач җәйгән һәм иң көчле вакыты XVII-XVIII гасырларга туры килә. Әмма XIX гасырда инде мәдәни вә технологик яктан артта калган Кытай Көнбатыш колонизаторлары йогынтысына эләгә, соңрак Россия һәм Япония дә аңа тыңгылык бирми. Тик, халкы бик күп һәм территориясе дә зур булу сәбәпле, бу чорда инде аны беркем дә тулысынча басып ала һәм буйсындыра алмый. Мәгълүм булганча, дөнья тотучылар да анда озак вакытлар үтеп керә алмаган. Идеологик яктан моңа кытай фәлсәфәсе (даосизм, конфуцийчылык) комачаулаcа, физик яктан инде ул Бөек кытай дивары аша да сакланган. Бары Икенче бөтендөнья һәм 1945-1949 елгы гражданнар сугышыннан соң гына анда коммунистик идеология керә. Кытай исә коммунизмны да кытайча кора. Бәгъзеләр хәзер коммунизмнан ничек арынырга белми. Ә коммунистик Кытайны Көнбатыш узган гасырның 70 нче елларында гына таныды (аңарчы ул Тайваньдагы гоминьдан хакимлеген генә таный иде).

Наполеон Бонапарт әле 1803 елда ук Кытайны «йоклый торган гигант» дип атаган һәм «әгәр ул уянса, бөтен дөньяны тетрәтәчәк» дип тә өстәгән. Күрүебезчә, аның сүзләре күрәзәчел булып чыкты: үсеш темплары буенча Кытай бүген көндәшләрен дер селкетә. Сатып алу мөмкинлеге чагыштырмасы (ППС) буенча исәпләнгән эчке тулай продукт (ВВП) күләме буенча ул бүген дөньяда ышанычлы төстә беренчелекне били. Дөрес, җан башына исәпләнгән ВВП буенча Кытай әлегә нык калыша. Әмма бу инде аның халкы күп (2019 елда 1,4 миллиард кеше иде) булуы белән аңлатыла. Хәлбуки, гегемонлык бүген илнең бөтен дөньяны җәлеп итәрлек идея тәкъдим итә алу-алмавы белән дә билгеләнә. Кытайда исә андый идеяләр җитәрлек. Әйтик, 2010 елларда тәкъдим ителгән «Ефәк юлы» дигән халыкара хезмәттәшлек оешмасы. Ул «Ефәк юлының икътисади поясы» һәм «XXI гасырның диңгез Ефәк юлы» проектларын үз эченә ала. «Бер пояс, бер юл» дигән борынгы Ефәк юлы рухын дәвам итеп һәм үстереп, бу идея төбәкләрнең икътисади чәчәк атуы, төрле цивилизацияләрнең мәдәни һ.б. өлкәләрдәге багланышларын җәйлау, шулай ук тотрыклы үсеш һәм тынычлыкны ныгытуның яңа механизмнарын булдыруны максат итә. «Бер пояс, бер юл» мегапроекты колачлаган бай ресурслы төбәкләрдә планетаның бүген 63% халкы яши, ә аның икътисади күләме якынча 21 триллион доллар тәшкил итә икән.

Искәртеп үтик, бу мегапроектның беренче форумы Пекинда 2017 елның маенда үткән иде. Анда 29 илдән дәүләт яки хөкүмәт башлыклары, шулай ук өч халыкара оешма җитәкчесе (шул исәптән БМО генераль секретаре) катнашты. Икенче форум инде Пекинда 2019 елның 25 апрелендә җыелды һәм анда дөньяның 150 иленнән вәкилләр (шул исәптән 40 дәүләт җитәкчесе) катнашты. Бу мегапроектны Кытайның дөньяда яңа икътисади вә финанс тәртибе урнаштыру юлындагы күрәшенең мөһим өлеше, дип тә карарга кирәктер. Ул шулай ук Си Цзиньпин җитәкчелеккә килгәч тә игълан иткән «Бөек кытай хыялы»н (ә ул кытай милләтен торгызуны максат итә) гамәлгә ашыру чарасы да булып тора. Монда инде Россиягә дә Кытай, ЕАЭС илләре, шулай ук Иран, Һиндстан, Пакыстан кебек илләрне дә берләштергән «Зур Евразия» партнерлыгында катнашудан башка юл калмый (В.Путин бу хакта әле 2019 елда Пекинда үткән икенче форумда ук белдергән иде).

Әмма 24 февраль вакыйгалары Россия-Кытай мөнәсәбәтләренә генә түгел, АКШ-Кытай бәйләнешләренә дә үзгәрешләр кертте. АКШ инициативасы белән, быел 18 мартта АКШ президенты Джо Байден һәм КХР рәисе Си Цзиньпин арасында видеоэлемтә режимында ике сәгатьлек мөһим сөйләшү үтте. 1972 елда Шанхай коммюникесын (Мао Цзэдун – Рейган) имзалауның 50 еллыгы уңаеннан үткәрелгән ул сөйләшү АКШ-КХР-РФ «өчлеге» мөнәсәбәтләренә багышланган иде. Байден анда АКШның әле дә Тайвань бәйсезлеген якламавы, "бер Кытай" сәясәтенә тугры калуы, Кытай белән низагка керергә теләмәве турында белдергән, АКШ һәм КХРның «өченче ил (бу очракта РФ күздә тотыла) белән башка илләргә (Украинага) каршы юнәлдерелгән килешүләргә бармаска» йөкләмә алуларын да искә төшергән. Кыскасы, Тайвань һәм Украина проблемаларын исәпкә алып, яклар уртак фикергә килгән. Байден АКШ-КХР сөйләшүләрендә ачыклык артуын кулай бәяләгән, бу мөнәсәбәтләрнең ныгуы XXI гасырда дөнья төзелешен билгеләячәге турында да белдергән. Эшләр шулай дәвам итсә, ККПның быел ноябрьдә узачак XX съездына Тайвань инде, «бер ил – ике система» дигән тезисны танып, бүләк тә әзерләргә мөмкин.

Фоат УРАЗАЙ.

Без – бер агач тармаклары

Татарлар һәм чуашлар гомер-бакый ут күршеләр генә түгел, хәтта тугандаш халык булып, бер-берсенең телләрендә сөйләшеп гомер иткән, нәсел бәйләнешләре дә булган. Ике халыкның тарихларын барлау Урта Идел буе халыклары үткәннәрен ачыклауда аеруча әһәмиятле. Моны татар һәм чуаш милләтләренең галимнәре дә яхшы аңлый. Шушы көннәрдә Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында татар һәм чуаш халыкларының тарихына багышланган яңа китап тәкъдим ителү моның ачык дәлиле булды. «Татары и чуваши – ветви одного древа» («Татарлар һәм чуашлар – бер агачның тармаклары») дип аталган яңа басма ике республика галимнәре белән берлектә әзерләнгән. Узган елның 7-8 октябрендә Чабаксарда һәм Казанда уздырылган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциянең материаллары туплап бирелгән басма белән танышканда да, аны тәкъдим итү тантанасында да татар һәм чуаш галимнәренең күп кенә мәсьәләләрдә уртак фикергә килүен күрергә мөмкин иде. Тарих институты директоры Радик Салихов залдагыларның игътибарын китапта ике халыкның да мөнәсәбәтләре төрле яклап каралуына, басмага филолог, тарихчы, археолог кебек галимнәрнең мәкаләләре кертелүенә юнәлтте. «Хәзер тарихның яңа этабы бара, үткәннәрдә калган катламнарны ике халыкның да тарихчылары гына түгел, антропологлар, лингвистлар, социологлар белән берлектә фәнни яктан комплекслы өйрәнүләре дәвам итәргә тиеш», – диде ул. Әлбәттә, бу ике халык галимнәре арасында килеп туган бәхәсле мәсьәләләрдә дә бер фикергә килергә булышачак.

Чуашиянең гуманитар фәннәр институтының фәннәр буенча директор урынбасары Геннадий Николаев хезмәттәшенең фикерләрен хуплап, соңгы вакытта татар һәм чуаш галимнәренең тарихыбызны өйрәнүдә бергәләп башкарган хезмәтләрнең милләтара мөнәсәбәтләрне ныгытуда да ярдәм итәчәген искәртте. Ике республикада археологик тикшеренүләр үткәрелүе дә моның ачык мисалы. Хәзер галимнәр урта гасырлар чорын бергәләп өйрәнүгә дә игътибарны көчәйткән.

Тарих институты хезмәткәре Айдар Ногманов Чуашия дәүләт гуманитар фәннәр институты галимнәренең зур булмаган коллектив белән дүрт томлык чуаш энциклопедиясен шактый сыйфатлы, саллы һәм тулы итеп нәшер итүен мактап телгә алды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

1 нче биттә – Казанда узган халыкара җылылык аэростатлары (һава шарлары) фиестасыннан бер күренеш. **Владимир ВАСИЛЬЕВ** фотосы. «Татар-информ».

Туган ягында истәлек

Азнакай районының Үчәлле авылында шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Рөстәм Зәкуановка мемориаль стела ачу тантанасы булды. Татарстанның өченче чакырылыш Дәүләт Советы депутаты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатының тууына 65 ел тулуга багышланган чарада чыгыш ясаганда, Азнакай районы башлыгы Марсель Шәйдуллин Рөстәм Зәкуановның район тарихында якты эз калдыруын билгеләп үтте. «Янтарь» совхозы директоры, район башлыгы урынбасары, ТР Дәүләт Советының Икътисад һәм эшмәкәрлек үсеше комитеты рәисе урынбасары, Таттелеком компаниясенең матбугат хезмәте җитәкчесе булып эшләгәндә, ул район һәм туган республикабыз өчен күп игелек кылды, – диде ул. – Азнакай халкы күренекле якташларыбызны хәтерли һәм хөрмәт итә. Рөстәм Зәкуановның истәлек тактасын урнаштыру инициативасы Дәүләт Советы депутаты Лотфулла Шәфигуллинныкы, ул проектны гамәлгә ашыруда да һәрьяклап ярдәм итте».

«Рөстәм Зәкуанов үз авылы, районы, халкының лаеклы улы иде, – диде Дәүләт Советы депутаты Таһир Һадиев. – Республика парламенты депутаты сыйфатында гади кешеләр мәнфәгатьләрен яклады. Һәрвакыт актив, эшлекле булды һәм һәрвакыт тагын да күбрәк эшләргә ашыкты».

Тантанада Татарстан Язучылар берлеге һәм Азнакай районы мөхтәсибәте вәкилләре, Рөстәм Зәкуановның туганнары һәм якыннары чыгыш ясады.

Фото: aznakaevo-rt.ru

Гариф аганы искә алу

Июнь аеның чәчәкле, матур көне Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновны арабыздан алып китте. Әдипнең кызы, шагыйрә Наилә Ахунова бу көнне ел саен әтисен, аның туган ягы – Арча төбәгендә искә алуны матур бер гадәт итте. Ул әдипнең балачагы узган Кече Өчиле авылы урынына кайтып, әтисе суын эчеп үскән «Ахун чишмәсе» янына һәм әдипкә бәйле башка урыннарга истәлекле әдәби сәяхәтнамә кыла.

Наилә ханым хәбәр иткәнчә, быел Гариф Ахуновның вафат булган көне аның исемендәге әдәби бүләкнең 25 еллыгы белән туры килгән. Гариф аганы искә алу һәм бүләкнең юбилеена багышланган чара уңаеннан мәртәбәле Казан кунаклар катнашында Арча балалар сәнгать мәктәбендә «Хәзинәле гомер» дип исемләнгән бик җылы әдәби-музыкаль кичә уздырылды.

Аны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Ренат Гатиятов ачып җибәрде, олуг язучыбызның иҗатын югары бәяләп, әдипнең үз әсәрләре, эшчәнлеге белән татар әдәбияты, район үсешенә саллы өлеш кертүен билгеләп узды.

Казан кунаклары – Екатерина һәм Василий Евдокимовлар, Камилла Латыйпова, Анжелика Благова һәм Ютазы районыннан килгән Ильмира Гобәйдуллина, «4 сезона» рок-группасы чыгышлары кичәнең матур бизәге булды.

Әдәби-музыкаль кичәдән соң кунаклар Арча шәһәре буенча экскурсиядә булып, язучылар аллеясына чәчәкләр салды. Наилә ханымны һәм кунакларны Арчаның әдәбият һәм сәнгать музеенда да зурлап каршы алдылар, биредә алар игътибарына Арча районында туып-үскән әдәбият-сәнгать әһелләренең һәм Гариф аганың, аның җәмәгате язучы Шаһидә Максудованың, уллары, язучы, тәрҗемәче Рәшит Ахуновның мемориаль ядкәрләре тәкъдим ителде.

Аңлашыла ки, кунаклар Арчаның татар зиратында да булды һәм каберләргә чәчәкләр утыртты. Биредә әти-әнисеннән, якыннарыннан кала, Наилә ханымның Бибинур һәм Йөзлекәй әбиләре, әтисенең бертуганы Сәҗидә апа да җирләнгән.

С. КЫЯМОВА.

Кремль йолдызы яңартыла

Казан Кремленең Спас манарасын торгызу эше 2022 елның февралендә башланды. Моңа кадәр биредә реконструкция эшләре 40 ел элек – 1983 елда үткәрелгән. Кремль диварлары һәм нигезе калкулык астындагы грунт һәм җир асты сулары хәрәкәтеннән ярылган. Шуңа күрә хәзерге вакытта беренче эш итеп архитектура корылмасының төп элементларын ныгыту буенча эшләр алып барыла.

«Казан Кремленең Спас манарасына аерым игътибар бирелә. Әлегә без реставрацияләүнең беренче һәм иң катлаулы этабында торабыз, ул авариягә каршы эшләрне, фундаментны, диварларны ныгыту, гидроизоляцияне төзекләндерү эшләрен үз эченә ала. Без иҗтимагый резонанс булачагын аңлыйбыз, шуңа да карамастан, аның авария хәлендәге торышы аркасында, Спас манарасындагы йолдызны реставрацияләү мәсьәләсен дә читләтеп уза алмыйбыз.

Без аны төшерергә, реставраторларга бирергә җыенабыз. Йолдыз һәм ныгытмалар шактый тузган хәлдә. Шуңа күрә аны сүтәргә мәҗбүрбез. Бу вакытлыча. Аны аска төшерергә, беренчел кыяфәтен кире кайтарырга һәм махсус саклагыч состав белән буярга кирәк. Реставрациядән соң Спас манарасы йолдызы үз урынына кайтарылачак», – дип сөйләде мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан комитеты җитәкчесе Иван Гущин.

Казан Кремленең төп символларының берсен торгызу күпме дәвам итәчәге әлегә билгеле түгел. И. Гущин сүзләренчә, мәдәни мирас объектларын реставрацияләү мәсьәләсендә иң мөһиме – вакыт түгел, ә эшнең сыйфаты.

«Биш кырлы йолдыз 1963 елда куелган. Йолдызның бер нурыннан икенчесенә кадәр озынлыгы – 2,7 метр. Манара конструкциясенең гомуми биеклеге – 2,9 метр. Манара очы эретеп ябыштырылган һәм ике өлештә чүкеп беркетелгән. Җилдән әлеге урынга зыян килгән», – дип сөйләде И.Гущин.

Кабан буенда – «Ярмәк вагы»

Кабан күле яр буенда «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты кысаларында «Ярмәк вагы» татар халык биюен өйрәтү остаханәсе узды. Бушлай осталык дәресендә теләгән һәркем катнашты.

«Бу бик борынгы бию. Безнең ансамбльгә Самара якларыннан Наил абый дигән биюче килеп, биюне өйрәтеп киткән иде. Без һәр хәрәкәтен отып калдык, үзгәрешсез биибез. «Ярмәк вагы»н биергә авыр, ул күп физик көч таләп итә. Өч минут кына биесәк тә, аяклар тала. Гел тыпырдап торабыз. Бу биюне концертларда да куябыз, ансамблебезнең «визит карточкасы» ул», – диде Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле артисты Владислав Уткин.

Аның әйтүенчә, «Ярмәк вагы» биюенә тальян гармун яңгырашы кулай: «Үзенең ритмнары бар, дәртләндереп җибәрә, йөрәк тибеше ешая». «Казан» бию ансамбленең әйдәп баручы солисты Рамазан Җамалетдинов биюнең гади халык арасында таралган төре һәм сәхнә өчен эшкәртелгән төре барлыгын аңлатты: «Сәхнә төрендәге биюдә билгеле бер техник алымнар бар, ул кысаларга кертелгән».

Хореографлар Самара татарларының бүгенге көндә дә «Ярмәк вагы» биюен онытмавын әйтте. «Ул якларга барсагыз, бию традициягә сакланган. Элек-электән рекрутларны армиягә чакырганда шул биюне биегәннәр. Тарихы шундый: егетләрнең аякларына чыбыркы белән сукканнар, алар чыбыркыны таптап, аяклары белән тотып калырга тиеш булган. Шуннан, тыпырдау хәрәкәте килеп чыккан», – диде ул.

«Хәрәкәттә – бәрәкәт» проектына Казан мэриясе нигез салды. Каланың Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова үз чыгышында: «Былтыр башланган матур эш дәвам итә. Бу проект бик популярлашты. Әүвәл ул проектны Казан мәктәпләренә керткән идек. Ай саен татар биюләренә генә багышланган җыеннар үткәрү дә файдалы булыр», – диде. Аның фикеренчә, башкала халкы мондый проектларга «сусаган». «Күзәтүчеләр дә, биючеләр дә күп. Без шушы хәрәкәтләрне өйрәткәндә халык татар теле буенча сүзлек запасын да баетыр дигән ышанычта. Бер ноктага җыелып, татар биюен, татар телен тантана итү безнең кечкенә генә булса да бер җиңүебез», – диде Гүзәл Сәгыйтова.

Фламенко бию остасы, хореограф Гөлсинә Галимуллина «Ярмәк вагы» биюе Татарстан халкы өчен гадәти булмаган дәртле бию дип саный. «Без халыкны татар биюенең төрле төрләре белән таныштырасыбыз килә. Татар биюен бер урында тыпырдау дип кенә уйламасыннар иде. Шушы чара белән кешеләрне татар теле, татар мәдәниятенең төрле булуына инандырырга, кызыксыну уятырга телибез», – диде ул.

Шәһәр халкы өчен дәресне халыкара конкурслар һәм фестивальләр лауреаты, халык биюенең педагог-хореографы Сәидә Миңнебаева, фламенко бию остасы, хореограф Гөлсинә Галимуллина, Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең балет артисты Владислав Уткин, «Казан» бию ансамбленең әйдәп баручы солисты Рамазан Җамалетдинов үткәрде.

Зилә **МӨБӘРӘКШИНА.**
Салават **КАМАЛЕТДИНОВ**
фотосы.

● Филиппиндагы Минданао утравында яшәүче 29 яшьлек Джунри Балуинг планетада иң тәбәнәк буйлы кеше буларак Гиннесс китабына кертелгән. Аның буе нибары 60 сантиметр тәшкил итә. Күп балалы гаиләдә туган малайга бер яшьлек чагында витаминнар кирәк була, әмма гади крестьян әти-әнисенең кыйбатлы дарулар алырга акчасы җитми. Шунлыктан Джунриның буе бер яшьлек чагындагы кебек кала. Бәләкәй булуына карамастан, егет файда китерергә тырыша: ул укый-яза белә, өй җыештыра, рәсем ясый. Гашыйк булып, өйләнү турында да хыяллана.

● Австриядән каскадер Джозеф Тодтлинг Гиннессның рекордлар китабына кертелгән: утка чыдам киемне бернича кат киеп, ул үзенә ут төрткән һәм 6 минут буе дөрләп янган, бер җиренә дә зыян килмәгән.

Татарстан Фәннәр академиясендә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Идел Болгарстанында рәсми рәвештә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган бәйрәм кысаларында әзерләгән яңа китаплар тәкъдим ителде. Алар – «Татар эпиграфик традициясе» сериясендә ике китаптан торган «Булгарские эпиграфические памятники XIII-XIV вв.» («Болгар эпиграфик ядкәрләре XIII-XIV йөз») һәм «Рухи мирас: эзләнүләр һәм ачышлар» сериясен дәвам иткән «Письменные памятники Волжской Булгарии» («Идел буе Болгар дәүләте язма истәлекләре») дигән басмалар.

КИТАПЛАРДА – Болгар язма ядкәрләре

Китапларда тарихыбызга бәйле мәгълүматлар тупланган. «Болгар эпиграфик ядкәрләре XIII-XIV йөз» хезмәтләрендә Алтын Урда дәүләтенең Болгар олысыннан сакланган ташъязма истәлекләр, кабер ташларының фотосурәтләре, алардагы язуларның текстологик укылышлары, бүгенге саклануыш халәтләре турында мәгълүматлар тупланган. Гомумән ике китапта 150 гә якын эпиграфик истәлек белән танышырга мөмкин. Беренче китапка борынгы Болгар шәһәре җирлегендә сакланган кабер ташлары турында мәгълүмат бирелгән. Аларның иң борынгысы 1282 елга карый. Икенче китапта элек Болгар дәүләте биләмәсенә кергән дип исәпләнгән өлкәләрдә сакланып калган ташларның аеруча кыйммәткә ия булганнары турында бәян ителгән. «Бу язма истәлекләр Болгар чорларыннан безнең көннәргә исән-имин килеп җиткән ядкәрләр. Алар - безнең үткәнебез, бүгенгебез һәм киләчәгебез. Язма истәлекләрне тиешле дәрәҗәдә өйрәнеп, аларны фәнни әйләнешкә тәкъдим итү – галимнәрнең бурычы», – дип ачыклап үтте Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирас үзәге җитәкчесе Илһам Гомәров.

Ул шулай ук китапларга әлегә кадәр галимнәргә мәгълүм булмаган ядкәрләр өстәлүе турында да әйтте. Хәзерге технологияләр теге яки бу эпиграфик язмаларны яхшырак аңларга ярдәм итә. Шуңа бәйле рәвештә китапларда кайбер истәлекләрнең яңача укылышы белән дә танышырга мөмкин. Әйтик, элекке елларда бер таш иясенең исеме «Әфриканҗи» дип шәрехләнгән булган. Соңрак бу сүзне «Үргәнчи» дип укырга кирәклеге ачыкланган. Ташлар шулай ук ул заманнардагы дәүләтләр арасындагы бәйләнешләр хакында да сөйли. Моннан тыш элекке елларда фрагментар рәвештәге ташлар исәпкә алынмаган булса, галимнәр яңа басмаларга аларның кайберләрен керткән.

Тарихчы галим, Болгар музей-тыюлыгының фәнни хезмәткәре Җәмил Мөхәммәтшин хәзерге вакытта 400гә якын кабер ташы ачыклануын искәртә. Аларның 200 е – Болгарда, калганнары төрле районнарда һәм Россия төбәкләрендә таралган. Ташларның саны арта бара. Моңарчы исәпкә алынмаган ташлар әле дә табылып тора икән. Әйтик, 2016-2018, 2021 елда Әлки, Аксубай, Спас районнарында Болгар чорына караган дистәләгән ташларга юлыкканнар, Чистай зиратында гына да 12 таш ачыкланган.

Җәмил Мөхәммәтшин бериш кабер ташларының Петр беренче тарафыннан 1722 елда исәпкә алынуын да әйтте. Төркият галиме Илья Березинның хезмәтләрендә исәпкә алынган ташлар инде сакланып калмаган. Ул заманда 1242 елга караган иң борынгы таш турында мәгълүмат та кәгазьдә генә. Ташларга татар телендә язылган булган. Галим искәрткәнчә, Болгар чорына караган ташларда бер үк сүзнең берничә төрле язылуы һәм укылуы үзенчәлекле. Әлки һәм Чистай районындагы ташларда «җиде» сүзенең «җати», «җияти», «җияҗ» кебек формаларда бирелгән. Җ.Мөхәммәтшин Иске Салман авылында табылган бер кабер ташында «сабантуй», икенчесендә «җыен» дигән сүзләр очравын да ачыклап үтте. Институтның әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Азат Ахунов XIII – XIV йөз Болгар чоры ядкәрләренең бер өлеше хәзерге татар әдәби телендә язылуын билгеләп үтте... дерде. «Таш язмаларда язылган исемнәрдә «татар» дигән сүз дә бар. Ул кешенең йә атамасы шулай булгандыр, яисә исеменең бер өлеше шулай йөртелгәндер дип уйларга җирлек бирә», – диде ул. Галим шулай ук «Татар эпиграфик традициясе» сериясен башлап җибәрүләрен әйтте. Галимнәр алга таба Казан ханлыгы чорындагы ядкәрләрне туплап, китап чыгарырга уйлый.

Шунысы да әһәмиятле: Болгар чорындагы ташлар нык булуы белән аерылып тора. «Алар, нигездә, известьташтан ясалган. Ә Казан ханлыгы чорына караган ядкәрләр – йомшак материалдан, акбур таштан. Алар җимерелеп бара», – диде Җ.Мөхәммәтшин.

Без, журналистлар, Болгар саклаулыгындагы чиркәү нигезенә куелган кабер ташларының язмышы турында да кызыксындык. Җәмил Мөхәммәтшин, аларның күбесенең нигездән алынуын, «Кара пулат» эченә куелуын, башка җирдә сакланганнары да булуын әйтте. Тарихчы галим кайбер кешеләр күзлегеннән карaганда, мондый хәл – вәхшилек булса, икенче яктан, кабер ташларының җир астындагы өлеше яхшырак та сакланган әле, дип җавап бирде.

Институт директоры Ким Миңнуллин эпиграфик ядкәрләрне өйрәнүдә көч куйган галимнәрне атады. Татар халкында кабер ташларын өйрәнеп, татар халкының үткәннәрдә калган сәхифәләрен барлаучылар күп түгел. Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин, Н.Калинин, Һ.Йосыпов, Р.Мәрданов, Г.Рәхим, Ф.Хәкимҗанов, А.Халиков, Җ.Мөхәммәтшин, И.Һадиев һ.б. фикерләренә таянып, моңа кадәр басылып чыкмаган яңа истәлекләр дә кертелгән.

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Идел буе Болгар дәүләте язма истәлекләре» китабы – Идел буе Болгар тарихының биш әдәби ядкәре кергән җыентык. Алар – Болгар чорларында кәгазьгә төшеп калган язма истәлекләр. Китап Әхмәд ибн Фадлан «Рисәлә»се белән ачыла. Ул 922 елда Болгарга килеп, илнең яшәешен, дәүләтне үз күзләре белән күреп киткән автор тарафыннан язылуы белән әһәмиятле. Бу язмаларда Болгар чоры, аның тирәсендә яшәгән башка халыкларның тормышлары ачык чагылыш таба. XII йөзнең беренче яртысында яшәп иҗат иткән әдип Сөләйман бине Дауд Саксини Болгарда Әбел-Галә Хәмид бине Идрис әл-Болгаридан дәрес алган. «Әдип фарсы телендә «Бәһҗәтел-әнвәр мин хәкыйкател-әсрар» («Нурларның яктылыгы – серләрнең хаклыгы») дигән китап язган, аннары аны гарәпчәгә тәрҗемә итеп, «Нөзһәтел-колүбел-мәраз» («Авыру күңелләрне сөендерүче») дип исемләгән һәм, автор әсәрен алга таба Коръәннән аятьләр китерү, хәдисләр һәм риваятьләр өстәү юлы белән тагын да камилләштерә, аны алтмыш алты мәҗлескә бүлә һәм аңа «Зөһрәт әр-рийаз вә нөзһәт әл-колүб әл-мирадз» (Бакчаларның матурлыгы һәм сырхау йөрәкләрнең юанычы) дип атый», – диде Илһам Гомәров. «Идел буе Болгар дәүләте язма истәлекләре» китабында әсәрнең русча вариантындагы берничә бүлеге тәкъдим ителә. Мондый әсәрнең булуы турында Мәрҗани дә язып калдырган. Морад Рәмзи Мәккәдә яшәгән вакытларында «Зөһрәт әр-рийаз»ның таркау бер кульязмасын күрүе турында язып калдыра.

Моннан тыш китапка беренче тапкыр бер чыганакта да телгә алынмаган, XII гасырда иҗат иткән Әбү Гали Мөхәммәд ибн Габдулла әс-Саксини дигән шәхеснең рамазан аен сәламләү, рамазан аеның шәрифәтләре турында язылган кечкенә генә бер әсәре дә кертелгән. Галимнәр «әс-Саксини» сүзе авторның Болгар дәүләтендәге Саксин шәһәрендә тууы яки аның анда иҗат итүе турында сөйләвен ачыклап үтте. Китапка шулай ук Таҗетдин әл-Болгариның фармакология турында «Ат-Тирһак әл-кабир» дигән хезмәт тә кертелгән. Бу уңайдан тарих фәннәре докторы, профессор Гамирҗан Дәүләтшин Идел буе Болгар дәүләтендә медицинаның, аерым алганда, фармакология фәненең нык алга киткән булуы турында сөйләде. «Болгар чорында иҗат иткән Таҗетдин Болгариның медицина трактаты булуы билгеле. Аны бер җыентыкта табалар. Анда бик күп рецептлар һәм аның медицина тарихы буенча ике әсәре бар. Беренчесендә ул вакытта күренекле табибләрдән саналган Әбу Гали ибн Сина, Зәкәрияләрнең хезмәтләре урын алган», – диде Г.Дәүләтшин.

«Идел буе Болгар дәүләте язма истәлекләре» китабы Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре белән тәмамлана. Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты, филология фәннәре докторы Дания Заһидуллина галимнәр тарафыннан бу юнәлештә алып барылган эшнең мөһимлеген һәм алда да дәвам итү кирәклеген ассызыклады.

Китаплар рус телендә нәшер ителгән. Институт җитәкчеләре аларның якын киләчәктә татарча да нәшер ителәчәгенә ышандыра. Китапларның электрон форматы белән һәркем өчен укып таныша алу мөмкинлеге дә тудырыла. Алар институт сайтына урнаштырылачак.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Атнаның сәяси мизгелләре

ФАКТЛАР ТЕЛЕ НИ СӨЙЛИ?

РФ Дәүләт Думасы рәисе В.Володин бу атнада парламентта Кеше хокуклары буенча Европа суды (ЕСПЧ) карарларын үтәмәү турында федераль законнар кабул ителәчәге турында белдерде. Депутатлар икенче укылышка тәкъдим иткән төзәтмәләр буенча, быел 15 марттан (Европа Шурасыннан чыгу турында Россия гариза биргән көн) соң ЕСПЧ чыгарган карарларны Россия үтәмәячәк. Моннан тыш, акчалата компенсация түләү турында 15 мартка кадәр кабул ителгән карарлар буенча түләүләр дә сумнарда гына һәм Россия банкларындагы счётларда башкарылачак. Төзәтмәләрнең исә РФ судлары карарын ЕСПЧ карарларыннан өстен куя торганнары да бар икән. Володин фикеренчә, ЕСПЧ бүген Көнбатыш сәясәтчеләре кулында Россиягә каршы сәяси көрәш коралына әйләнгән. Аның кайбер карарлары РФ Конституциясенә генә түгел, илдәге традиция вә милли кыйммәтләргә дә каршы килә икән.

Россия президенты В.Путин исә Петербург халыкара икътисад форумына юллаган телеграммасында анда катнашучыларны ПМЭФның 25 еллыгы белән котлаган. Ул анда шулай ук 2020 еллар Россия өчен икътисади суверенитетны ныгыту еллары да булачагы турында белдергән. Узган атнада В.Путин АКШның Украинага заманча сугыш кораллары куюы җәһәтеннән дә үз фикерен әйтте. Аныңча, АКШның залп белән ут ачу ракеталарын Россия хәрбиләре «чиклəвек яргaн кебек кенә вата». Шуның белән бергә ул, Киевкә ракеталар биреп әвәрә килүнең асылында үзгәреш күрмәве турында да искәртә. Моны ул андый совет коралының Украина арсеналында моңарчы да булуы белән аңлатты. Ә Украинага яңа сугыш кораллары куелу дәвам итә. Бөекбритания аңа М270 индекслы залп белән ут ачу корылмалары җибәрергә җыенса, Испания инде Алманиядә эшләнгән «Леопард» танклары белән дә ярдәм кулы сузмакчы. ЕС та ярдәмне өзми. Украинадан экспортка чыгарыла торган тауарларга пошлинаны 4 июньнән ул бер елга туктатты.

Узган атнада Россия тышкы эшләр министры С.Лавровның эш сәфәре буенча Сербиягә барырга дип һавага күтәрелгән очкычы белән дә гауга килеп чыкты. Чөнки Болгария, Черногория һәм Төньяк Македония җитәкчеләре Россия очкычын үз һава киңлекләре аша үткәреп җибәрүдән баш тарткан. Шуңа С.Лавров Сербиягә бара алмыйча калды. Хәзер инде серб лидеры үзе Мәскәүгә килергә тиеш була. Ә Киев белән Мәскәү арасында бүген солых турында сөйләшүләр дә туктатылган. Чөнки, С.Лавров әйтүенчә, Көнбатыш Киевкә моның өчен рөхсәт бирми икән.

Фоат УРАЗАЙ.

Саха (Якутия) Республикасында Татарстан Республикасы көннәре уңаеннан Татарстан китап нәшриятында «Төрки әдәбият» сериясендә «Хәзерге якут прозасы антологиясе» басылып чыкты. Китапта егерме авторның – өлкәннәрдән алып, яшьләргә кадәр – әсәрләре урын алды. Мәңгелек туңлык хөкем сөргән ерак тарафта көн күрүче кардәш төрки халыкның ялкынлы хисләре, тирән тойгылары һәркем күңеленә хуш килер. Укучылар игътибарына Наталья ХАРЛАМПЬЕВАның якут әдәбияты, якут прозасы, антологиягә кергән әсәрләр турындагы язмасын тәкъдим итәбез.



Наталья ХАРЛАМПЬЕВА,
Саха (Якутия) Республикасының халык шагыйре,
Саха (Якутия) Язучылар берлеге рәисе

Якут рухының аһәңе

Башка төбәк, башка халыкның китап укучысына, хәтта ул тугандаш булса да, хәзерге якут хикәясен тәкъдим итү бик җиңелләрдән түгел. Эш шунда ки, якут әдәбиятының чишмә башында безнең классиклар торган һәм алар, барыннан да элек – шагыйрьләр. Борынгы төрки традицияләрдән күренгәнчә, шигъри тел төрки халыклар өчен иң үтемлесе, шуңа күрә ул классикларыбыз – якут язма әдәбиятын башлап җибәрүчеләр өчен дә өстенлек алгандыр. Якут әдәбиятында проза жанры, димәк, хикәя дә, күпмедер вакыт күләгәдә кала. Хәлбуки укучы тарафыннан һәрчак кызыксыну күзәтелсә дә.

Шул ук вакытта яшь якут язма әдәбиятында хикәя тиз арада үз урынын тапкан, бәлки, безнең олоңхога хас эпик башлангыч һәм традицион купшылык, сюжет-эчтәлегендәге кайчак ироник, күп катламлы тасвирлылык моңа сәбәпче булгандыр. Шуңа яңа буын иҗатчыларның шигърияткә караганда күбрәк прозага күчә башлавының да үз нигезе бар. Беренче якут классиклары Анемподист Софронов – Алампа, Платон Ойунский һәм Николай Неустроев хикәяләренең колачы шактый киң – алар борынгы риваятьләргә яки тарихи шәхесләрнең язмышларына нигезләнгән хикәяләрдән алып, үзләре яшәгән чорның әхлакый һәм социаль мәсьәләләрен күтәргән әсәрләргә кадәр иҗат иткән. Әлеге каләм ияләре артыннан Суорун Омоллоон, Амма Аччыгыйа, Эрилик Эристин, Кюндэ... хикәя жанрында эшләгән. Шуны да искәртеп узарга кирәк: алар чәчмә әсәрләр генә язмаганнар.

XX гасырның 60 нчы елларында якут әдәбиятында проза әйдәп барган жанрларның берсенә әверелә, һәм бу вакытка беренче романнар пәйда була. Амма Аччыгыйаның «Язгы чор» романы – зур юлның башлангыч өлеше, һәм бүгенге көндә әлеге әсәр саха халкының XX гасыр башындагы тормышы хакында энциклопедия булып санала. Амма Аччыгыйаның «Язгы чор», Николай Якутскийның «Язмыш», Иван Гоголевның «Кара торна», Болот Боотурның «Язгы кырау», Леонид Поповның «Тогой Сэлэ» романнары, тарихи темаларга багышланып, зур вакыт аралыгын колачлый. «Хрущёв җепшеклеге» чорында Софрон Даниловның авылда көн күргән зыялыларның яшәешенә багышланган, аларның киләчәккә өметләрен, көн кадагына суккан проблемаларын яктырткан «Йөрәк типкән чакта» дигән психологик романы исә аерым урын алып тора.

Һәрберсе якут укучысы өчен вакыйгага әверелгән әлеге зур әдәби әсәрләр җирлегендә якут хикәясе дә үсеш кичерә. Әдәбият мәйданына яшь язучылар аяк баса, яңа исемнәр күренә. Аларның күбесе үз иҗатын нәкъ менә хикәядән башлап җибәрә, соңыннан башка жанрларны да үзләштерә.

Бу китапка хәзерге якут авторларының хикәяләре тупланды. Арада бер повесть һәм романнан өзек тә бар. Бирелә укучы иң беренче чиратта замандашының тормышка карата төрле яклы күзаллауларын табачак. Шул ук вакытта электәлектән якут хикәясе тарихында ау хикәятләре, юмористик хикәяләр, борынгы ышанулар һәм тарихи риваятьләр кайтавазы булып яңгыраган хикәяләүләр аерым юнәлеш рәвешендә тамыр җәйгән. Минем фикеремчә, әлеге китапта укучы боларның барысы белән дә укып танышачак, чөнки якут прозаикларының чын милли фикере нәкъ менә шунда чагыла. Шуның белән берррәттән хикәяләрнең төп асылы социаль-әхлакый темаларга кагыла. Аерым кешенең җәмгыятьтәге роле, заманның актуаль мәсьәләләре төрле ракурсларда һәм тормыш шартларында ачыла.

Әлеге җыентыкта урын алган авторлар үз әсәрләрен үзгәртеп корудан соңгы чорда, саха халкының милли үзаңы ныгыган вакытта, зур үсеш алган социализмнан гади капитализмга күчешнең авыр дәверендә язганнар. Хикәяләрнең тематикасы да, проблематикасы да авторларның ул чорда чынбарлыкны тоюы һәм бүгенге тотрыксыз дөнья тәэлеше белән дә бәйләнгән. Бер яктан, авторлар тарихка, ышануларга һәм гореф-гадәтләргә таянып, аякларында нык басып торырга теләде, икенче яктан, алар табигатьне саклау, җир асты байлыкларын ерткычларча файдалану, төрле сәяси фикерләрнең бәрелешен, халыкны ярлылар һәм байларга бүлү кебек кискен проблемаларга да битараф кала алмады. Шуның белән бергә халыкның әхлакый, гомумкешелек кыйммәтләре иң алгы планга чыкты.

Якутиянең халык язучысы Николай Лугинов Чыңгызхан турында зур тарихи роман язган автор буларак билгеле, ләкин шул ук вакытта ул хикәя остасы да булып санала. Бу антологиягә кергән «Кара Козгын турында баллада» әсәре мәгә инде өч гасыр дәвамында бер нәселнең тормышын күзәткән Козгынның уйларын тасвирлый... Яшәү, үлем, уңыш, бәхет, мәхәббәт, өмет – болар барысы да кысылган вакыт эчендә бирелә. Зур романга торырлык әсәр тормыш һәм вакыт кыйммәтләре турында төптән уйланырга мәҗбүр итә.

Халык язучылары Василий Егоров-Тумарча белән Павел Харитонов-Ойуку да роман авторлары буларак мәгълүм, ләкин алар бервакытта да хикәяне игътибарсыз калдырмады. Ә халык язучысы Василий Васильев-Харысхал исән вакытында ук әлеге жанрда классикка әверелде – аның зур булмаган хикәяләре хәзерге заман кешесен үз тамырлары, табигатьнең бөек көче, кешенең аның белән берләшүе турында уйланырга мәҗбүр итә. Бу антологиягә халык язучысы Семён Попов-Туматның хикәясе дә керде, монда борынгы якут риваяте язучының бай теле белән сурәтләнә.

Антологиядә бүгенге якут прозаиклары рәтен тәкъдим иткән язучыларның хикәяләре дә урын алды. Алар үзләрен күптән оста каләм ияләре итеп таныттык, күбесе күләмле чәчмә әсәрләр дә иҗат итте: Елена Слепцова-Куорсуннаах, Данил Макеев, Анна Варламова-Айысхаана, Айысен Сивцев-Айсен Дойду, Степан Сивцев-Хамалга, Константин Эверстов, Олег Сидоров-Амгин. Алар артыннан безнең Язучылар берлегенең яшь әгъзалары килә: Анатолий Слепцов, Ангелина Васильева-Дайыына, Аграфена Кузьмина, Пётр Самсонов-Бүөтүр Хара, Валерий Андросов.

Антологиядә инде мәрхүм булган каләмдәшләребез Иннокентий Дмитриев-Сиэн Чолбодук һәм Иван Иннокентьевларның хикәяләре дә урын алды. Аларның әсәрләреннән башка хәзерге якут прозасының гомуми сурәте тулы булмас иде.

Ленар ШӘЕХ
тәрҗемәсе.

22–24 июньдә Саха (Якутия) Республикасында Татарстан Республикасы көннәре уза. Шул уңайдан газета укучыларыбызга якут шагыйрьләренең шигъри шәлкемен тәкъдим итәбез.

●Татарстан Республикасында Саха (Якутия) Республикасы көннәренә килгән якут язучылары (сулдан уңга): Рөстәм Каженкин, Николай Лугинов, Елена Слепцова – Куорсуннаах, Николай Винокуров – Урсун, Наталья Харлампьева, Аграфена Кузьмина, Гаврил Андросов. Арча районы. 6 июнь, 2021 ел

Семён ПОПОВ – СЭМЭН ТУМАТ
(1944), Якутиянең халык язучысы

* * *

Әрләшүләр була инде кайчак,
Үпкә-кинәләр дә булгалый.
Күзне йомам үз-үземне тыеп,
Тик әрнүләр генә югалмый.

Искә төшә шулчак синең белән
Иң беренче безнең кичке аш –
Син пешергән коймакның хуш исе,
Һәркайсысы –
Нәни бер кояш.

Кинәт онытыла әрләшүләр,
Хатирәдән күңел җылына.
Әйтерсең лә янә башлыйбыз күк
Безнең озын гомер юлын да...

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәсе.

Колын кебек юксынамын аны
Яшел киңлек – изге җирен дә.
Ачыласым килә уйларымда
Әдәп рөхсәт иткән кадәрле.
Көнлек мәшәкатьләр шатлыгында
Ихтыярны туплау кадерле.
Кан кардәшләр, кайда икән соң сез?
Сез саклаган таулы ил кайда?
Күтәрелеш, очу мәле сезнең
Сер артында булсын тик, берүк.
Хөсет уйлы явыз бәндә-җаннар
Эз салмасын синдә тибенеп.
Яшьләреңнең дәртле җырулары
Айыл өсләп рухын ныгытсын.
«Җакшылар!» дип якты сәламләүләр
Атлы халык җанын җылытсын.
Бабаларның утын саклаганда,
Сезнең дәрман ашсын Күккә!
Гүзәл Алтай төбәгендә калды сөю:
Тауларына, Күккә, Бөркеткә...

Гөлүсә БАТТАЛОВА тәрҗемәсе.

Әйе, мин – гап-гади бер якут. Яшимен елмаеп һәм балкып...

Наталья ХАРЛАМПЬЕВА
(1952), Якутиянең халык шагыйре

* * *

Мин – көчле хатын-кыз. Мин – якут.
Яшимен елмаеп һәм балкып.
Берәү дә кулымнан алмады,
Чанама тәүге юл салмады.
Берәү дә таягын бирмәде,
Ярдәмен күтәреп килмәде.
Аллага шөкер, дим, әле дә
Калганмын мин шушы хәлемдә.

Тырыштым, ихтыяр белдердем,
Үземнең атымда җилдердем.
Өлешкә тигәнне сайладым,
Иҗатта яшәдем, кайнадым.
«Бөеклек» чире дә йокмады –
Кыргый хис тамырда туктады.

Әйе, мин – беркатлы, самими.
Кешеләр: «Син үтә гади, – ди, –
Илһамлы акылың астарак,
Чәчеңнән дә хәтта кыскарак...»

Әйе, мин – гап-гади бер якут.
Яшимен елмаеп һәм балкып.
Барысын ишетәм дә күрәм,
Җаныма кояштан нур үрәм.
Ә болай яшәве рәхәт тә,
Куркыныч та кебек, әлбәттә:
Мең үлеп, мең кабат терелеп...
Һәм тыштан таш кебек күренеп...

Ленар ШӘЕХ тәрҗемәсе.

Виталий ВЛАСОВ
(1960), шагыйрь, композитор

СҮЗ

Минем галәм –
Табигатьнең сере.
Ә табышым –
Сүз көче, ул – тере.

Сахам минем
Гаиләм – табигатьтән.
Туган телем –
Аллаһ биргән сут-тәм!

Сүз – яшәүнең башы,
Сүзне хөрмәт итәм.
Балалар да аны
Белми димәм бүтән.

Үлемсездер ул тел,
Тередер гел бу тел.
Күзләр күргән дөнья
Булмас ансыз бөтен!

Сүзләр сайлап алдым:
Алар энҗе сыман.
Ачышымнан исә
Ачылыр күк томан...

Минем сүзләремнән
Сахам булыр үзгә.
Җырларымны бары
Багышлыйм мин сүзгә!

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА тәрҗемәсе.

Елена СЛЕПЦОВА – КУОРСУННААХ
(1964), шагыйрь, прозаик

САХА ХАЛКЫ ШӘҖӘРӘСЕ

Борынгыдан безнең тамырларда
Төркиләрнең кайнар каны аккан.
Шул кайнарлык белән ярсуланып,
Далаларда безнең атлар чапкан.

Яшь булса да, карт булса да якут,
Дошманыннан көчле рухы аның.
Чал гасырлар аша безне алга
Әйдәп бара рухы Чыныс Хаанның[1] .

Үзен санламаган бәндәләрнең
Кан тамырын өзгән безнең халык.
Беркем безгә киртә буналмаган,
Ташлаганбыз барсын юлдан алып.

Безнең атлар тояклары белән
Барабаннар кагып алга чапкан.
Халыкларга бөек оран салып,
Дөнья буйлап ташкын булып аккан.

Без ирекне кымыз итеп эчтек,
Дан җырладык бөек Олоңхога.
Таш һәм мүктә безнең эзләр ята,
Шәҗәрәбез безнең – Якут-Саха!

[1] **Чыныс Хаан** – якутларда язмыш алласы.

Рафис КОРБАН тәрҗемәсе.

Елизавета МИГАЛКИНА
(1973), шагыйрь

* * *

Бар нәрсәдән разыймын мин бүген
Яшьни бирсен, әйдә, яшеннәр!
Упкын сыман җирнең киңлегенә
Иң кадерле серне яшерәм.

Изге теләк юллыйм болыт аша,
Мактау булсын кояш нурына!
Канат кагып, иркен сулыш алып,
Кабат очам хәят юлына.

Бер борылып күккә баккан идем,
Алсулана җәйгор эзләре.
Иң кадерле серем белән бергә
Эреп бетте яшен, түзмәде.

Рифат СӘЛАХ тәрҗемәсе.

Яна БАЙГОЖАЕВА
(1977), шагыйрь, кинопродюсер

* * *

Гыйнварның зәмһәрир һавасын
Сулыймын йотлыгып.
Һәм үтеп чиксыз томаннар эченә
Чумамын омтылып.
Төртмәле сүзләрне, гайбәтне
Күтәрү җиңелрәк, катырсам боз итеп.
Бәхетсез көннәрем очрам кышларның
Чиксез ак куйнына бәс итеп.
Җанымны сызлаткан югалту ачысын,
Күңелем әрнүен басам да.
Мин алга атлыймын,
Хәл җыеп аякка басам да.

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА тәрҗемәсе.

Зинаида АРХИПОВА
(1980), шагыйрь, нәшир

* * *

Борылып карасам – суынган эзләрем
Һәм кырау болынның гөлләрен көйдергән.
Төнката җан өзгеч җил улап шом сала,
Юлларым мәңгелек көртләргә күмелгән.

Сәдака соранган хәерче хәлендә
Күкләргә кул изәп ялвардым догамда.
Асылда, мин кысыр хәсрәттән көйгәнмен,
Йөрәкне көл итеп, калмаган дуслар да...

Йөрәгең кушканча яшәү ник тыелган –
Дөньяның йөгеннән бушанып, күз яшьсез?
Тукталып хәл эстәр урыным, син кайда?
Юл башы кайда һәм... без кая барабыз?

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ тәрҗемәсе.

Александра МАТВЕЕВА – ДОЛГУРА (1983), шагыйрь

ИЗГЕ АЛТАЙДА

(Циклдан)

Кан кардәшләр газиз бишеге ул –
Гүзәл Алтай тарта мине дә!

Рөстәм КАЖЕНКИН
(1985), шагыйрь, тәрҗемәче

ТОРМЫШ ТУРЫНДА

Ала карга белән бергә
Өн сала Күк-Ата.
Сөйләк белән әкият уртак
Туганда ир-атка.

Ир кешегә якын күкнең
Гөлдерәү тавышы.
Урта дөньяда мөкатдәс
Ысыах вакыты.

Әгәр егет уйга чумса,
Тере үлән сула.
Кояш кереп югаладыр
Болыт арасына.

Ә ир-егет киткән чакта,
Җил белән Күк-Ата –
Юлы кыскамы, озынмы –
Аны искә ала.

Рифат СӘЛАХ тәрҗемәсе.

Гаврил АНДРОСОВ
(1985), шагыйрь, публицист, тәрҗемәче

* * *

Йомшак кар яуды. Узган төндә...
Кинәт...
«Чана кары яуды», – дип әйтер иде,
Ала үгезен җигеп, ерак бабам,
Күз карашын алыс офыкка төбәп...

Иске ас тунны җилкәмә салып,
Саха – Сайсары җирләре буйлап
Мин атлап киләм, тиз атлап киләм,
Ихаталарның тынлыгын җыйнап.
Чылбыр тагылган, йозак эленгән
Эт тормышына шом-шөбһә өстәп,
Буш һәм бормалы урамнан барам...
Эт өргән тавыш килгәндәй... тешләп.

Әле бик иртә. Әле караңгы.
Кинәттән генә тамагым ачты.
Бер утыруда зур гына кисәк
Ит ашар идем... – Уйлар таралды...

Ленар ШӘЕХ тәрҗемәсе.

Танылган кинорежиссер, Татарстан Кинематографистлар берлеге рәисе Илдар Ягъфәров белән Союз офисында очраштык. Офис «Татаркино» оешмасы белән бер ишегалдында урнашкан. Сүзебезне акча темасыннан башлап, республикада кинематографиянең хәле, һичшиксез булырга тиешле Кино фонды һәм һичшиксез төшерелергә тиешле яңа фильм проекты турында сөйләштек.

– Илдар, сез Кинематографистлар берлеге рәисе буларак хезмәт хакы аласызмы?

– Кечкенә генә хезмәт хакы бар – мин аны урынбасарыма бирәм, үземә берни дә алмыйм. Татарстан Дәүләт Советында кинематография буенча түгәрәк өстәл утырышыннан соң алга китеш булыр кебек – безнең Союзга штатлар биреләчәк. Язучылар берлегендәге кебек рәсми рәвештә хезмәт хакы ала башласак, яхшы булыр иде. Алты ел рәттән бушка эшләү авыр. Икенче яктан, мин проектлар эшли алам. Һәрхәлдә, үземнең бирердә кирәклегемне тоям…

– Сезнең оешмада әгъзалык взносы бармы?

– Елга 2000 сум.

– Әгъзаларга союзның файдасы бармы?

– Кешенең Союз әгъзасы значогы бар икән, димәк, ул профессиональ кинематограф. Союз аша грантлар алып була. Профессиональ ассоциацияләр грантлар бүлгәндә әгъзалык значогы булган кешегә күбрәк игътибар итәргә тиеш. Хакимият безне ишетә кебек. Әгъзалыкның өстенлекләре бар, матди ярдәм дә бар. Ул бик аз да түгел – 60–70 мең сум булырга мөмкин. Елга аны 12 кеше ала. Кешеләргә санаторийга юллама бирелә.

– Ә шәхсән сезгә ни файда? Әйтик, төрле комиссияләрдә утыра аласыз, Тукай комиссиясендә… тагын?

– Мин шул Тукай комиссиясендә генә. Аһ, дәүләт структуралары катнашкан әйбер турында сөйләү дә авыр. Яңарак кына комиссия утырышы булды. Минемчә, бу комиссия чын талантларны билгеләргә – Тукай премиясе комиссиясе әгъзалары тәкъдим ителгән әсәрне яхшылап өйрәнергә тиеш. Алар еш кына карап та тормыйлар.

– «Исәнмесез?!» фильмын – Мансур Гыйләҗев белән уртак хезмәтегезне халыкка күрсәттегез. Алда нинди планнар?

– Кино проекты ясый башлаганда, нинди татарны күздә тотарга дип уйлыйм да, миндә каршылык туа. Татарлар бик төрле. Алар бүлгәләнгән һәм бер-берсен яратмый. Динилар һәм дөньявилар, керәшене, мөселманы, зыялысы, Мәскәүләшкәне… Һәрберсе үзен акыллы һәм хаклы дип саный. Зур кораб авыр йөзә инде… Минем бер идея бар – Тукай турында кино төшерәсем килә. Аны, һичшиксез, төшерергә кирәк! Әмма ничек? Аны Голливуд проекты итеп төшерергә кирәк, мәктәп дәресе өчен кулланма итеп түгел. Суперпрофессиональ команда тупларга иде. Костюмнар, декорация, сюжет, диалоглар, акцентлар – барысы да уйланган булырга тиеш. Бу чын кино булырга тиеш! Төшердең дә киштәгә куйдың түгел.

– Безнең Тукай дөньяга кызык булачакмы?

– Мин Россия һәм чит ил дистрибьюторлары белән очрашсам, шул сорауны бирәләр: Россиягә бу проект нәрсәсе белән кызык, янәсе. Аңлатам – Россиядә руслардан тыш башка күп милләтләр дә яши. Ә рус киносы төшерсәм, үземә хыянәт итәмдер кебек. Екатеринбургта бер дистрибьютор белән бик каты бәхәсләштек. «Кемгә кирәк татар киносы?» – ди, үзенең хатыны татар бит әле… «Татарларга кирәк», – дим. Дөньяда милли Татарстан киносы барлыкка килергә тиештер бит?! Без эшләмәсәк, ул булмаячак. Милли кино дибез икән – ул милли булсын! Әлбәттә, шовинистик төсмерләрдә түгел, үзебезгә якын кино… Без нинди уртача кино ясасак, яки гомумроссия масштабы дип уйласак, Мәскәүнең Казан вокзалында сатылган өчпочмак булачак. Аның тәме авыл мичендә әбиләр пешергән өчпочмакныкы кебек түгел.

– Сез Тукай турында киноның нинди буласын күзаллыйсызмы?

– «Амадей» фильмы кебегрәк. Бөек Моцарт турында шундый фильм бар. Ул композиторның ничек музыка язуы турында түгел, кеше турында. Безгә дә Тукайда кеше күрергә кирәк. Бүгенге яшь буын өчен ул модалы, заманча кеше булырга тиеш. Тукай бит 27 яшендә күпме эшләп өлгергән. Ә татарлар гел вак әйбер буенча бәхәсләшә. Безнең «Исәнмесез?!» фильмын карагач та, «Алай җырләмиләр», диючеләр булды. Ә Бардада, мәсәлән, шулай җырлиләр. Һәр татарның үз дөреслеге…

– Тукай киносы буенча ниндидер эш барамы?

– Сценарий языла башлады. Кинематография дә хөкүмәткә бәйле бит – Татарстан хөкүмәтенә заявка бирәсем килә. Россия Мәдәният министрлыгына бирергә дә буладыр. Әмма көз көне интуициям хатлар язмаска кушты. Чөнки пандемия белән болай да авыр чак иде. Кинематография белән ачуларын китерәсем килмәде.

– Сезне интуициягез кыен хәлдә калдырмыймы?

– Кайчак тыңламыйча ялгышам. Мәдәни кодны, Президентлыгыбызны һәм Татарстанны саклыйбыз дисәк, безгә мәдәни калкан, димәк, кинематография кирәк. Дәүләт акча белән генә түгел, мәдәният белән дә көчле була ала. Нык дәүләт – ул яхшы әдәбият һәм музыка. Иран – күп тыюлары булган ябык территория саналса да, беренче чираттә кинематографияне үстерә башлады. Иранда шигыйлар – рәсем ясарга, кино төшерергә ярый. Иранның үз галимнәре бар. Ә безнең?! Сөнниләр булган дәүләттә мәдәни түгел, фәнни деградация бара.

– Ягъни, без Тукайны символ итеп түгел, кеше итеп күрә алачакбыз?

– Иң мөһиме – диетик кино килеп чыкмасын. Чөнки дөрес кеше турында дөрес киноны беркем дә карамаячак… Сүзне минем «Исәнмесез?!» фильмыннан башласагыз да, сез аны

«СУКБАЙ ЭТКӘ

Солтан Исхаков фотосы.

мактамадыгыз. Ә минем мактанасым килә, ул бит бик уңышлы карала. Кая гына килсәк тә, тулы заллар. Кемдер уңышсыз дип санаса да, мин аннан канәгать.

– Ә нигә акланасыз? Әйтсәләр әйтәләр инде.

– Проблема тирәндәрәк. Мин беркемне дә ышандырырга теләмим. Киресенчә, ошатучылар күбрәк икәнен әйтәсем килә. Ә җитәкчеләр арасында фильм уңышсыз дигән фикер бар.

– Сез аларны ул фикердән кире кайтармакчы буласызмы?

– Без ниндидер курчакка әйләнеп барабыз. Күргәнегез бардыр: татар концертларына хатын-кызлар калфак дип санап, сувенир лавкасындагы баш киеме кия. Без татар милләтенең дини аспектына таянабыз, Бөтендөнья татар конгрессы дини аспектка ставка ясый, дини оешмалар белән күбрәк аралаша. Нишләп татар милләте дөньяви яктан нығымый – аңлый алмыйм. Нишләп дөньяви татар милләте барлыкка килми? Дини тәрбиягә китеп барабыз кебек. Сезгә алай тоелмыймы?

– Тоела.

– Без моның белән ярты татарны югалтабыз. Без татарларның бөтенесен дә яратырга тиеш. Татарча белмичә, күңеле белән татар булганнарны да. Кая гына барсам да, авылда туып татарча яхшы өйрәнү бәхете елмаймаган кыз бала баса да, татарча начар белгәннәрне түбәнсетә. Һәрвакыт шулай!..

– Сез татарча беләсез бит, сез Рәшит Ягъфәровның улы!

– Мин өйрәнәм, татарча чыгыш ясарга да тырышам. Новосибирскида, Екатеринбургта күрәм – ярты зал татарча белми. Тел тирәлектә яшәргә тиеш. Дәүләттә кулланылырга тиеш. Мәктәптә укытылырга тиеш. Ул юк бит. Без дәшмибез... Телне куркытып өйрәтеп булмый. Кочаклап, «Молодец» дисәң яхшырак. Кеше керпе кебек, рәнҗетсәң энәләрен тырпайта. Кешеләрне рәнҗетмик! Дини кешеләрне дә! Алар безнең өчен дә дога кылсын. Алар Аллаһка якынрак. Әмма бөтен кешене бер төсле дип уйламасыннар.

– Быел 3 млн сумга Ә.Еники хикәяләре буенча кино төшереләчәк. Сез ул акчага кино төшерер идегезме?

– Нигә 3 миллионга ризалашалар соң? Нишләп продюсерлар эшләп карыйсы килгән бөтен кешене кино төшерергә ала? Янәсе, кемнеңдер төшәсе, кемнеңдер төшерәсе килә. Бу бит һәвәскәрләр көтүе! Аннары шулар төшергәнне карыйбыз, интеллигент кеше буларак дәшмибез. Шуңа күрә үзешчәннәр яңгырдан соң чебен гөмбәсе кебек арта бара. Без дәшмәгән саен алар бәхетле. Дәшә башларга кирәк! «Халима» да булдымы фильм? Адәм көлкесе! Юлия Захарова – республиканың беренче режиссерымы? Казахлар белән уртак проектны да ул төшерде (Г.Ибраһимовның «Алмачуар» повесте буенча «Тарлан» фильмы төшерелде).

– Сез татар фильмын ташлап качучыларга нинди киңәш бирәсез: калыгыз, дипме, китегез дипме?

– Кайберләренә китәргә булышам да әле. Акча табып, дүртесен режиссерлык курсларына җибәрдек. Татар киносы

иҗат иткән микродөнья мәңгелек. Аның срогы чыкмый.

– Ә безнең җитәкчелек һәм халык моны аңламый…

– Аңлыйлар дип уйлыйм. Әмма ышаныч юк. Ничек ышандырырга?.. Монда зур бер нюанс бар. Хәзер Мәдәният министрлыгы елына 8 млн сум бирә. Шулай килешенгән. Ул аны да бирмәскә мөмкин. Бирмәсә, кино ничек яшәр? Моны беркем дә уйламый һәм уйларга да теләми. Музыкантларның да филармониясе бар. Алар концерт куеп акча эшләсәләр дә, 10-15 мең сум хезмәт хакы алып шунда утыра. Кинематографистларның ул да юк.

– Рәссамнар да алмый.

– Әйе, алар белән дә фонд төзергә кирәк. Советлар Союзында рәссамнар нинди сыйныф иде! Әти Бакый Урманче белән сөйләшеп утырганда, шул тирәдә йөгереп йөргәнебезне хәтерлим. Рәссамнарга дәүләт нык булыша иде. Ашыгыч рәвештә алар өчен дә фонд төзеп, 200–300 миллион касы студиясе дә бетте. Кешеләр урамда калды.

– «Болгар җилләре», чыннан да, афера идеме?

– «Болгар җилләре» безгә күпне бирде. Яшь кинематографистлар үсеше өчен уңдырышлы туфрак иде ул. Яшь үсентеләр булып шытып чыктык. Мин дә алар арасында идем. 20 дән узган гына идем әле. Чәчәк чагым! Башкалар да чәчәк атты. Инде шул чәчәкләр җимеш бирә дисәк… ярдәм, таяныч булмады. «Күктау»дан соң башкача җитди ярдәм булмады. Ә бит ул чорда кино төшерелде. Рамил Төхвәтуллин актив фильмнар төшерде. Минемчә, 3-4 ел эчендә 4-5 фильм төшерде кебек. Фильмнар чыга торды, аның көйләнгән системасы юк иде.

– Мин аның «Зөләйха»сын бик яхшы фильм дип саныйм. «Күктау»ны да.

– «Зөләйха» – яхшы кино. «Исәнмесез?!» дә. Екатеринбургта хатын-кызлар фильмны карагач: «Безнең ирләрнең

ҺӘРКЕМ ТИБЕП КИТӘ»

төшерәсе килсә, кайтыр. Андый «лампочкасы» юк икән, барыбер төшерми, димәк, кайтуыннан файда юк. Әмма хәзер мине милли кино дигән булып, акча эшләргә йөрүчеләр борчый. Дәүләт акчасын алучылар арасында «очраклы пассажирлар» күп.

– Алга таба моны сез оештырырга хыялланган Кино фонды көйләячәкме? Президент акча сорап килүчеләрне шунда озатачакмы?

– Шулай булырга тиеш. Фонд булса, барысын да комиссия хәл итә.

– Сез елына 200 миллион сум бюджет белән Кино фонды сорыйсыз. Шул 200 миллионны сезгә биргән милләт ни алачак?

– Мин система булдыру турында сүз алып барам. Бездә система юк. Без хаоста. Бу фондның бер өлеше республиканың мәдәни имиджы өчен эшләячәк. Без ике елдан Тукай турында фильм төшерергә тиешлегебезне аңларга тиеш.

– Муса Җәлил турында фильм төшерү буенча да сүз барды. Анысы да барып чыкмады… Ярар, сез сораган 200 миллион турында сөйләшүне дәвам итик.

– Иң мөһиме – Кино фонды проектларның яхшы вуз тәмамлаган кешеләр кулында булуын контрольдә тотарга тиеш. Бу инде сиңа яхшы вуз тәмамласаң, профессия буенча күтәрелә аласың дип сигнал, датчик булып торырга тиеш. Кеше укуын тәмамлап кайта, ә ул безгә кирәкми булып чыга. Бездә барысы да кино төшерә, теге кыз да, бу малай да…

– Кибет товарның төзек эшләвен яки ризык булса, ашарга яраклы булуын гарантияли. Ә 200 миллионга мин нәрсә алам?

– Татарстанда милли кинематография барлыкка киләчәк.

– Ә продукция?

– Фильмнар була. Кино фонды аларны контрольдә тотачак.

– Алар начар булырга да мөмкин.

– Бездә театрлар чыгарган барча спектакльләр дә яхшымы әллә? Безнең күпме дәүләт театры бюджеттан акча ала! Ә сез кинематографистлардан гына нәтиҗә көтәсез. Аларның нәрсә хисабына ничек яшәвен берегез дә белми. Ягъни бездә кинематографист үз һөнәре белән акча эшли ала торган эш урыны юк. Ә бит кино, начармы–яхшымы, бар. Мин үзебезнекеләргә шуның өчен булса да рәхмәтле. Төзелсен шундый система – кешеләр ел саен нинди дә булса эшкә алынырлык булсын… Сүз бит режиссерлар турында гына бармый. Операторлар, рәссамнар, гримерлар… Алар системалы рәвештә кинода эшләр иде, бер фильмнан икенчесенә күчәр иде. Бу оештырылмаган. Хаоста кино тумый. Ә сез бездә тиз генә Канн фестивалендә җиңәрлек фильм көтәсез.

– Матди яктан безнең киноны күтәрерлек рәтебез бармы? Бер миллион сумга ярыйсы гына спектакль чыгарып була, кино чыгарып булмый…

– Ә син театрның күпме торганын беләсеңме? Камал театры, мәсәлән, без сораган бюджеттан ике тапкыр артык. Бу республика өчен зур акчамы? Без гигант акчалар сорыйбызмы? 200 миллион сум – бик кечкенә акча. Моңа кадрларны укыту да, сценарий базасы да, тулы метражлы һәм кыска метражлы фильмнар да, гомумән, кинематографиянең үсеше дә керә. Кино бит ул әзер сценарийдан башлана. Аны язарга кирәк. Сценарий язучы кешенең каядыр эшкә барасы, гаиләсен туендырасы бар. Менә мин дә гаиләмне туендырам. Мин Татарстанда ничектер яшәргә тиеш. Нишлим дип уйлыйсың? Төрле коммерция проектларына алынам. Бер дә җиңел түгел. Ни өчен мин ике елга бер фильм төшермәскә тиеш? Ни өчен мине төрле проектларга режиссер итеп алмыйлар?

– Илдар, хәтта безнең тамашачыга да безнең кино кирәкми түгелме? Без кайчан да булса үз тамашачыбызны үз кинобызга ышандыра алабызмы?

– Кино, беренче чиратта, безнең киләчәгебез өчен кирәк. Мин 50 елдан ни буласын белмим. Бәлки рус провинциясе булып калырбыз. Ә кино булса, безнең нәрсә уйлавыбызны, ниләр өчен борчылуыбызны белерләр иде.

– Ягъни киләчәк өчен эшлибез.

– Кино мәңгелек өчен эшләнгәнгә күрә, башка сәнгать төрләренә караганда кыйммәт тә инде. Спектакль карадың да чыктың. Музыка тыңладың да концерт бетте. Ә кино, кеше сум бюджет билгеләргә кирәк. Ел саен 100 рәссам Татарстан, безнең тормыш, безнең гадәт–йолалар турында картиналар иҗат итсен. Татарстанның «сәнгать фонды» җитәкчеләр, район башлыклары портретыннан гына тора. Бездән киләчәккә шул калачак.

– Туксанынчы елларда энтузиазм белән эшләп, ун ел эчендә «Күктау»ны төшерә алырлык булып җитешкәнбез. Ник тукталып калдык?

– Әй, нindидер мода китте, аеруча җитәкчеләр арасында, бөтен уңышсызлыкта кинематографистларны гаепләләр. Ә бит андый вәзгыятьне үзләре тудырды. Барысы да «Болгар җилләре…»нә килеп тоташа.

– Ягъни милли кинематография үсешенә шул коточкыч аяк чалды булып чыга?

– Ә бит Татарстан кинематографистларының, аеруча хәзергеләренең, бу фильмга бер катнашы да юк. Нәрсә, безнең төзелештә андый гына хаталар юкмы?

– Ләкин шушы бер вакыйга милли кинематографиянең киләчәгенә зыян салган. Нигә оныта алмыйлар?

– Зәгыйфьне кыйнау җиңел бит. Кинематографистлар кем алар? Иясез мескеннәр. Оясында утырган токымлы эткә карагандa, иясез сукбай этнең артына тибү җайлырак бит. Бер чиный да тына. Кинематографистлар да чама белән шушы халәттә иде. «Болгар җилләре»нең барып чыкмаячагын белгәч, Кинематография комитетын да тараттылар. Казан кинохроникасы ... маңгаена суга торган фильм булган», диде. Кемнәрдер кинода кызны көчләү күренеше булып, теманың өзелеп калуын ошатмады. Ә бит бу табигый: андый хәл булса, кыз баланың тормышын бозмас өчен авыл дәшмә. Чынлыкта да шулай бит! Бу бит символ: безне шулай итәләр, ә без дәшмибез.

Менә син алга таба ни белән шөгыльләнүемне сорыйсың. Миңа калса, бөтен кеше ошата торган кино төшерергә кирәк дигән чүп-чарны башымнан чыгарып атырга кирәк. Кино фонды да, минем тормышым да, без төшерәсе фильмнар да Татарстанда милли кино барлыкка килүгә багышланырга тиеш. Башкорт киносы, якут киносы кебек. Безнең кебекләр булмаса, ул барлыкка килә алмаячак. Татарстанда милли кино барлыкка килү республиканың яңа мәдәниятендә квант сикереше була. Чөнки без попсада терәлеп каттык, спектакльләрдә утырабыз. Алга китеш юк. Симфоник музыка, балет һәм опера татарлар өчен эшләми диярлек. Миңа калса, Кино фонды яшьләр өчен киләчәккә өмет сигналы була алыр иде.

Безнең әле татар җанлы Президентыбыз барында Кино фондын оештырып калырга кирәк. Ул милләт өчен борчыла кебек. Ул бит үзебезнең татар егете. 10 елдан соң боларны эшләп булмаячак – «миңа барыбер» булган кешеләр килүе мөмкин. Без бит бөтенләй карыша белмибез. Татар дәшми.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

intertat.tatar

МУЗАЛАР БЕРЛӘШКӘНДӘ

Сынлы сәнгать, музыка һәм әдәбият, бер-берсен тулыландырып һәм көчәйтеп, гасырлар буе янәшә бара. Шуңа күрә дә сәнгать, мәдәният һәм әдәбият юнәлешләрен үз күрүчеләрне бергә туплау максатыннан чыгып, Яр Чаллы шәһәре үзәк китапханәсенең сәнгать бүлегендә 2015 елны ук «Под сенью муз» дип аталган әдәбият-сәнгать салоны ачылды. Салон тамашачыларның бер урында берничә сәнгать юнәлешләре белән таныша алулары белән уңайлы. Биредәге тематик очрашуларны оештыруда шушы өлкә кешеләре актив булышлык итә. Салонга Татарстанда яшәүче танылган язучылар, музыкантлар, рәссамнар килеп, укучыларны үз иҗат яңалыклары белән таныштыра.

Бирела Чаллының мәшһүр рәссамнары Мадияр Хаҗиев, Хәмзә Шәрипов, Ленар Әхмәтов, Сәгыйдә Сиражиева, Анатолий Пашинның, Санкт-Петербургтан – Лилия Зияева, Чистайдан – Павел Самойлов, Казаннан Рина Ариаднаның һ.б. шәхси күргәзмәләре уңыш белән узды.

Салондагы очрашуларда камера оркестры солисты Павел Савочкин скрипкада уйный. Ә «Болгар» бию театрының оркестр солисты Людмила Каширская исә көйләрне гөслөдә башкара. Халык танылган гармунчы Роберт Галиев иҗат кичәсен дә җылы кабул итте. В.Высоцкий исемендәге автор җыры клубы әгъзаларының да җаннарны ярып сузган көйләренә тамашачылар кушылмыйча калмый.

Шигырь кичәләрендә рус шагыйрьләреннән Виктор Гладков, Светлана Попова, Николай Алешков, Людмила Дорженковская, татар әдипләреннән Хәмит Латыйф, Марс Ягудин, Равил Әхмәтҗанов, Мансур Сафин, Рәкит Әбделмәнов чыгыш ясады. Очрашуларның һәрберсендә залда ихлас әңгәмә куба: укучылар иҗат әһелләренә сораулары да бирә, алып баручыларның чыгышларына өстәмәләр дә кертә ала, иҗатчы осталары тыңлап бетергәч, үз бәяләмәләре белән дә уртаклаша.

Мондый очрашулардан соң китапханәләргә йөрүче укучыларыбыз да матур картиналарның, поэзиянең уңай энергетикасын туплап, канәгать булып таралыша.

Наилә ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА,
Яр Чаллы үзәк китапханәсенең сәнгать бүлеге мөдире.

Хисам КАМАЛОВ

БАЛАМЫ, ЧАГАМЫ?...

«Бердәнбер ул» повестеннан

Хәбир бер укучының дәфтәрен тикшереп чыкты да уйга калды. Тагы «начар» куярга туры килә инде. Сүз уртасында һаман хәреф төшереп калдыра. Нидән икән бу? Юк, белмәүдән генә түгел шикелле. Тел галиме профессор Мөхәммәтханов моны баланың нервысыннан килә торган нәрсә дип аңлата. Алай булса, укытучының биредә ни гаебе бар?

Өйалдында аяк тавышлары ишетелде. Ә-ә, элеккеге күрше Николай Иванович икән, Мишаның әтисе.

– Әйдүк, – диде Хәбир, кунакка урындык биреп, һәм шунда ук сизеп алды: Николай Ивановичның йөзендә ниндидер борчу бар иде. Хәбир, нәрсә уйларга белмичә, күзлеген салды, күз кырыен бармагы белән сөртеп торды да, тагын киеп, аңа таба карады.

– Сезнең эш тә майлы ботка түгел икән, – дип, Николай Иванович өстәлдәге әрдәнә кебек өелгән дәфтәрләргә ияге белән ымлады.

– Яраткан эш ялыктырмый, диләр бит. Эшнең күп булуы әйбәт тә, кайгыга урын калдырмый.

– Сезнең дә кайгы бармыни?

– Һи-и, беркемнең дә бурасы буш түгел инде. Баласыз йортта гына кайгы булмый торгандыр.

– Татар дөрес әйтә, бала-чага, дип. Чага шул, чага.

– Шул чагудан башка яшәп кара, ни рәхәте бар инде?

– Баланың чагуы да рәхәт дисең, ә? – дип, Николай Иванович шул сүзгә кәефе килгәндәй кеткелдәде. Аның җыерчыклы йомшак муенында бугаз төере селкенде. Ул нигәдер кулын селтәп куйды. Буяу цехында эшләгәнгә күрә, кул чугы беләзегенә кадәр алсу–шәмәхә төстә булуы күзгә ташлана иде.

– Әй, җан көйдерүләреннән бүтәнне белгән юк әле. Әнә тагы Миша сабагын белми. Укытучылары язып җибәргән, рус теле әйбәт түгел, алгебрага бөтенләй күңел бирми, дип. Аптыраш! – Николай Ивановичның йөзе Хәбиргә текәлде, аның күз карашы монда сезнең дә гаебегез бар дигән кебек иде. Берәр гаугачыл, чәнчәләк кеше булса, бу хакта авызыннан утлар чәчәр иде, ә эшче кеше гади шул, әйбәт.

Хәбирнең башыннан шундый уйлар узды һәм хәлне кискенәйтмәскә тырышып әйтте:

– Авыр инде Мишага, авыр, ләкин ул бик башлы малай, барысын да җиңеп чыгар.

– Аны Тәүгиздән ничек тә аерырга иде, шунсыз...

– Ничек аерасың инде аларны? Мишага тагы да кыен булмасмы соң?!

– Тәүгизне дә русчага гына бирәсегез калган, Хәбир туган, ә? Икесе бергә булсалар, әллә...

– Үзем татар теле укытучысы була торып, шулай эшләсәм, кешеләрдән уңайсыз бит?

– Кеше сүзе дип инде, Тәүгиз өчен...

– Әгәр алай итсәм, мин татар теленең көченә ышанмыйм булыр иде. Ә үзең ышанмаган эшне ярату да мөмкин түгел.

– Безнең меховойга быел авылдан килгән яшьләр керде, рус теле имтиханын бирә алмадык, диләр.

– Тырышлыклары җитмәгән, димәк. Тырышкан табар, ташка кадак кагар. Шулай бит?

– Син инде ана теленә бик бирелгән кеше, патриот, – диде Николай Иванович, һәм аның күзләрендә җылы очкыннар кабынды.

Хәбир дә елмайды.

– Син дә бит, Николай Иванович, меховой патриоты, рәсемең әнә, гел Мактау тактасыннан төшми.

– Әйе, фабрикага тел тидертәсе килми. Малай да шунда эшләсен иде, дип тели күңел. – Ул, күзләрен түбәнгә төбәп, уйчанланып калды.

– Кеше язмышын эш, хезмәт билгели шул, – дип, Хәбир нәтиҗә чыгарган кебек әйтте.

Шунда Николай Иванович башын күтәрде, ниндидер мөһим нәрсә әйтергә җыенган тавыш белән сүзне ялгады:

– Сез Мишаны үз итеп бетердегез, Хәбир туган, – диде. – Киенгәне гел сезнеке булды, ашавы да дигәндәй... Әнә мәктәбе әйтә, малайны үз кулыгызга алыгыз, ди. Моның өчен сез дә аны үзегездән биздерегез. Бу хакта элегрәк тә сүз булган иде. Инде шулай килешик.

– Тукта әле, Николай Иванович, ничек мин аңа безгә килмә, дип әйтим?

– Бик каты тый, бетте-китте, ни өчен син укытучы?

– Юк инде, без каты була алмыйбыз, Николай Иванович, үзең дә беләсең.

– Тәүгиз кәефе өчен генә Мишаны иялэндердегез, беләбез. Тәүгизне дә артык иркәләп бозасыз бит, Хәбир, чын...

– Иркәләү әйбәт түгел, әлбәттә, – диде Хәбир, ничектер киеренке тавыш белән. – Әмма тәрбия әсбабы итеп каеш куллану да бик начар. Бала күңелендә ачу төйнәлеп калуы бар.

Николай Иванович үзенең Мишага кырыс булуына төрттереп әйтүне бик яхшы аңлады һәм, башын читкә борып, кулын селтәде.

– Һәй, юкны сөйлисең син дә. Әнә эти мине гел тезген белән яра иде. Аңа карап, мин начар булмадым. Әтием түремдә. Ә Миша, үскәч, нигә катырак торып, фәнгә өйрәтмәдегез, диячәк. Әйе, әйтәчәк. Мин дә хәзер этигә шулай дим, ник тагын да ныграк кыйнап укытмадың, дим.

– Алайса, мин – пас. Шулай диләр бугай руслар. – Хәбир бер кулы белән күзлеген тотты, бу исә кәефе китә башлавын белгертә иде.

– Мишаны үзегезгә кертмәгез, менә шул, – дип, Николай Иванович капылт кына кузгалды да ишеккә таба атлады. Аның киеренке йөзеннән һәм бөкрәебрәк күренгән аркасыннан бик каты ачуы сизелеп калды.

Нигә дип шулчаклы изалана? Мишаның рус телен начаррак белүе әле баш китәрлек бәла түгел. Ул аны барыбер кайта–кайта укып булса да үзләштерәчәк. Ә менә кирәгеннән артык табалауның бала күңелендәге кешелеклелекне бетерүе бик ихтимал. Моны инде кире кайтарып булмый.

Ата белән бала... Ата-ана үзенчә тәрбияләргә тырыша, бала исә карыша, алар ихтыярына буйсынасы килми. Нилектән шулай? Кеше күңелендәге нинди көч эше бу? Тормышның нинди чыгыры хәрәкәт итә монда? Тәҗрибә белән коралланган ата-ана, баланы үз өлгесенә яраштырып, гел үзенчә генә итмәкче буламы? Нигә, укытучы үзенең баласын укытучы итәргә теләсә, начармыни? Ләкин балалар еш кына ата-анасы теләге белән йөрми шул. Тәҗрибәле ата-ананың сүзен тыңламый. Әмма тәҗрибәнең хәтәр ягы шунда: ул беркатлы, утырып җитмәгән шәхескә басым ясарга, бөгәргә ярата. Ә шунсыз үзеңә итеп булмый...

Баланың табигате нинди соң? Аның бер генә дә җиңелеп каласы килми. Хәтта эти-әнисе тарафыннан да җиңелергә теләми, үз-үзен расларга тырыша. Ягъни карыша. Җиңүнең бөтенчә ысулын белми әле ул, бөтәнчәсенә көче дә җитми. Бик табигый хәл югыйсә, әмма ата-анага баланың тыңламавы гаять тә авыр, гайре булып тоела.

Менә Тәүгиз мине тыңламаса, ифрат та кыен инде. Ачу килә, нишләргә белмисең. Кинәт бөтен өметләрең өзелгәндәй була. Нигә ул миңа карыша, дисең. Нигә әнисенә дорфа кылана? Гүя бездә аның кайтарасы ачуы бар. Синең сүзеңне, эшеңне юкка чыгару аңа ниндидер канәгатьлек бирә шикелле. Менә бит ничек? Класста да кайсы балалар шулай: хәтта укытучыны җиңәргә азапланалар. Бер җиңсә, беттең инде. Ул синең өстеңнән таптап йөри башлый...

Гамәлләребез милләткә мөнәсәбәтне билгеле

Казанның Совет районы 11 нче татар гимназиясендә төрледән-төрле бәйрәм кичәләре, танылган шәхесләребезгә багышланган эшлекле җыеннар, фәнни-гамәли конференцияләр еш уза, аларның исәбе дә елдан-ел арта бара. Шушы көннәрдә уку йортында «Дөньяда сүзебез бар» дип исемләнгән Хатыйп Миңнегулов исемендәге III Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе дә зур уңыш белән үтте. Конференциягә 200 дән артык эш кабул ителгән, аның 77 се финалга үткән. Алар арасында Мәскәү, Самара өлкәләреннән, Саха (Якутия), Чуашстан республикаларыннан, Татарстанның Арча, Балтач, Теләче, Биектау, Әтнә, Яшел Үзән, Алабуга, Түбән Кама, Кукмара, Сарман һ.б. районнарыннан килгән уңышлы эшләр бар.

Татар әдәбияты галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, профессор Хатыйп Миңнегулов 11 нче татар гимназиясендә 21 ел дәвамында фәнни консультант булып тора. Дәрвишләр бистәсендәге бу гимназиягә нигез салынган вакытта ул, фәнни җитәкче буларак, балаларны шушы уку йортына чакыруда, милли мәктәпне таныту юнәлешендә дә үзеннән күп өлеш керткән. Ул шул ук вакытта биредә белем бирүче укытучыларның иң яраткан остазы да, киңәшчесе дә. Бу инде галимнең Казан шәһәрендә фәнни-методик эшләрне, татар телендә милли мәгарифне үстерүдә чын-чынлап гамәли ярдәм күрсәтүе турында да сөйли. Казах, немец, төрек, үзбәк, инглиз телләрендә сөйләшә, аралаша алган Хатыйп ага – Россия күләмендә генә түгел, бөтен төрки дөньяда танылган галим. Х.Миңнегуловның төрки дөньяда аяк басмаган мәмләкәте калмавын да беләбез. Ул Европа, Азия илләрендә йөрде, Кытайга да барып чыгыш ясап кайтты, димәк ки, ул төрле мәмләкәтләрдә татарларны да югары дәрәҗәдә күрсәтте, дигән сүз.

Филология кандидаты, Казан федераль университеты доценты Таһир Гыйләҗев Хатыйп аганың алты дистә елга якын әдәбият фәненә хезмәт итүен, аның күп көч сорый торган тирән катламнарын күтәргән шәхес икәнлеген ассызыклады. «Хатыйп аганың башкарган эшләре тау кебек. Ул 1700 ләп мәкалә, 74 тән артык китап авторы, аларның 23 е – монография», – дип ачыклап үтте. Т.Гыйләҗев гыйльми эшчәнлек мәсьәләсендә галимә Р.Ганиеваның бер чыгышында Х.Миңнегуловны Р.Фәхреддин белән тиңләвен дә искә төшерде. Таһир әфәндегә Хатыйп ага белән Чуаш дәүләт университеты каршында оешкан Батыр филиалына барырга туры килгән. Салкын гына бинада кунганнар. Әмма Хатыйп ага үзенә җылы бүлмәләр таләп итмәгән, салкынча кабинетта дәресләр дә биргәннәр.

Тәлгать Галиуллин Х.Миңнегулов белән дуслар да, көндәшләр дә булып әдәбият фәненә хезмәт иткәннәр. Аларның ачуланышкан вакытлары да булган, әмма авыр вакытларында һәрвакытта да бер-берсенә иңнәрен куйганнар. «Гыйльми дөньяда үзара мактанышып кына алга китеп булмый. Хатыйпның яңа китабы күренсә, мин дә хезмәтләр, мәкаләләр яза башлыйм. Башкача була алмый. Телимме-теләмимме, мин аның иң зур галим икәнлеген таныйм. Ул – татар халкының иң борынгы чорларыннан алып рухи мирасын күтәргән кеше. Сәйф Сараи, Котб, Кол Гали, Тукай дисеңме... – диде Т.Галиуллин. – Ул хәтта хәзерге чор әдәбияты турында да яза. Шуның кадәр эш мәйданын бер кеше иңләп алып бара. Моннан тыш Хатыйп татар халкының сугыш, төрле катаклизмнар сәбәпле башка илләрдә калырга мәҗбүр булган, яки әсир төшкән кешеләрнең иҗатын да барлый. «Озын гомерем сәхифәләрем» дигән китабында Финляндиядә, Австралиядә, Америкада һ.б.илләрдә яшәгән милләттәшләребез иҗатының шигъри үрнәкләр бик күп китерелгән. Шуларны укып карыйм, анализлары бик заманча. Һәм ул шигырьләр татар телен, шигъриятен, әдәбиятын баета». Т.Галиуллинның Х.Миңнегулов хезмәтләре хакында, шулкадәр эшне үзе генә эшли микән, дип уйлаган чаклары да булган, ә инде аның Г.Исхакый турындагы бер фикерен күргәч, «Ул безнең заманның икенче Исхакые икән. Ул да үз гомерендә күп кеше башкара торган эшне берүзе алып барган. Аның һәр эш көне атнага, айга тора торган булган. Таланты, дәрте булмаса, ул кадәр эшне башкарып чыга алмас иде», – дигән нәтиҗә ясый.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шагыйрә Илсөяр Иксанова конференциядә ясаган чыгышында, Х.Миңнегуловның халыкка Шәрекъ әдәбиятын яраттыра алуы турында сөйләде. «Болгар чоры, Казан ханлыгы, Алтын Урда чоры әдәбияты безнең өчен бик катлаулы булып тоела иде. Хатыйп ага педагог буларак, хезмәтләре аша шәрекъ әдәбияты, шигъриятенең бөтен поэтикасын, матурлыгын ачып бирде», – диде шагыйрә.

Шул ук вакытта дуслары, хезмәттәшләре Х.Миңнегуловны гаҗәп дәрәҗәдә тынгысыз кеше буларак белә. Аны барлык чараларда күрергә мөмкин. Галимнең һәр вакыйгага шәхси карашы, фикере бар. Шул ук вакытта ул фикерне үзендә генә йөртми, җиткерә дә белә.

Әдәбият галиме, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов Х.Миңнегуловның әдәби тәнкыйтьче булуына игътибар юнәлтте. Хатыйп ага – татар әдәбиятын бик яхшы белгән аз санлы галимнәрнең берсе. Әдәбият турында сүз алып бару өчен аны бөтен итеп күрергә кирәк. Кол Галидән алып бүгенге көн әдәбиятына кергән мирасыбыз турында тирән белемгә нигезләнеп кенә этрафлы сүз әйтергә мөмкин. Икенчедән, аның Аяз Гыйләҗев, Әхмәт Рәшит, яисә Рәдиф Гаташ, Әхмәт Синегул иҗаты, матбугатта чыккан яңа китаплар турындагы рецензияләре Х.Миңнегуловны менә дигән тәнкыйтьче итеп таныта. Хатыйп аганың хезмәтләрен укыганда, аның язучылар иҗатында гомуми тематика, макетлар, төрлелек күренә. Бу галимнәрдән тирән белем, осталык сорый. «Әдәбиятыбызның борынгы чорларына һәм бүгенгесенә бәя биргән вакытта, аңа шәрекъ, гареб, көнбатыш, рус әдәбиятлары йогынтысы турында күп сөйлибез. Ничек кенә булмасын татар әдәбияты зур һәм бай һәм язучының формалашуы беренче чиратта ул милли нигезләргә таяна. Татарның үзенең мифологиясе, менә дигән фольклоры, борынгыдан алып менә дигән әдәбияты бар, шуны өйрәнү аша әдәбиятка килә һәм татар әдибе булып танылa. Татарның милли традицияләре, аның нигезе хакында без беренче чиратта горурланып, мактанып әйтергә тиеш тә инде. Хатыйп ага турында сөйләгәндә, аның милли горурлыгыбызны яклавы һәм саклавы, үзен борчыган мәсьәләләр турында ачыктан-ачык һәрберебез каршында әйтә алуы ул әдәбиятны бәяләгәндә дә чагылыш таба», – диде Ә.Закирҗанов.

Халык шагыйре Рәдиф Гаташ белән Х.Миңнегуловның дуслыгы инде 60 елдан артык вакыт дәвам итә. Бу – халыкка бергәләп хезмәт итүнең бәрәкәтле үрнәге. Р.Гаташ Х.Миңнегуловның китапларын кабат-кабат чыгарырга кирәклеген искәртте. «Бу хезмәтләр мине яңадан шәкерт итте. Мин аларны өйрәндем. Робагый, газәл кебек борынгы жанрларга мөрәҗәгать итүем, китаплар чыгаруым – шуннан. Миңа Х.Миңнегуловның йогынтысы искиткеч зур булды», – диде ул.

Чаллы шәһәренең 15 нче мәктәбендә директор урынбасары Сиринә Абдуллина, иң бәхетле студентлар татар теле һәм әдәбияты факультетында укыгандыр, дигән фикердә. «Хатыйп абыйның хезмәтләре әдәбиятыбызны халкыбызга гына җиткерү түгел, ә бәлки милләтебезне, әдәби мирасыбызны дөньякүләм таныту өчен башкарылган», – диде ул.

Зәй районы Апач авылында дөньяга килгән Хатыйп аганың әтисе Йосып ягыннан нәсел тамырлары руханилар, морзаларга барып тоташа. Хатыйп аганың әнисе исә – Сарайлы кызы, һәм ул туган авылына кайтып йөргән. «Мин кечкенәдән үк Хатыйп абыйның әнисенең авылга килүен зур бәйрәм кебек истә калдырганмын. Ул улының йөгерек телле, игътибарлы, җитез, хатын-кызларга карата ихтирамлы булуын матур итеп сөйли иде. Шул вакытта гына мин безнең нәселебездә нинди зур галим барлыгын аңладым», – диде С.Абдуллина.

Х.Миңнегулов киләчәктә һәркайсыбызның гамәлләрен милләт язмышы турында уйланып башкарырга тиешлеген әйтте. «Аерым шәхесләргә мөнәсәбәттә милләт язмышын үзәккә куеп, аның бүгенгесе, киләчәге турында уйланырга тиешбез. Кешенең эшенә аның милләткә нинди мөнәсәбәттә булуыннан, файдалы гамәлләр кылуыннан карап бәя бирергә кирәк», – диде ул. Конференцияне Дәрвишләр бистәсе балалар иҗат үзәгенең бүлек мөдире Ләйсән Антонова 11 нче гимназия коллективы белән берлектә әзерләгән. Гыйльми җыенны ул Питрәч районы Богородское авылы мәдәният йорты директоры Фәнил Галиуллин белән алып барды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

● «Агыйдел» ансамбле чыгышыннан бер күренеш.

● «Ак инеш» ансамбле биючеләре.

АКТАНЫШ –

Май аеның соңгы көннәрендә Актаныш яшьләренең талантлыгы, гүзәллеге белән хозурланып кайту бәхете эләкте әле. Әүвәл мәшһүр шагыйрь Гамил Афзалның туган көнендә аның хөрмәтенә уздырылган әдәби бәйге йомгаклары белән таныштык. Аннары инде Чаллы каласында яшәүче Актаныш якташлар җәмгыятенең матур кичәсендә сокланып утырырга туры килде. Һәммәсен дә тәртип буенча тезик.

Татар шигъриятенең сатира һәм лирика остасы булган Гамил Афзалны Актаныш районында искә алу йоласы 20 елга якын дәвам итә. Гомеренең күпчелек елларын Әлмәт каласында яшәп үткәрсә дә, Гамил ага Актанышның Такталачык авылында 1921 елда дөньяга килгән. Тормышның астын өскә китерү гарасаты 4 ел элегрәк кузгалган булса да, большевикларча тиранлык сәясәтенең кансыз тәгәрмәче яңадан да 20 ел буе дәвам иткән әле. 1927 елда илне ашыгыч рәвештә үстерү һәм бар дөньяны шаккатыру өчен беренче бишьеллык план кабул ителә бит. Аның нигезендә Харьковта, Сталинградта һәм әле бистә хәлендә генә булган Магнитогорскида металл кою һәм тракторлар җитештерү өчен зур заводлар һәм яңа кала төзү гамәлгә куела, ә большевиклар тырнагына эләккән казнада бернинди мая да юк. Байлык туплау ысулы тиз табыла: хәлле крестьяннарны кулак дип танырга һәм аларның байлыкларын талап, индустриягә юнәлтергә! Эшче кулларны каян табасы дип баш ватмалы түгел, шул кулаклар сыйныфын чыбыкны һәм мылтык көпшәсе астында яңа заводлар төзелешенә озатырга!.. Менә шулай итеп, авыл гыйбадлары барча Такталачык өчен үрнәк булган Гыймазетдин агай гаиләсен кулакка чыгарган да ерак Урал тарафына куып озатканнар. Республика буенча 45 меңгә якын кешене Пермь өлкәсенә, Уралга, Себергә «олактырып», Татарстан «кулак»ларга каршы көрәш буенча барча Россия күләмендә «рекорд» куйган. Магнитогорск каласын да туя белмәс илгә туган туфрагыннан куылган татар төзеп биргән!..

Туган нигезеннән куган чакта 9 яшьлек Гамилне дә ат арбасына чыгарып утыртканнар. Сабый баланы рәнҗетмәсләр әле, дигән өмет белән, яңа гына сырган фуфайка белән кичә генә бәйләнгән оекбашны да Гамил астына куеп «яшергәннәр». Ләкин илгә кичәге Щукарьлар шикелле хәерче-гыйбадлар хуҗа булып алган замана бит. Шундый гоҗларның берсе: «Хәзер бу сәвитнеке, ул безнеке!» – дип кычкырып ташланган да, сабый Гамил астыннан да фуфайка белән оекбашларны талап алып калган...

Гамил абый шушы нахак рәнҗетүне кабул итә алмады, күрәсең, күрше Әлмәттә генә яшәсә дә, кабат туган авылына кайтып күренмәде. Ә үзе барыбер Актанышны якын иткән инде. 80 яшьлек юбилей кичәсендә котларга дип чыккач, мин фәкыйрегезне дә «Син Актанышныкы, сиңа ярый, янымда тор», дип байтак минут сәхнә түреннән төшермичә тотты... Ходайның рәхмәте, кадерен үз вакытында күрә белделәр: шәһәр башлыгы Ришат Әбүбәкеров менә шушы 80 яшьлеге уңаеннан Гамил абый яшәгән урамга әле ул үзе исән чагында ук аның исемен дә биреп куйды...

Гамил абыйны, әлбәттә, Актанышта да чиксез сагыналар. 2003 елда вафат булганнан соң, һәр май ае саен аны искә алу көне, аның хөрмәтенә республика мәктәпләрендә Гамил Афзал конкурсы үткәрелә. Быел да менә конкурста Татарстан гына түгел, Башкортстан, Чуашстан, Марий Эл укучылары да катнашкан икән. Алдынгылык яулаган вәкилләре Гамил абыйның туган авылы Такталачыкка да барып килде. Гамил абый исемен йөртүче урамда, элек алар йорты урынына куелган стеланы авыл мәчете һәм җәмәгатьчелек үзәге янына күчергәннәр, бөек шагыйрьне искә алып, шул стела янына чәчәкләр дә салдык. Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тантанасы Актаныш үзәгендә, әле былтыр гына ачылган Гуманитар гимназия бинасында узды. Конкурста Гран-при бүләгенә лаек булган Рәлиф Гыйздәтуллин атлы егетнең шигырьләре аеры җәлеп итте. Берсе бик гаҗәеп. Егет быел гына үзенең урта мәктәпне тәмамлавын да әйтми. Туган өенә кайтып керә дә әнисен кочып ала. Ихатага чыгып, абзар тирәсендә тир түгүче абыйлары белән хозурлана. Аннары акрын гына зиратка юнәлә дә «Исәнме, эти!» дип каберне сәламли. Шигырь тәмам, ә егетнең ятим үсүе, михнәт-сызланулар әйтелмичә кала...

● Актаныш мәдәният паркына куелган Г.Афзал бюсты янында.

Гимназиядә 400 дән артык, хәтта урыс өлкәләреннән килгән балалар да белем ала. Әлбәттә, замана таләбе буенча, информатика фәненә урын мул бирелгән. Шул ук заманага яраклашып, балалар компьютерларда комикслар ясарга да өйрәнә. Журнал рәвешендә чыгарып куелган бер комикста 1681-1684 елларда узган азатлык явының җитәкчеләреннән берсе булган Сәет хәзрәт Җәгъфәр улының рәсемен күреп, нык гаҗәпкә калдым. Нигә Сәет Җәгъфәр? Аның туган төбәге билгесез, ул фетнә отрядлары белән дә Пермь, Көнгер, Чиләбе араларында яу йөргән. Ә шул ук азатлык явының юлбашчысы булган Теләкәй морза Улукай углы үзебезнең Актаныш районыннан чыккан, шушында ук үз исемендәге Теләкәй авылын нигезләп калдырган, 1684 елда дар агачына асып үтерелгән батыр лабаса! Нишләп Актанышныкылар аны данга чөйми, газиз Теләкәйләре белән нигә горурланмый?..

Сере ерак түгел: Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы әзерләп чыгарган тарих дәреслекләрендә фетнә белән Пермь якларында җитәкчелек иткән Сәет Җәгъфәр исеме генә теркәлгән, ә Актаныш туфрагында туган бөек Теләкәй искә дә алынмыйча, йомылып калган икән. Министрыбыз Илсур әфәнде Һадиуллинны бик тә хөрмәт итәм, мәктәпләр өчен дәреслекне кайсыдыр институтның үтә зур «тарихчы»сы әзерләп биргәндер, дип гөманлыйм. Ләкин күңелне ачы сорау тырный: «Министрлык вәкилләре, дәреслекләр язуны надан «тарихчылар» кулына тапшырып, ник дәүләт акчасын суга саласыз сез?!.»

Актаныш үзәгендәге мәдәният паркы ел саен үзгәрешләр белән сокландыра. Бер ай элек кенә хезмәттәшебез Ләбиб Лерон Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган иде, аның рәсеме белән атын инде шундый дәрәҗәдәге якташлары хөрмәтенә булдырылган стелага да куярга өлгергәннәр. Ләбибне ике-өч ай яшәве өчен генә

● Актаныш сандугачы Лилия Хөсәенова.

● Г.Афзал фестивalenең Гран-при иясе Рәлиф Гыйздәтуллин.

ТАЛАНТЛАР ИЛЕ

Мөслимдә дә район стеласына эләргә ашыкканнар, әмма асыл егет Актаныш туфрагында тәпи баскан кеше, гыйлемне дә Олы Имәндә алган.

Актаныштагы гуманитар гимназиянең актлар залында кичә рәвешендә үткән тантанада ук шушы мәктәп укучыларының бию төркемнәре, яшь җырчылар чыгышы сокландырган иде, икенче көнне мондый манзара Чаллы каласындагы «Энергетик» мәдәният сараенда да дәвам итте. Чаллыда яшәүче актанышлыларның елына бер мәртәбә җыелып, зур кичә үткәрә торган күркәм йоласы бар, аңа Актанышның үзеннән дә кунаклар чакыралар. Узган ел гына коронавирус зәхмәте мондый чараны уздырырга ирек бирми калды. Әллә шуңадырмы, район башлыгы Энгель Фәттахов Чаллыдагы кичәгә «Агыйдел» җыр һәм бию ансамблен дә, шул зәхмәт аркасында ике ел буена зур сәхнә күрмичә җәфаланган талантлы балаларны да алып килгән. Ике йөз вәкилдән хасил кунакларның ике сәгатькә сузылган чыгышы күңел өчен ял да, якташ талантлар сәләтенә соклану учагы да булды.

● Район башлыгы Э.Фәттахов Чаллыдагы актанышлылар җәмгыяте рәисе Ф.Газетдиновка Рәхмәт сүзе тапшыра.

Районнар буенча йөрмичә тормыйбыз, хәтта күршедәге Удмуртия, Башкортстан, Чувашстан республикаларының калаларында да балалар коллективларының җыр һәм биюләрен дистәләрчә тапкыр күзәткән бар. Үзебезнең Татарстандагы һәрбер район үзәгендә сәнгать мәктәпләре эшләп тора, һәрберсендә яшь буын җыр-биюгә өйрәнә. Бер район башлыгының балалар ансамблен киендерү өчен генә дә ел саен бер-ике миллион тәңкәне казнадан махсус рәвештә бүлеп бирүен дә беләм. Һәм һәркемгә мәгълүм: Татарстан Президенты Р.Миңнеханов та, сәнгать дөньясы, эстрада яңарсын дип, ел саен 20 миллион тәңкәне «Үзгәреш җиле» фестивале өчен бүлеп тора. Ләкин иң аянычы – ул «җилләр» дә, 20 миллионнар да сәхнәне яңартмый, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Хәйдәр Бигичев, Фәридә Кудашева кебек талант иләрен бер дә өстәми шул.

Актаныш туфрагында һәрбер агач, хәтта табагач та бии, дигән гыйбарәдә хаклык та бар шикелле. «Энергетик» сәхнәсен ду китереп биегән һәм ун ел элек үк барча Татарстан районнары арасында бердәнбер булып «дәүләт ансамбле» статусын алган «Агыйдел» коллективының яңадан-яңа, гел үзгәреп торучы чыгышларына таң калмыйча мөмкин түгел. Бер дә, башкала коллективлары шикелле, «Кармен», «Фигаро» спектакльләре яисә Чайковский, Вагнер, Шопен көйләрен дә сайлап тормаганнар, үзебезнең «гап-гади», инде меңнәр колагы һәм күңеле өчен газиз «Талы, талы», «Ай, былбылым», «Олы юлның тузаны», «Агыйдел буенда җәяү йөрисем килә», «Тал әйләнә» җырларының моңы уңаена теттерәләр генә! Һәрбер чыгышлары – аерым спектакль, һәрбер бию – өр-яңа, кабатланмас дөнья! Ансамбльнең һәр биюен тудыручы һәм сәхнәгә куючы Лилия Фәтхуллинаның таланты алдында мең кат баш иясе!

Сабыйларның «Ак инеш» ансамбле коллективын районнан-районга йөртә-йөртә, үрнәк итеп күрсәтсәң дә була. Ул «Йолдызлык» фестивалендә быел юкка гына республика күләмендә Гран-при яуламаган инде! Президентыбыз финанслаган «Үзгәреш җиле» фестиваленең катып калуы, бер урында таптану икәнлеге турында да әйтеп үттек. Ул фестивальне оештыручылар Актанышның Лилия Хөсәенова, Рәзилә Галиева кебек гүзәлләре җырлавын бер тыңласын иде. Аларның Венера Ганиеваны да көнләштерерлек нәфис тавышларын, былбыл шикелле сыгылмалы итеп, гөлдән-гөлгә сикергәләп сузган моңнарын тыңлап туя алмаслык!..

Һәрберебезгә мәгълүм: гүзәллекне тасвирлау, мактау өчен сүз табуы читен. Асылташларны үзең барып күзәтү кыйбатлырак. «Агыйдел» килми калмас, аңа сокланыгыз!

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

● Актанышның гуманитар гимназиясендә якташ язучылар сәхифәсе.

● Тукай бүләгенә ия актанышлылар стеласына Л.Лерон исеме өстәлде.

●Композитор Ренат Еникиев һәм Суфия Бәдретдинова.

●Фасил Әхмәтовның тууына 70 ел тулуга багышланган кичәдә. 2005 ел.

ДӨНЬЯДА ҮЛМӘС

Ренат Еникиев студент елларыннан ук абыем - композитор Фасил Әхмәтовның якын дусты иде. 1960 елларда оешкан яшь композиторларның иҗади төркемен «Куәтле төркем» дип йөрттеләр. Төркемне энергияләре ташып торган, үтә тәвәккәл, дәртле, кыю иҗади омтылышлар белән яшәгән яшь композиторлар Фасил Әхмәтов (1935–1998), Ренат Еникиев (1937–2020), Мирсәет Яруллин (1938–2009), Рафаэль Белялов (1940 –1999), Илдус Якубов (1935–2021) тәшкил итә иде.

Ренат Еникиев музыкасын мин яшь чагымнан тыңлап үстем. Казанда ел саен үтә торган Композиторлар берлеге корылтайларында Ренат абыйның яңа әсәрләре еш яңгырый иде. Аны миңа Фасил абыем Әхмәт күрсәтте. Бераздан без аралаша башладык. Аның белән гәпләшкәндә мине гаҗәпкә калдырганы – композиторның логикага нигезләнгән фикерләү сәләте, төгәл дәлилләр, төрле фактларны исбатлау.

Беркөнне әңгәмә барышында мин, яшь музыкант, аның каршында ялгыш фикер яңгыраттым: «Бәлки, фәлән композиторның сәләте юктыр?» Ренат абый эмоциональ рәвештә шундук аңлатып бирде: «Композитор сәләтсез була алмый, чөнки музыка училищесында, консерваториядә укыганда, ул «селекция» үтә». Асылда да композиторны үстерү системасы билгеле логика, принципларга нигезләнеп төзелгән. Шуңа күрә композиторлар цехында очраклы эләккән, сәләтсез моң иясе була алмый. Димәк, һәркайсы үз иҗатында уку дәверендә туплаган белемен, потенциалын күрсәтә, тормышка ашыра.

Абыем Ф.Әхмәт вафатыннан соң Ренат абый белән ешрак аралаша башладык. Сәбәбе – мин «Аккош җыры. Композитор Әхмәтов» дип исемләнәчәк китап әзерли башладым. Ренат абыйга да дусты турында истәлекләр язарга тәкъдим ителде. Иң элек аның истәлекләрен диктофонга яздырдым, аннары шул кулъязманы тикшерү өчен китердем... Мәкаләне шомарту авырлык белән барды. Ахыр чиктә ул әзеп салды: «Үзем язган мәкалә – иң яхшысы булыр!» Шулай итеп «Милли бәйрәм кичәсе» дигән язма кулыма эләкте. Иң гаҗәпләндергәне: мәкалә азагында Ренат абый Татарстан китап нәшрияты редакторына мөрәҗәгать иткән: «Бер хәреф һәм сүзне дә үзгәртмәскә!» Шул чакта ук мин композиторның характер ныклыгы, аның һәр әйткән сүзе өчен җаваплы булуы турында уйлап куйдым...

Р.Еникиев – Казандагы зыялы, интеллектуаль гаилә вәкиле. Аның нәсел тамырында – Уфа губернасының Бәләбәй өязендәге Каргалы авылы морзалары. Әтисе – Әхмәтгәрәй Сәхибгәрәй улы, университет тәмамлап, сәяси әдәбият нәшриятында корректор вазифасын башкара. Улына бер яшь тулганчы вафат була. Әнисе – Разия Зиннәтулла кызы – Габдулла Тукайның якын туганы. Аның туганнары – дин әһелләре, муллалар.

Р.Еникиев гаиләсе Казанның Яңа бистәсендә, Г.Камал урамында яши. Әнисе ялгыз көе ике ул, бер кыз тәрбияләп үстерә. Балалар бакчасының оркестрында ук Ренат курайда һәм гармунда уйнарга өйрәнә. Яшь музыкант күп тапкырлар район, республика күләмендә үткәрелгән олимпиадаларда призлы урыннар яулый. Татар мохитендә, 12 номерлы мәктәптә укыганга күрә, Ренат балачакта рус телен белми, кирәк чакта әнисе тылмач була. Шул ук әнисе улын 1 номерлы музыка мәктәбенә озата. Мәктәп директоры Рувим Поляков сәләтле малайга виолончельдә уйнарга тәкъдим итә. Ренат аның тәкъдименнән баш тарта. Киләсе елда алар әнисе белән 6 нчы музыка мәктәбенә юл тоталар. Ниһаять, баланы фортепиано бүлегенә укырга алалар. Беренче укытучысы итеп Нина Николаевна Карукес билгеләнә. Ул Еникиев язмышында зур роль уйный. Нина Николаевна фортепианода уйнарга өйрәтүдән тыш аның рухи остазы да була.

Карукес Казанга Кытайдан, Шанхай шәһәреннән күчеп килә. Сөйкемле, чибәр, мөлаем хатын, Нина Николаевна матур, заманча киенә. Ә иң мөһиме – аның рус һәм көнбатыш композиторларның ноталарыннан торган ифрат бай китапханәсе бар, сәләтле укучылар тәүге тапкыр Д.Шостакович, С.Прокофьев һәм А.Хачатурян әсәрләре белән шунда таныша.

Р.Еникиев сөйләве буенча, шушы ике хатын: әнисе һәм Н.Карукес аның шәхесен формалаштыруда ярдәм итә. Әнисе Разия тәвәккәл, кыю холыклы була. Бөек Ватан сугышы чорында да аның балалары ачлык күрми. Сыерлары булу өстенә ул күршеләргә, танышларга телогрейкалар тегеп бирә. Әнисе ярдәме белән Ренат күп бәла-казаларны читләтеп үтә. Хәтта, Разия апа улына «әүлия» дип дәшә, аның белән олыларча киңәшләшә.

11 яшьлек чагында Ренат Еникиевтә импровизациягә, көйләр чыгаруга кызыксыну уяна. Н.Карукес монда да егеткә кулын суза, хәтта үзенең китапханәсеннән М.Гнесинның «Практик композициянең тәүге курсы» дигән әсбап бүләк итә.

4 елдан соң, Р.Еникиев Ю.В.Виноградов классына Казан музыка училищесына кабул ителә. Виноградовның укыту методикасы җитди һәм кырыс. Ул үз шәкертләренә үтә дә күп өй эшләре биреп, яшь буынны төрле музыкаль жанрлар белән таныштыра, композиторлар партитурасында нәшрият җибәргән хаталарны эзләп табуны таләп итә. Училище Ренатка профессиональ яктан үсү, музыкаль кругозорын киңәйтүдә бик нык булыша. Шуңадыр студент елларында ук Ренат Г.Тукай сүзләренә балалар өчен җырлар, М.Җәлил шигыренә «Бәхет» романсын, сонет иҗат итә.

Казан дәүләт консерваториясендә Р.Еникиев А.С.Леман классына эләгә. Шул ук класста Ренатның якын дуслары – Фасил Әхмәтов белән Мирсәет Яруллин да укуларын дәвам итә. Гадәттә, студентлар профессор каршында яңа иҗат иткән әсәрләрен фортепианода уйнап күрсәтә, аннары һәркем үз фикерен әйтә, музыканы анализлый. Немец милләтеннән булган профессор Альберт Семенович та бик күп татар композиторларының әсәрләрен яттан белә һәм дәрес барышында фортепиано артына утырып, уйнап күрсәтә. Үзе дә менә дигән музыкант, дистәләгән композитор үстергән профессор А.Леманның татар музыка сәнгатенә керткән хезмәте бәяләп бетергесез.

Әле Р.Еникиев музыка училищесында укыган дәвердә үк анда иҗади түгәрәк ачыла. Җитәкчесе – яшь композитор Азонтин Фәттах. Җыелышлар кич үтә, төрле бүлекләрдән җыелган яшьләр иптәшләрен яңа гына иҗат иткән әсәрләре белән таныштыра. Әле исемнәре халыкка билгесез музыка белгечләре, теоретиклар ишеткән әсәрләргә анализ кора, кырыс тәнкыйть белән чыгыш ясый. Шундый шартларда Р.Еникиевнең һәм аның дус-ишләренең музыкаль үсүе формалаша, осталыклары чарлана.

Консерваториянең Ю.Виноградов, А.Фәттах кебек мөгаллимнәреннән тыш Р.Еникиев фортепиано укытучысы Надежда Рецкерны телгә ала иде. Ул бер сәгать урынына Ренат абыйны 4-5 шәр сәгать укыта. Яшь студент, өйгә кайткач, үзлегеннән мавыгып, укытучысы белән өйрәнгән әсәрне пианинода уйный. Нәтиҗәдә, консерваторияне тәмамлаганда, ул инде фортепианода Бетховен сонаталарын, Шопен этюдларын, Шуман концертын, Бах әсәрләрен яратып башкара.

Студент елларында Ренат үзен соната, квартет, татар музыкасында моңарчы очрамый торган яңа төр музыкаль жанрларда да сынап карый: трио, концерт иҗат итә. Еникиев татар сәнгатенең, милли музыканың зур потенциалын тоеп иҗат итә. Ул заманда кайбер консерватория укытучылары яшь композиторның новатор әсәрләрен кабул итә алмый, зур бәхәсләр куба. Еникиевнең яңа музыкаль тел белән язылган әсәрләренә карата, хәтта шәхесенә карата да кайбер укытучылар тарафыннан нәфрәт туа (композиторлар берлегендә башкарылган скрипка, альт, виолончель өчен Трио; Соната). Композитор – «формалист» дипломы куркыныч астында, бернигә комиссия әгъзасы консерватория тәмамлаган таныклыкны бирмәс өчен нык фикердә торалар. Пленумда купкан низагны Мәскәү белгече Н.Шумская юкка чыгара. Яшь композитор консерваториядән куылмый, ул дипломлы була.

Әмма диплом ала да, Ренат... эшсез кала. Яшәү өчен, тамак туйдыру өчен очраклы эшләргә алына: базарда, тәзелештә, җир казу, йөк ташу... Кыска вакыт эчендә дипломлы композиторга Г.Камал исемендәге дәүләт

МОҢЫ КАЛДЫ

●Ренат Еникиев, Суфия Бәдретдинова, ..., Әхмәт Кәримов.

академия театрында концертмейстер вазифасын башкарырга туры килә. Ул чорда аны театраль музыканың үзенчәлеге кызыксындыра. Ләкин театрда музыкаль бүлек мөдире булып йөрү дә Ренатны канәгатьләндерми башлый. Бераздан өлкә комитетының идеология бүлеге җитәкчесе Мирзаһит Вәлиев ярдәме белән ул радиокомитетта концертмейстер булып эшли башлый. Аннан да аңламаучылык аркасында китәргә туры килә.

Ниһаять, Р.Еникиевнең тагын бер эш урыны – Татар дәүләт филармониясендә дусты, җырчы Илһам Шакиров төркемендә пианист – концертмейстер. Илһамның иҗаты чәчәк атып килә торган вакыт, аны яраталар, зарыгып чыгышларын көтәләр. Артистлар илнең төрле почмакларына, шәһәрләргә, авылларга гастрольләргә йөри. Мондый шартларда яшь композиторның музыка иҗат итәргә һич вакыты калмый. Биш елдан соң Ренат алдында тагын сорау туа: нишләргә? Иҗатка сусаган Еникиев, композиторлык юлын сайлый.

Телгә алынган елларда композиторлар арасында «ирекле иҗатчы» булып яшәүче аз (мәсәлән, М.Яруллин – ТР Композиторлар берлеге рәисе; Р.Белялов – консерватория укытучысы). «Куәтле төркем»нән фәкать Фасил Әхмәтов белән Ренат Еникиев кына үзләрен тулысынча композитор хезмәтенә багышлый.

Таләпчән Еникиев үзенә максат итеп татар музыкасы өчен яңа биеклекләр билгели: «Соната жанрында, мәсәлән, аеруча мине борчыган шәхси һәм философик проблемаларны чагылдырырга мөмкин; музыкаль образларны төрлеләндереп, эшкәртеп, тезис, антитезис белән баетып, минем музыкаль фикерләүгә хас булган монотематизм кертеп язарга».

Кыска вакыт эчендә Еникиев тарафыннан күләмле әсәрләр языла: өч квартет, «Оркестр өчен Рапсодия», вокаль-симфоник поэма «Муса Җәлил истәлегенә», фортепиано өчен күп санлы миниатюралар, баритон белән оркестр өчен «Карьят батыр» сюитасы, җырлар, романслар һ.б.

Иҗади тормыш дәверендә Еникиев татар милли музыкасына яңа төр жанрларны кертә бара: ария, ариэтта, юмореска, вальс-скерцо, каприччио, фуга, пассакалья, рапсодия. Атап үткән әсәрләрдә үҗәтлек, музыкаль темаларның агышында лиризм, кыюлык, форма төзелешендә рационалльлек, музыкаль телнең байлыгы сизелеп тора. Композиторның һәр әсәре чын тойгылар, киң фәлсәфи нәтиҗәләр белән сугарылган. Аның әсәрләрендә бүгенге заман пульсы сизелә. Композиторның баш миендә туган, йөрәк җылысы белән өретелгән, темперамент һәм дәрт белән баетылган музыка яшь һәм балигъ булган тыңлаучыларның күңелләренә барып ирешә, рәхәтлек, ләззәт бирә.

Еникиевнең зур хөрмәт вә мәхәббәт уяткан җырлары һәм романсларның күбесе татар вокаль музыканың шедеврлары булып танылды: «Ак дулкыннар» (М.Хөсәен), «Синең эзләр» (Р.Әхмәтҗанов), «Үрләр менгәч» (С.Хәким), «Ышанам» (Л.Айтуганов) һ.б. Кешегә хас кайбер кимчелекләрдән көлә торган җырлар: «Хатынга булмый ярап» (М.Хөсәен), «Өф-өф итеп» (Г.Афзал) халык арасында тиз таралды. Әлеге җырларга хәзерге тыңлаучыларның да мәхәббәте кимегәне юк.

Нинди генә жанрда язуына карамастан, Р.Еникиев әсәрләрендә рухи көрәш, җитди темаларга омтылу, кешенең үз-үзен камилләштерүе, пакьләнү, сафлану кебек сыйфатларны милләтнең сынлы сәнгать нигезен булдыручы бөек Бакый Урманче сизеп ала. Ике иҗатчының, яшь аерымлыгына карамастан, рухи якынлыгы, тәңгәллеге, дуслыгы дистә елларга сузыла. Ренат өлкән дустына берничә әсәрен багышлый: скрипка һәм фортепиано өчен «Романс»; Б.Урманче сүзләренә язылган тенор вә фортепиано өчен «Багышлау»; виолончель һәм фортепиано өчен «Сагыш». Гыйбрәтлесе шул: Р.Еникиев үзенең афишаларына һәм чакыру билетларына фото урынына Б.Урманче ясаган график портретын урнаштыра торган була. Бу, әлбәттә, ике классик, ике даһиның чын дуслык билгесе.

Җәмәгать эшендә дә Р.Еникиев читтә яшәмәде. Мәсәлән, композитор Фасил Әхмәт вафатыннан соң, ул Салих Сәйдәшев музееның идарә җитәкчесе була. Бала чактан мәшһүр Сәйдәш музыкасына гашыйк Ренат абый «Сәйдәшстан» дигән пьесалар циклын яза. Монда даһи композиторның вокаль көйләрен яңа «киемнәргә» төрә.

Без Ренат Еникигә тагын бер гаять зур хезмәте өчен рәхмәтле. Ул Сәйдәшнең чәчелеп яткан әсәрләрен төрле урыннардан, шәхси архивлардан табып, экспертиза ясап, 3 томга туплап нәшер итте. Берничә елга сузылган эшне ул, үз иҗатын читкә куеп, профессиональ яктан камил итеп тәмамлады, назлы, сокландыргыч музыканы туган халкына кайтарды. Сайланма әсәрләр җыентыгын редакцияләүгә вакытын кызганмыйча көч куйды.

Р.Еникиев нәкъ С.Сәйдәшев кебек үк халыкчан, милли композитор, әмма аңа новаторлык та хас. Үз халкының улы, ул милли сәнгатьнең киләчәген рус, Европа вә шәрык мәдәниятен үз эченә алып, татарларга гына хас үзенчәлекләрен дә кертеп үсүен күз алдына китерә иде. Шушы изге максатка ул икеләнүләр, көрәшләр аша, каршылыкларны җиңеп бара белә. Шул авыр тормыш юлында аның янәшәсендә хатыны, күренекле музыка белгече, радиокомитет хезмәткәре Нәркиз Мөштәри булды. Иренең фикердәше, хәтта изге фәрештәсе дә була белгән Нәркиз Җиһанша кызы – аның иҗади процессында актив катнашучы, тәнкыйтьче, архивист та.

Бер очрашуда ул миңа берничә диск бүләк итте. Аңа минем «Татарстан сәнгате һәм мәдәнияте музее» оештыруым турында мәгълүм иде. Шул дисклар аша мин Ренат абыйның яңа «Төрек көйләре» дигән хезмәте турында белеп алдым. Соңрак аның ноталары да нәшер ителде. Бу юлы ул музыка сөючеләрне төрек халыкларның музыкаль сәнгате белән таныштыра. Ренат Еникиев себер, кырым, төрек, румын, әзәрбайҗан, үзбәк, кыргыз, төрекмән, гомуми әйткәндә, кайчандыр Тын океан ярларыннан алып Дунай елгасына кадәр киң мәйданда яшәгән төрки халыкларның көйләренә авторлык транскрипция ясый. Үзе исән чакта шушы күләмле әсәрнең бер өлеше («Кырым татарларының көе», «Ныгытма янында», «Болгар гүзәле», «Чәчәкләр арасында») «Татар музыкаль антологиясе»нә кертелә. Фортепиано өчен язылган пьесаларның көчле, үтемле образлары күпгасырлы төрки музыкаль мәдәнияте интонацияләр белән сугарылган. Р.Еникиевнең шушы әсәрләре балалар музыка-сәнгать мәктәпләре, көллиятләр, музыкаль-педагогик югары белем бирү учреждениеләрнең репертуарларын баетты. Еникиев пьесалары гомуми белем бирү уку мәктәпләрендә дә кулланыла. Аның музыкасы балаларда, яшьләрдә үзенчәлекле халкы өчен горурлык хисләре тәрбияли, укучыларның үзаңнарын күтәрә, шул ук вакытта аңнарына төрле этник төркемнәрнең бер-беренә тиң булуларын исбатлап, үзенең миллилеген, кадерле мәдәниятенең өстенлеген күрсәтә...

90 нчы елларда Татарстанның суверенлыгын расларганда, аның гимнын булдыру өчен республикада мәртәбәле комиссия оештырыла. Аңа шагыйрь Ренат Харис, консерватория профессоры Шамил Монасыйпов, композитор Ренат Еникиев та сайлана. Еникиев дөньядагы күпчелек дәүләтләрнең гимннарын тыңлап, анализлап чыкты. Конкурс йомгаклары буенча, комиссия нигездә ике әсәргә туктала: Р.Яхинның Р.Байтимеров сүзләренә язылган «Туган ягым» дигән романсы һәм халык җыры «Тәфтиләү». Музыкаль яктан гимн аһәңен бирүдә Р.Яхин романсына өстенлек бирелә, мондый нәтиҗә ясауда Р.Еникиев фикере хәлиткеч көч уйный. Шул көннән алып илнең, Җир шарының төрле почмакларында Татарстан гимны яңгырый...

Шул ук җәмгыятьтәге «үзгәртеп кору» елларында профессиональ композиторларга карата кызыксыну кимеде. Сәхнә түренә үзешчән композиторлар, үзешчән шагыйрьләр, үзешчән җырчы һәм музыкантлар бәреп чыкты. Концерт заллары зәвыгы түбән тамашачы белән тулды. Халыкның музыкаль зәвыгы, мәдәни биеклеге түбәнәйде. Сәнгатькә коммерция үтеп керде.

Тискәре күренешне Ренат Еникиев һәм аның дуслары да сизеп алды. Татарстанның беренче президенты М.Шәймиев белән очрашканда, шушы юлдан чыгу өчен Р.Еникиев Казанда саллы музыкаль музей төзү идеясен яңгыратты. Ни кызганыч, тормыш ыгы-зыгысы, төрле каршылыклар аркасында Ренат Әхмәт улының гаять кирәкле, мөһим идеясе тормышка ашмады, ул хыялда тоткан мәдәни оешма ачылмады...

Казанда һәм республикада музыка юнәлешендә берничә музей эшләп килә (Н.Җиһанов музей-фатиры; композитор Р.Кәлимуллин музейлары; «Татарстан сәнгате һәм мәдәнияте»; Җ.Фәйзи мәктәп музее; җырчы Ф.Насретдинов музее; С.Сәйдәшев музее). Казанның Тельман урамында С.Гобәйдуллина заманча музыка үзәге уңышлы эшләп килә.

XX гасырның чын мәгънәсендә классик композиторы, академик музыка тарафдары, татарларның да Рахманиновка, Шопенга тиң булуын раслаучы композитор Ренат Еникиев үзе исән чакта ук дан казанды, сәнгатьтә үз урынын билгеләде, җир куеныннан бәреп чыккан саф чишмә сулары кебек, композитор йөрәгеннән ургылган моң, музыка татарлар һәм башка милләт күңеленә юл тапты. Р.Еникиев әсәрләре югалмас, мәрхәмәтсез вакыт аларны онытмас. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премия лауреаты, Россия һәм Татарстанның атказанган эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, композитор Ренат Еникиев әсәрләре башкарылыр, яңгырар, яңа буын вәкилләренең күңелләрен рухи биеклеккә күтәрер. Р.Еникиев көйләре, җырлары милли аңга һәм җанга мәңгегә сеңеп калды.

С.БӘДРЕТДИНОВА,
Россиянең мактаулы мәгариф хезмәткәре.

Соңгы атналарда Европаның Көнчыгыш белгечләре арасында Зәки Вәлиди әфәнде (Әхмәтзәки Әхмәтша улы Вәлиди (Вәлидев) (1890–1970), башкорт халкының милли азатлык хәрәкәте җитәкчесе, тарихчы, тюрколог) хакында немец телендә язылган бер мәдхия тараттылар. Бу мәдхиядә З.Вәлиди әфәнденең Анкарага булган карага буялган хәрәкәтләрен төрле басмаларда, төрек җәмәгатьчелек фикерен З.Вәлиди әфәндедән читләштерергә мәҗбүр иткән ялгыш бер рәвештә аңлатылган һәм З.Вәлиди гүя фән корбаны кеби күрсәтелгән иде. Бу хакта таратылган кәгазьләр бәхәсләшүгә керешүдән, төрек хәрәкәте мактаулы булса булсын, бөек зарарлы эшләргә үзенә гадәт иткән. Бу әфәнденең тәрҗемәи хәленнән белгәннәремне хакыйкать исеменә ачып бирүне милли бурычым дип саныйм.

Гаяз ИСХАКЫЙ:

Зәки Вәлиди

●Зәки Вәлиди.

Зәки Вәлиди әфәндене мин егерме елдан бирле таныймын. Беренче тапкыр 1913 елның май аенда Казанда очраттым. Ул вакыт З.Вәлиди әфәнде дини мәдрәсәләрнең берсендә шәкерт иде. Һәм дә түбән сыйныфларда мөгаллим иде, үзе рус теленнән уку белән мәшгуль иде (З.Вәлиди 1908 елдан Казанда «Касыймия» мәдрәсәсендә укый башлый. Шул вакытларда «Рус булмаганнар өчен рус теле мөгаллимнәре әзерләү мәктәбе» укытучысы Емельяновтан рус тарихы һәм әдәбияты буенча дәресләр ала). Ул дәвергә кадәр үзенең «Төрек-татар тарихы» исемендәге китабын (Г. Исхакый бу урында З.Вәлидинең Казанда 1911 елда басылган «Төрек һәм татар тарихы» дигән китабын искә ала) нәшер иткәндә, бу бер яшь егеткә ярдәм итүне милли бурычым дип санадым. Һәм мин дә болар арасында булдым. Бу вакытларда З.Вәлиди әфәнденең мөгаллиме, хәзерге көндә Анкара хокук китапханәсе мөдире Фуад бәк Туктар иде (Фуад Фәссах улы Туктаров (1880 –1938) 1925 елда Төркиянең мәгариф министры димләве белән Төркиягә килә. Шул ук елда хөкүмәт китапханәсенә мөдир итеп билгеләнә. 30 нчы еллар башында ул хокук мәктәбе китапханәсе мөдире вазифасын башкара. Әдип-публицист соңгысын искә ала). Мәдхиядә күрсәтелгән кебек, З.Вәлиди рус дәресләре мөгаллимлеккә имтихан биргән ул вакытлар һичкемгә мәгълүм түгел иде. Казан университетында укуын дәвам иткәне һәм дәвам итмәгәне һәркемгә мәгълүмдер. Чөнки университетны дәвам итәр өчен Россиядә бакалаверия имтиханы тиештер һәм мәдрәсә шәкерте өчен моны эшләү имтихан тышында. Мәдхиядә З.Вәлиди әфәнденең Казан тарих тикшерү җәмгыяте тарафыннан кулъязмаларны өйрәнер өчен Фирганәгә җибәрелүе язылмый (З.Вәлиди 1913 елның көз айларыннан 1914 елның март аена кадәр Фирганә, Сәмәрканд һәм Бохара өлкәләрендә кулъязма китаплар җыю белән шөгыльләнә. Ул бу өлкәләргә Н.Катановның һәм Казан университетының «урындагы төбәк тарихы, археология һәм этнография җәмгыяте» тәкъдиме белән җибәрелә). Бу тулысы белән хакыйкатькә туры килмидер. Төркестанга З.Вәлиди әфәндегә күндерелгән, 1913 ел баш мөхәррирлегем алдында Петербургта нәшер ителгән «Ил» газитәсе булды (Г.Исхакый мөхәррирлегендә басылган «Ил» газетасы 1913 елның 22 октябреннән – С.-Петербургта, 1914 елның ноябреннән 1915 елның мартына кадәр Мәскәүдә 89 саны басыла. З.Вәлиди «Ил» газетасында Төркестандагы сәфәре турында мәкалә бастыра). Һәм бу сәяхәт газитәбезнең Төркестанда таралуы вә Төркестанда мөхәрриребезне күбәйтү өчен эшләнгән бер чара иде. Абунә акчалары алына, абунә дәфтәрләре бирелгән, шуннан [җибәрелгән] хатларны З.Вәлиди әфәндеңң үзенә мин җибәрдем. З.Вәлиди әфәнде Төркестаннан берничә мәкалә язды («Ил» газетасында 1913 елның декабреннән башлап 1914 елның март-апрель аена кадәр З.Вәлидинең «З.Вәлиди», «Әхмәдзәки», «Ә.Зәки» имзалары белән «Төркестан мәктүпләре» дигән язмасы басыла. Г. Исхакый шул язманы истә тота), вә [шул] рәвештә гәзитәгә абунә җыюны тапшырды, акчалары хисапланды. Петербургка килгәннән соң эшләячәген белдерде. Соңрак Төркестанның төрле шәһәрләреннән минем шәхси карарым белән З.Вәлиди әфәндедән шикаятьле хатлар килми башлады. Хатларның эчтәлеге түбәндәгечә: З.Вәлиди әфәнде үзен «Ил» гәзитәсенең хәбәрчесе дип таныштыра, һәм без дә аны гәзитәгә хөрмәт ягыннан карый дип кабул иттек. Ул иске кулъязма китапларының юкка чыгуын сөйләде. «Шәһәрдәге фәлән әфәнде, фәлән әфәнденең хосусый китапханәләренә кердек, кулъязмаларны күрсәттек». Берничә көннән соңрак З.Вәлиди әфәнде, җирле полиция чиновниклары белән шул китапханәләргә килеп, яманлык эшләде, кыйммәтле кулъязмалар полиция тарафыннан тартып алынды… Исән калганнары, мондагы җирле халыкның дошманнары, югарыда телгә алынган миссионер Остроумов (Николай Петрович Остроумов (1844 –1930), шәргыятьче галим, тарихчы) һәм аның шәкертләре З.Вәлиди әфәндеңң кем булуын белми. «Ил» гәзитәсенең [хәбәрчесе] булганнан гәзитә кирәк сыйфаты хакын карар өчен, бу әфәнденең безнең каләмдәшебез булмавын тиз белдермәүләрен соравын үтенүебезне үрнәк итеп, З.Вәлиди әфәндегә тагын хат язып, мәшәкатьләрне сөйләдек һәм, киләчәктә шулай бер хәрәкәт эшлисе булса, бөек хата ясаячагын аңламаганын, моннан соң бу юлда хәрәкәт эшләмәсә (читләштерергә) ният иттек. Фәкать моннан соң килгән шикаятьләрдә аркасы тапшырган иде. Без бу авыр вәзгыятьтән нәрсә чыгачагыбызга төшенгәнемне аңладым. Оренбург шәһәренә уңышлы сәяхәтендә булынган, гәзитәбезнең хәбәрчеләреннән Шакир әфәнде Мөхәммәдъяр (Шакир Зариф улы Мөхәммәдъяров (1883 –1967), сәясәт эшлеклесе, хокук белгече, педагог) Петербургка килде вә Оренбургта нәшер ителгән «Вакыт» гәзитәсенең баш мөхәррире Фатих әфәнде Кәримидән (Фатих (Мөхәммәтфатих) Гыйльман улы Кәрими (1870 –1937), язучы, нашир, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. 1906 –1918 елларда Оренбургта басылган «Вакыт» газетасының баш мөхәррире) минем исемгә язылган бер хат китерде. Һәм хатта шул сүзләр өстәлгән иде. «Вакыт» гәзитә идарәсенә З.Вәлиди әфәнденең «Ил» гәзитәсе хәбәрчесе сыйфаты белән Төркестанга сәяхәте вакытында хосусый буларак [эш итеп] китапханәләрдән полиция арадашлыгы ярдәмендә кулъязма кәгазь тупланмасында шикаятьләр белән тулы. Мин бу хатларны үз күзләрем белән күрдем. Гәзитәбез исеме өчен оят булды. Фатих әфәнде Кәрими бу шикаятьләрне гәзитәбездә нәшер итсәк, гәзитәләр арасында көндәшлектән хөкем бер аңлашу булмавы шиксездер. Моның эшләгәннәрен мөмкин саналган [гамәл] түгелдер. Моның өчен үзегез катгый чаралар алыгыз, бу иптәш [юлдаш] түгел дип игълан итегез. Кәримигә чакыру җибәрегез. Юкса без дәвамчыларның мәҗбүриятендә калачак», – дигән. Шул көн З.Вәлиди әфәнде телдә безгә хат язган, вә Фатих әфәнде Кәрими хыялларына да чара алганын белдердек. Берникадәр вакыттан соңрак Зәки Вәлиди әфәндедән гаять юкка чыгу [өчен] «сартларны» (төркестанлыларга руслар биргән исем) хурлаган һәм безгә көферләр яздырган хатны алдык вә моның белән мөнәсәбәтебез киселде. Петербургка килгәннән соңрак, янә безгә эш бирде, ни абунә акчаларын [бирмәде], ни дә үзенең эшләгән эшләрен хакыйкатьтә бәян итмәде. [Ул] рус көнчыгыш белгечләре фикере арасына керер өчен, Төркестаннан полиция куәте белән тупланган кулъязмаларны рус оешмаларына бирде. Бу вакыйга З.Вәлиди әфәнденең хөрмәтен Идел буенда тәмам юкка чыгарды, ул да рус көнчыгыш белгечләре белән хезмәттәшлеккә күчте (З.Вәлиди 1910 –1911 елларда университетка ирекле тыңлаучы буларак йөри башлый. Бу елларда ул рус шәрекъ белгечләре Н. Ашмарин, Н. Катанов, В. Богородецкий һ.б. белән якыннан аралаша, алардан шәрекъ фәннәре буенча дәресләр ала). Моны да игътибарга алырга кирәк ки, Россиядә элек Көнчыгыш белгечләренең йөзгә-йөзе христиан миссионерлары – төрек-татар дошманнарыдыр. Моннан соң З.Вәлиди әфәнде өчен Идел буеның милли матбугаты тәмам ябылды. Моннан соң З.Вәлиди әфәнде тормышын анда-монда мөгаллимлек итеп үткәрде (З.Вәлиди 1912 –1915 елларда Казанда «Касыймия» мәдрәсәсендә укыта. Әмма үзенең истәлекләрендә 1909 –1910 елның кышыннан башлап мәдрәсәдә төрек тарихы һәм гарәп әдәбияты тарихыннан укытуы һәм бу вазифаны дүрт ел дәвамында алып баруын искә төшерә. Монда З.Вәлидинең 1913 –1914 уку елында Урта Азиядә фәнни командировкада булуы да керә кебек).

1917 елгы баш күтәрүдән соңрак, Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнарының корылтае тупланды (1917 елның 1–11 май көннәрендә Мәскәү шәһәрендә узган Бөтенроссия мөселманнарының Беренче корылтаенда З.Вәлиди башкорт җирләре һәм этнография мәсьәләләре буенча чыгыш ясый). Бу корылтай үзеннән бер куәтле киңәшмә сайлады, һәм боларның саны утызга җитте. Россия төрек-татарларының милли эшләре, җәмгыять хезмәтчеләре һәрбере дә сайланмады. З.Вәлиди әфәнде үзен сайлатыр өчен күп тырышты. Фәкать җәмәгатьчелек фикеренең үзенә каршы булганы өчен сайлана алмады, вә моннан соң корылтайның төрек берлеге нигезенә корылган карарларына каршы хәрәкәт итә башлады («Хатирәләр» китабыннан күренгәнчә, З.Вәлиди Россиянең федераль дәүләт төзелеше булганда гына төрек-татарның ирекле үсеш алачагына ышана, шул фикерне алга сөрә. Г.Исхакый исә, төрек-татарларның бөтен Россия-

кемдер?

гә таралуын истә тотып, корылтайда киләчәк дәүләт төзелешендә унитаризм принцибын яклый. Ул унитар дәүләт булганда гына гомумтөрки берлеген сакларга мөмкин дип исәпли). Корылтай Бөтенроссия төрек-татарларның берлектә хәрәкәт итәчәген карарга алды һәм бу юлда хәрәкәт итәчәген тыныч юл белән дәвам итте. Шура мәйданга китергән хәлдә, З.Вәлиди төрек кабиләләренең кечкенәләреннән булган башкортларны котырту юлына басты. «Татарлар безне алдый, башкортлар аерым оешма мәйданга китерергә тели» дигән фикерен тарата башлады, һәм үзе, татар кабиләсенә яраклы булганы хәлдә, бабасының башкорт

Истанбул университетында. 1928 ел.

кавемендә затлы нәселдән булуыннан файдаланып, «мин – башкорт, руслар безгә татарлардан күпкә якындыр, без – башкорт милләтчесебез» кебек демагогияләр мәйданга атты. Фәкать Оренбургта тупларга теләгән съездга килгәннәрнең йөзгә туксаны, Мәҗлес вәкилләренең төп максаты булган төрек вәгъдәсенең буталчык икәнен аңлар-аңламас, Мәҗлесне ташлап китте (Оренбург шәһәрендә башкортларның өч корылтае була. Г. Исхакый бу урында беренче корылтайны күз уңында тота. Бу корылтай 1917 елның 20 – 25 июль көннәрендә эшли). З.Вәлиди берникадәр вакыт боргаланып-сыргаланып йөреп ялгыз калды. З.Вәлиди әфәндедең бу хәле бөтен Идел буе төрек-татар галәмендә үзенә каршы бөек бернәрсә тудырды. З.Вәлиди тәмам ялгыз калды. Шул вакытларда Шәриф Манатов исемендәге бер әфәнде Европадан кайтты (башкортларның милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе Шәриф Әхмәт улы Манатов (1887 яки 1892 –1936), Петербургта психоневрология институтында укыганда, Балкан сугышында катнашыр өчен Төркиягә китә. Сугыштан соң Швейцариягә бара. Анда В.Ленин белән очраша. Г.Исхакый бу урында аның Швейцариядән кайтуын искә төшерә). Бу әфәнденең патша хөкүмәтенең шымчысы чагында Петербургта студентлык еллары иде. Фәкать төрек-татар студентлары җәмгыяте, моның шөбһәле кеше икәнен белгән хәлдә, тулаем үзенең арасыннан чыгарган иде. Рус хөкүмәте дөнья сугышы башлар-башламас, Шәриф Манатов, ялган исемгә төрелгән милләтче исеме бирер өчен, Төркиягә китте. Балкан сугышы дәверендә дә бу әфәнде Истанбулда булып, русларга шпионлык иткәне өчен [кулга] алынган булганыннан, Төркия хөкүмәте бу иптәшкә куркынычлы итеп карады, һәм Ш.Манатов Төркиядән чыгарылды. Ул Швейцариядә большевиклар арасына керде. 1917 елда большевик буларак Россиягә кайтты. Фәкать моның тарихы бик яшерен булганы өчен, һичбер ысулдан үзенә урын булмады. Милләтләре тарафыннан нәфрәткә [дучар ителгән] бу ике иптәш: Зәки Вәлиди һәм Шәриф Манатов берләште. Һәм берлектә «башкорт комитеты» дигән бер оешма мәйданга китерде. Вә монда татар-башкорт арасында дошманлык хисе теләгән таратырга вә йә башкортлык хәрәкәтенә большевизм рәвеше бирә башладылар. Большевик фиркасенең [үзәге] Петербургта бөек эшчәнлегендә булганга, аларга совет гаскәре ярдәме белән башкорт матбугаты дөньяга китерә башладылар (башкорт-татар кабиләләре бер уй, бер вакыт бәрабәр яшәде. Карарындагы фирканең, фәкать географик булганы катгый булганы һичбер дәвердә аерым-аерым эшләгәннәре булынмаслардыр. Хәйләкәр башкортларның тавыш-гаугалары һәр ысулында фикер йөртүләрне ике кабиләне аера беләчәк бөек бер гамәл диюгә төшенделәр һәм башкорт телен белмәсләрдер. Фәкать бер төрки телдә китаплар яза белмәктәдер). Россия инкыйлабыннан соң һәр милләт үзенең аерым гаскәри оешмаларын төзи башлаган кебек, Россия татарлары да бу эшкә кул берлекләре башлады. Революциягә кадәр гаскәри хезмәтне ялгыз Идел буе төрек-татары вә Кырым төрекләрен генә мәҗбүр иттеләр, төркестанлы, кавказлы кардәшләребез гаскәри хезмәттән ерак торганлыктан (1916 елга кадәр төркестанлы һәм кавказлылардан рус гаскәрләренә солдатлар алынмаган. Беренче бөтендөнья сугышы барган елларда эшче көчләргә ихтыяҗ туу сәбәпле, 1916 елда, Россия хөкүмәтенең әмере буенча, Урта Азия һәм Кавказ халыклары да патша гаскәренә алына башлый), табигый, бу гаскәри оешмаларның үзәге Казанда урнашкан иде. Анда бу төрек-татар гаскәри оешмасының мәркәзен мәйданга китерү өчен, бу куәтне бөтен төрек илләренең Кавказ, Төркестанда хәл катлаулы булган хәлдә хәрби куәткә рөхсәт бирелмештер. Һәм аның эчендә Кавказ, Төркестан төрекләренә гаскәри ярдәм теләк ителгән иде. Идел буе вә Кырымнан мобилизацияләнгән яшьләр бер мең тугыз йөз егермедән артык булганлыктан, хәли хәзер дә берничә йөз мең төрек-татар гаскәре бар булганы кебек, Алмания, Австрия, Венгриядә әсирләр саны йөз меңнән ким түгелдер. (Алманиянең ялгыз Вюнсдорф төрмәсендә, лагерьларында илле җиде мең татар гаскәре булуы мәгълүмдыр. Беренче бөтендөнья сугышында Германия гаскәрләренә әсир төшкән мөселман һәм татар әсирләренең күпчелеге Вюнсдорф төрмәсе һәм лагерена озатылган. 1931 елда дөнья күргән А.Аршаруни һәм Х. Габидуллинның «Очерки панисламизм и пантюркизма в России» китабында күрсәтелгән мәгълүматка таянып, Вюнсдорф төрмә һәм лагерьларында 40 мең чамасы әсир булганлыгы билгеле. И.Гыйләҗев исә бу санның 100 меңгә җитүен яза). Моның өчен бу төрек-татар гаскәренең милли полклары төрек-татарның хәрби куәт рәвешенә керсә, кирәк Керенский хөкүмәте (Александр Фёдорович Керенский (1881–1970), 1917 елның 8 июлендә Вакытлы хөкүмәтнең рәисе итеп сайлана. Бу вазифаны ул 1917 елның 25 октябрендә (7 ноябрь) башкарган), кирәк большевиклар өчен ясатылган бер хәрәкәт иде. Керенский хөкүмәте бу оешмаларны тыяр өчен күп тырышты, фәкать уңышлы булмады. Большевиклар да, моннан курыкканнары өчен, Зәки Вәлиди, Шәриф Манатовның аерым башкорт полклары ясау фикерен күп уңайлы күрде һәм моңа «башкорт кызыл полкы» исемен бирде (З.Вәлиди истәлекләренә караганда, 1917 елның 2 ноябрендә Башкортстан автономиясе игълан ителә һәм милли гаскәрен төзү эшенә керешә. Бу эш З.Вәлидигә йөкләнә, ул яңа төзелә башлаган гаскәрнең беренче министры да була. Г.Исхакый бу урында шул башкорт гаскәрен истә тота кебек), һәм гаскәриләр арасында большевиклык пропагандасы ясый башлады, һәм бер аерымрак хәрәкәтнең оппозицияләренә каршы тырышлык күрсәтергә тотынды.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 13 том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2013. 244 б.

(Дәвамы киләсе санда).

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

11 июнь (шимбә). ***Зөлкагдә аеның 12нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,16.20 сәгатьтә калка, 1.35 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.28 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Лимон – бавырга шифа

Бавыр авыруларын булдырмас өчен, халык медицинасында бик яхшы чара бар: 2 аш кашыгы атланмай, 1 әр аш кашыгы сары һәм яшел лимон согы, 1 бөлем изгән сарымсак, 250 мл кайнар суны кушып, яхшылап болгаталар да, ач карынга эчәләр. Яки урталай кискән 1 лимон өстенә 1 стакан кайнар су салып, төн буе тоталар, иртән ач карынга шуны әз-әзләп эчеп бетерәләр.

12 июнь (якшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 13нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,17.57 сәгатьтә калка, 1.52 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.29 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Тамак авыртканда

1 чәй кашыгы шалфей үләнен 1 стакан кайнар суда пешереп, шуның белән әледәнәле тамакны чайкарга кирәк. Яртышар аш кашыгы ромашка белән шалфейны 2 стакан кайнар суга салып, икенче кәстрүлдәге суга утыртып, 15 минут пешерәләр, сөзеп, көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, өчтән берешәр стакан эчәләр. Калган төнәтмә белән авызны чайкыйлар, борынны юдыралар.

13 июнь (дүшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 14нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 19.36 сәгатьтә калка, 2.18 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.30 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Подаградан – алма согы

Подагра (тоз утыру авыруы) интектергәндә, яңа сыгылган алма согы эчү бик файдалы. Яисә 2 литр суга 3-5 алманы турап, ябык савытта 10 минут пешерәләр, 4 сәгать төнәтәләр һәм көн буе эчеп бетерәләр. Чәйгә алма турап эчү дә яхшы.

14 июнь (сишәмбе). ***Зөлкагдә аеның 15нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 21.09 сәгатьтә калка, 3.02 сәгатьтә бата. 14 сәгать 51 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 17.31 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карама

булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Крыжовник

Крыжовник – тимер һәм бакырга, фосфор тозларына бай диетик җиләк, аны матдәләр алмашы бозылганда, симергәндә куллану файдалы. Ул – үт һәм бөвел кудыргыч чара, шулай ук хроник эч катудан да кулланыла. Җимешләре азканлылыктан, еш кан китүдән һәм тире авыруларыннан дәвалый. Элек Кавказда туберкулез белән чирләүчеләргә крыжовникның пешереп суытылган яфракларын ашатканнар. Җимешләре ашказаны-эчәк тракты авырулары вакытында авыртуны баса. 20 грамм крыжовник җиләген термостагы ярты литр кайнар суда 6 сәгать төнәтәләр, көненә 2 тапкыр яртышар стакан эчәләр, бераз бал кушарга була. Мондый чара куәтле үт кудыру үзлегенә ия.

15 июнь (чәршәмбе). ***Зөлкагдә аеның 16нчы көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Кәкҗәмөгез йолдызлыгында, 22.21 сәгатьтә калка, 4.11 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.32 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Тоз утыруны кисәтү

1 килограмм бәрәңгене яхшылап юып, кабыгы белән вак кына турыйлар, 3 литр кайнар суга салалар һәм сүрән утта 1 сәгать 20 минут пешерәләр. Аннары сөзәләр, көненә 3 тапкыр 1-2 шәр стакан эчәләр. Дәва курсы – 40 көн. Буыннарны болай чистарткан вакытта итле ризыклар ашамаска тырышырга кирәк.

16 июнь (пәнҗешәмбе). ***Зөлкагдә аеның 17 нче көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Кәкҗәмөгез йолдызлыгында,23.07 сәгатьтә калка,5.41 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.33 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

17 июнь (җомга). ***Зөлкагдә аеның 18 нче көне. 18 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Сукояр йолдызлыгында,23.52 сәгатьтә калка, 7.48 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.34 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Каррилы кәбестә

300 г кәбестә, 200 г бәрәңге, 200 г суган, 2-3 аш кашыгы үсемлек мае, ярты аш кашыгы карри порошогы, чирегешәр чәй кашыгы ак әнеч (тмин) һәм төелгән кызыл борыч, 2 канәфер кадагы, дәфнә яфрагы, 50 г томат пастасы, ярты стакан су яки шулпа, тоз кирәк. Башта бөҗралап туралган суганны майда кыздыралар, карри өстәп, 3-4 минут сүрән утта пешерәләр, аннары башка тәмләткечләрне һәм туралган кәбестәне өстәп, 10 минут кайнаталар. Бәрәңгене шакмаклап турап, кушалар, томат пастасы, су яки шулпа салып, сүрән утта әзер булганчы пешерәләр, тәмечә тоз өстиләр. Аннары дәфнә яфрагы һәм канәфер кадагын алырга кирәк.

КОРЪӘН шифасы



Яр Чаллы дәвачысы Нуретдин хәзрәт Мирзаев соңгы елларда Рамазан ае башлануга ай дәвамында бихисап сулы савытларга Корьән догаларын укый. «Бер көн эчендә Корьәндәге алтмыш битне укып чыгам, – ди хәзрәт. – Соңрак бу сулы савытларны шифага мохтаҗларга, авыруларга таратам».

Нуретдин хәзрәт кыска әңгәмәдә үзе хакында болай бәян итте: «Бу савaплы юлга басуыма бик күптән инде... Милләтем буенча мин таҗик. Таҗикстанда үстем. Совет елларында тәрбия алдым, институт тәмамлагач та, 23 яшемнән намаз укый башладым. Ә менә гайре табигый хәлне 22 яшемдә күзәттем. Бер ханым дәвачыга сыерым югалды дип килгәч, ул хәсрәткә баткан ханымга: «Шушы китапның фәлән битен ачып, фәлән юлларны укы әле», – диде. Ханым укыды да: «Аңладым», – дип китеп барды. Сыер табылгач, рәхмәт әйтергә килде: «Сез миңа аның кайда табылачагын әйттегез, рәхмәт сезгә!» – ди. Бу дәвачы исә аңа үтә дә гаҗәпләнеп карады да: «Мин сиңа берни дә әйтмәдем. Сиңа Аллаһы Тәгалә булышлык итте», – дип җаваплады. Миңа кызык булып тоелды. Яшь чакта могҗизаларга тару күңелгә бик тиз кереп кала бит ул.

26 яшемдә мин дә шушындый белемнәргә өйрәнә башладым. Әйтик, теләгән зур булса, гайре табигый сәләт кешегә кучә ала дигән гыйбарә бар. Үзеннән-үзе, имеш... Ул чактагы остазларым мине кешеләргә мәгълүм булмаган ерак бер җирдәге урынга ябып куйдылар. Анда кырык көн буе ач тордым. Ишек аша ипи, су бирсәләр, ашадым, онытсалар, юк. Догаларда булдым. Шул вакытта унсигез килограммга ябыктым. Аннан чыккач, өч көн буе туктый алмыйча диярлек ашадым-эчтем. Әмма бу әле бары физик тән белән бәйле. Мин бит шуннан соң кешеләрне үтәли күрә башладым. Бу беренче мәлләрдә бик куркыныч, моңа тиз генә күнегеп булмый. Күзләр дә моңа тиз генә ияләнми. Шулчак бик курыктым, хәтта еладым да. Укытучыларыма: «Кирәкми икән бу сәләт. Минем гадәти кеше буласым гына килә», – дидем. Ә алар: «Син инде безнең арада. Ә без гел агым суда торабыз. Без шушы судан чыга да алмыйбыз, әмма батмыйбыз да», – дип җавап бирде.

Билгеле, теләсә кем дәвачы була алмый. Бергә укый башлаган утыз ир-ат арасыннан мин берүзем генә укып бетерә алдым. Моннан күп еллар элек Яр Чаллыга килеп төпләндем. «Сөембикә» мәчете каршында авыруларны дәвалау, кешедән җен-шайтаннарны мөселман догалары булышлыгында куып чыгару белән шөгыльләнәм. Мине күпләр белә. Чирлеләр күп килә, аеруча яшьләр еш мөрәҗәгать итә. Дәвачы булу – авыр хезмәт. Чөнки кеше эчендә утыручы шайтан бик көчле булган очраклар да бар. Ә аның кешегә үтеп керүе күп очракта шул кешенең гамәлләре белән дә бәйле. Корьәннең «Әз-Зухруф» сүрәсенең 36 нчы аятендә болай диелгән: «Шәфкатьлене искә алудан читкә тайпылучыга шайтанны билгеләп куярбыз һәм ул аңа иптәш булыр». Кеше эчендәге шайтан гаять көчле икән, андый бәндәгә тиз генә булышлык итеп булмый. Мәсәлән, үзмнең практикада мондый дүрт очрак бар. Алар хәзер дә, вакыт-вакыт, миңа дәваланырга килеп йөри, кешеләрдән җен-шайтанны куып чыгарганда «Җен» сүрәсе аятьләрен, «Бәкара» сүрәсен укырга кирәк. Ә гомумән, Иранда дәвачылык дәресләре алганда, остазларыбыз безгә: «20 мең тапкыр «Җен» сүрәсен һәм дә 15 мең тапкыр «Бәкара» сүрәсен укырга кирәк», – дигән иде.

Мондый дәвалауга өйрәнергә теләүчеләр якын-тирәмдә юк, чөнки бу хезмәткә алынырга куркалар. Ә менә Корьәнне дөрес итеп укырга теләүче укучыларым хәттин. Дәвалау һәркемнән рухи ныклык белән берлә батыр йөрәкле булуны да таләп итә. Шуңа күрә бу юлны сайласаң, бик авыр булачагына төшенүчеләр моңа алынмый.

Мин гозер белән килгән кешенең иң әүвәл күзләренә карыйм. Нинди авыру белән чирләүләрен күзләренә карап күрәм. Күзләрдә бары да язылган. Аларны юкка гына күңел көзгесе дип атамыйлар. Бу чыннан да шулай».

Нуретдин хәзрәт Мирзаев әлегә хаҗ кылырга бармаган. «Чөнки минем якыннарым арасында бернечә үтә мохтаҗ кеше бар, мин аларга булышлык итәм. Әлегә хаҗ кылып кайту өчен дип акча җыймыйм», – ди ул.

Аңа да үз язмышларын яисә илдәге, җәмгыятьтәге вәзгыятьнең ничек дәвам итәчәген алдан белешергә теләүчеләр мөрәҗәгать итми калмый. Әмма ул, мөселман динендә, ислам кануннарында буларак, мондый гамәлләр белән шөгыльләнми. «Ил яисә кеше язмышлары бары тик Аллаһы Тәгалә кодрәтендә!» – ди әңгәмәдәшем.

Нуретдин хәзрәт бу араларда догалар укылган шифалы суларны таратып та бетергән. Бүгенге көндә аңа төрле шәһәрләрдән киләләр. «Ватсап аша Бөекбритания, Германия кешеләре дә мөрәҗәгать итә. Аларга да Корьән догаларын укыйм. Шифасын тоялар. Әмма мин бу шифа өчен бары бер сәбәпче генә. Кешеләр Аллаһы Тәгалә сүрәләрен, аятьләрен ишетеп савыга», – дип йомгаклады сүзен Яр Чаллы дәвачысы.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

10 июнь – «Сәфәр» (А.Шакиров).
11 июнь – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
12 июнь – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
14 июнь – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
15 июнь – Ф.Г.Волков исемендәге драма театрының «Калина красная» спектакле (В.Шукшин).
16 июнь – Ф.Г.Волков исемендәге драма театрының «...Забыть Герострата» спектакле (Г.Горин).
17 июнь – Ф.Г.Волков исемендәге драма театрының «Неаполитанские каникулы» спектакле (Э.Скарпетта).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

10 июнь – «Трубадур» (Дж.Верди).
13,14 июнь – Казан хореография училищесының чыгарылыш курс шәкертләре концерты.
17 июнь – «Кармен» (Ж.Бизе).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

10 июнь – «Полиционер» (И.Зәйниев).
13 июнь – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).
14 июнь – «Акча бездә бер букча» (З.Хәким).
15 июнь – «Төш» (Т.Миңнуллин).
16 июнь – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

15,16 июнь – Премьера – «Йосыф» (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» һәм Корьәннең «Йосыф» дип исемләнгән 12 нче сүрәсенә нигезләнеп куелган).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

10 июнь – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).
11 июнь – 11.00, 13.00, 15.00 – «Сказка о царе Салтане» (А.С.Пушкин). 12.00 – «И, кызык Шүрәле!..» (Г.Зәйнашева).
12 июнь – 10.00 – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина).12.00, 14.00 – «Волк и семеро козлят» (Э.Гыйлемханова инсценировкасы).
13 июнь – 11.00, 13.00 – «Приключения Барона Мюнхгаузена» (Р.Распе). 11.30, 12.30 – «Не хочу, не буду» (П.Геннадьева).
17 июнь – «Әлфия» (И.Зәйниев).

Дин һәм заман таләбе



Күпчелек рухиятне диндарлык дип белә. Әмма бу тар караш – Аллаһыга ышану, Аның берлеген тану һәм гыйбадәт кылу гына иманлы итми. Шулар өстенә, һәм бу иң мөһиме, Аллаһ кануннары буенча яшәү мәслихәт. Моның өчен Коръәндә һ.б. Изге Китапларда бирелгән дини тәгълиматны заманча аңлау зарур. Дөрес, шәригать законнарына нигезләнгән дини йолалар Коръән аятьләренең хикмәтле мәгънәләрен аңламыйча да дөрес яшәү мөмкинлеге бирә сыман. Әмма шәригатьтә дә байтак батыйл (рух төшенчәсенә ят) гадәтләр кертелгән. Шулар арасында милли күптөрлелекне инкяр итү, гармонияне бозучы газават, «исраф әл-харам» мәсләгенә туры килмәүче «батырлык»ны (камикадзеләрне) аклау (батырларча көрәшәсе урынга «батыр»ларча үлүне яклау) кебек традицияләрне атарга була.

Мөселман руханиларының вәгазь вә гамәлләреннән күренгәнчә, Ислам цивилизациясе бердәмлегенең асылын алар үзләре дә аңлап җиткерми. Аңларга вакыт инде безгә: Мөхәммәд (с.г.в.) өммәте бердәмлеге, наданнар уйлаганча, бер төрле (гарәпчә исәнләшүдә («исәнмесез» урынына «әссаләмӨгаләйкүм» дип), дини аңда изгеләштерелгән халыкларча (гарәпләрчә) киенүдә (әйтик, хатын-кызны хиҗап-пәрәнҗәгә төрүдә) һ.б.ш. исламга бернинди кагылышы булмаган бертөрлелектә түгел, ә Рәсүлебез тәгълиматы тәрбиясендә ирешелгән уртак аңыбыз камиллегендә (киң карашлылык, гаделлек, сабыр-түземлелек, толерантлык, мәрхәмәтлелек, үзара мөнәсәбәтләрдә гармониягә омтылу кебек сыйфатларыбыз бердәйлегендә), иманлылыкта, Аллаһы төшенчәсен һәм шаһәдәтне дөрес аңлауда, күптөрлелекне тануда һәм аны яшәү рәвеше дип кабул итүдә.

Җәмгыяви берлеккә омтылу – Аллаһка тиңдәш эзләү, димәк, мөшриклек; чөнки Ул гына бер һәм Бердәнбер. Цивилизация исә бертөрле түгел, ә бердәм булырга тиеш. Моңа ирешү юлы билгеле: милли үзгәлекләрен саклаучы күптөрле җәмгыяви формалар арасында исламга нигезләнгән гармонияле багланышлар формалаштыру мәслихәт. (Татар исламы менә шундый карашны алга сөрә.)

Без физик дөньяга Аллаһ яралткан Җиһанның күпртөрлелек бердәмлеге икәнен танып белү; Ул бар иткән бөтен формаларның Бер Җан төрләре булганлыгын аңлап, аларның үзара мөнәсәбәтләрендә табигый гармонияне сакларга өйрәнү өчен җибәрелгәнбез. Күптөрлелексез бу тәҗрибәне алып булмый, димәк, иң әүвәл, аны (шул исәптән һәм беренче чиратта, кешелек җәмгыятендә) урнаштыру зарур.

Әйтергә кирәк, бертөрлелек бердәмлеге проблемасы исламга гына хас әйбер түгел, ул башка конфессияләргә дә кагыла. Әмма аны уңай хәл итү мөмкинлеге ахырзаман динендә генә каралган – ягъни бу Мөхәммәд (с.г.в.) өммәтенә тәкъдирләнгән. Ләкин тәкъдири ихтималлык хәзергәчә реальләштерелмәгән. Ни өчен алай икән?

Аңлашыла булса кирәк, моңа җавап тапмый торып, исламны реформалау турында сүз куерту сафсата сату булып кына калыр. Моңа дәлилләр мөселманнар тарихында бихисап, татарныкында да аз түгел. Куелган сорауга җавап мәсьәләсенә килгәндә, эш болай тора: традицион ислам диннең сәясәткә буйсындырылган шартларда, империячел дәүләт ихтыяҗларына яраклаштырылып формалашкан. Шул сәбәпле, аның теологиясе вә фәлсәфәсе шаһәдәтне бер яклы (тәүхиди мәгънәдә генә) аңлату һәм тану гадәте урнашкан. Бу очракта Коръән аятьләрендәге каршылыклы тоелган хәбәрләрне килештерү кыенлашкан. Әйтик, аларда бар нәрсә – Аллаһтан, Аның идарәчелеге мәңгелек икәнлеге турында әйтелә; шул ук вакытта кешегә кайту юлын сайлау ирекe бирелгәнлеге хакында да искәртелә. Чынлап та, шаһәдәтнең иҗтиһади мәгънәсен дә исәпкә алмаган очракта, боларны уртак мантыйкка китерү мөмкин түгел.

Традицион исламда әлеге каршылыкны марксистик рухта хәл иткәннәр: большевиклар шикелле, каршы якларның берсен юк итү (шаһәдәтнең иҗтиһади мәгънәсен танымау) юлына басканнар. Мәгәр бу очракта кеше ирегенә бәйле мәсьәләләрне дә кире кагарга туры килгән. Хәер, бу беркемдә дә борчылу тудырмагандыр, чөнки шаһәдәтнең тәүхиди мәгънәсен мотлаклаштыру, адәми күзлектән, ислам көчләп тагылган җәмгыять ихтыяҗына бик тәңгәл килә сыман: хөкемдар да моңа риза – бу дәүләт башлыгының абруен ныгыта, гавам да каршы түгел – аның ата-бабадан килгән гадәти (мәҗүсиләрчә) инануы да шундый иде. Менә шулай, башта шаһәдәтне тәфсирләүдә батыйл караш урнашкан һәм бу дөньяны мәҗүсиләрчә (галәмне Аллаһның тәне яки гәүдәләнгән алла дип) күзаллау мөмкинлеге калдырган; аннан, шуңа бәйле рәвештә, күп кенә башка: әйтик, реинкарнация, ират һәм хатын-кыз мөнәсәбәтләре, милли үзгәлекләрне инкяр итү, иҗтиһат капкасын ябу, толерантлыкны тыю кебек мәсьәләләрдә һ.б.ш. юнәлешләрдә дә мәҗүсиләр карашы рәсми төс алган – исламда мөшриклек урнашкан.

Биредә адәми зат яшәеше өчен ифрат мөһим булган бернәрсәне искәртү зарур (аны белмәү шаһәдәтне дөрес аңлауга да комачаулый). Сүз тәкъдир вә язмыш нисбәтләре турында бара: тәкъдирдә каралганнар котылгысыз рәвештә язмышта реальләшәме? Гадирәк итеп әйтсәк, язмыштан узмыш мөмкинме? Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, андый ихтималлык бар, әмма бер цикл кысаларында гына. Тәкъдирнең котылгысызлыгы һәм шул ук вакытта аны реальләштерү өчен бирелгән ирек (ягъни тәкъдирнең котылгысыз булмавы) каршылыгы болай хәл ителә: цикл дәвамында тәкъдир потенциальлек рәвешендә тәгаенләнә һәм аны реальләштерүдә Кеше акылына (ирекккә) өстенлек бирелә; цикллар алмашынуы һәм алардагы яңа шартларны билгеләү Аллаһның Үз кодрәтендә калдырылган, ягъни боларын Ул Үзе (котылгысыз рәвештә) гамәлгә куя. Кыскасы, адәми зат яшәешендә объективлык вә субъективлык нисбәте менә шушындый тәртиптә тәгаенләнгән.

Татар исламы да шаһәдәттә каралган объективлык һәм субъективлык нисбәтенә нигезләнә (алар мөнәсәбәтендәгечә гамәлләтә). Бу илаһи цикллар алмашынуына – ахырзаман чорына керүебезгә бәйле. Әлбәттә, Аллаһ тарафыннан анда кешелек язмышы нинди булырга тиешлеге алдан тәкъдирләнгән, тик ихтималлык рәвешендә генә. Аны реальләштерү юлы Коръәндә күрсәтелгән. Әмма аятьләрнең мәгънәсен аңлау вә тәфсирләү традициясе иске циклда (борылыш, ягъни мөшриклек чорында) формалашканлыктан, исламдагы байтак караш вә гадәтләр яңа шартларга туры килми. Димәк, адәми затның, Коръәндә күрсәтелгән кайту маршрутын искечә күзаллап, тугры юлдан тайпылу куркынычы реаль төс ала. Бу очракта субъектив сәбәпләр аркасында ахырзаман өчен тәгаенләнгән тәкъдир гамәлгә ашырылмый калырга да мөмкин. Бу инсаниятнең һәлакәте булыр иде. Шөкер, Аллаһ гадел вә мәрхәмәтле – Ул, кешелекнең ахырзаманга күчеше вакытында Коръәнне заманча аңлап вә кулланып, аның хәзерге эволюцион үсеше өчен ләүхелмәхфүздә язылган тәкъдирен реальләштерүче көч итеп татарны билгеләгән.

Гамәли яктан, татар исламының ничек тормышка ашырылуын күзалларга теләсәк, анысы да шаһәдәттә каралганча булыр (тәкъдири объективлык вә адәми субъективлык каршылыгы кысаларында барыр), дип фаразлый алабыз. (Чөнки бу ислам тарихында цикллар алмашынуы лабаса!) Башта, бала эмбрионы, ана карынында барлыкка килеп, аның бер «әгъза»сы буларак кына үсеп, туууга әзерләнгән кебек, татар исламы да традицион ислам эчендә гомум мөселман дөньясының бер кисәге рәвешендә яшәгән. XIX гасыр азагында – XX йөз башында туачак татар исламының эмбрионын җәдитчелек дип атаганнар. Совет чорында иблиси затлар большевиклар кулы белән исламга «аборт» ясап, аны «төшертмәкче» булганнар. Мәгәр Аллаһ аңа өметле киләчәк тәкъдирләгән, ә халкыбызның иманлылыгы белән әлеге тәкъдир реальләшкән – ул сакланган һәм, хәтта, камилләшә төшкән.

(Дәвамы киләсе санда).

Рашат САФИН
«Татар инануы»
китабыннан.

Тукай бүләге уйланырга мәҗбүр итә

Быел Тукай бүләгенә тәкъдим ителгән кандидатлар исемлегендә башка елларга караганда да сәерлекләр күренде. Бу исемгә тәкъдим ителгән 19 кандидат арасында, кайберләренең кем икәнен дә белмәгән, исемнәре җәмәгатьчелеккә таныш булмаган фамилияләләрнең артып торуы күзгә ташланды. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турындагы республика Президенты указында: «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге җәмгыять тарафыннан киң танылган, илебез мәдәниятен һәм милли мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертkән, югары профессиональ осталыгы белән аерылып торган, үзенчәлекле автор стиленә ия булган аеруча күренекле әдәбият һәм сәнгать әсәрләре, шулай ук сәнгать һәм әдәбият белеме өлкәләренә караган күренекле фәнни тикшеренүләр өчен бирелә», – дип язылган. Татарстан Язучылар берлегеннән тәкъдим ителгән 6 әдипнең исеме арасында Фәүзия Бәйрәмова булуга карамастан, аның кандидатлыкка үткәрелмәвен күңел кабул итә алмый. Тукай бүләгенә генә түгел, Нобель бүләгенә лаек булырдай шәхес бит ул Фәүзия ханым. Дөрес, ул ялагайланып түгел, ничек бар шулай яза. Бу бит аның минусы түгел, плюсы булырга лаеклы икәнен күрсәтә югыйсә. Шундый да курку белмәс, белемле, батыр йөрәкле, булдыклы милләттәшебезнең булуы белән горурланып яшисе урында, аның кыерсытылып, җәзаланып гомер кичерүен кабул итеп булмый, әлбәттә.

Бу бүләккә лаек булучыларның җәмгыять тарафыннан «танылган»лыгы мөһим икәнлеге турында әйтелсә дә, күрсәтелгән кайбер фамилиядәге кандидатларны белү түгел, аларның исемнәрен ишеткән кеше булды микән? Аларның кем тарафыннан тәкъдим ителүләре турында да бер сүз әйтелмәде.

Олпат язучыларыбыз Айдар Хәлим белән Фәүзия ханымның бу дәрәҗәле исемгә күп еллардан бирле тәкъдим ителүләренә карамастан, шушы көнгә кадәр аларга бу бүләкнең бирелмәве, әлбәттә, җәмәгатьчелекне канәгатьләндерми.

Советлар заманыннан гына башлап карасак та, талантлы, булдыклы, үз фикерен курыкмыйча әйтә алган күп санлы интеллигенция вәкилләренең юкка чыгарылуын һәм кайберләренең чит илләргә китеп кенә котылып калуын тарих белә. Илдән китәргә мәҗбүр ителгән шәхесләрнең хәзерге вакытта да булуын күреп торабыз. Үз вакыты белән андый шәхесләрнең исемнәре кайтарыла һәм аларга карата уңай караш тудырыла. Тарих моңа да шаһит.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.
Казан.

13 айда – дүрт бала

Америкада 45 яшьлек Трейси исемле хатын-кыз 13 айда дүрт бәбиле булып куя. Ун яшьлек улы энекәш яки сеңелкәш турында хыялланууын әйткәч, Трейси суррогат ана хезмәтеннән файдаланырга карар кыла, әмма килешү имзаланган көндә үзенең дә йөкле булуы ачыклана. Суррогат ана аңа Пайпер һәм Пресли исемле игезәк кызларын табып бирә, үзе тудырганына исә Харлоу дип исем кушалар. Шул ук елны Трейси кабат йөккә уза. Аның төпчек улы 29 атнадан җитлекмичә туа, әмма сау-сәламәт була һәм тиз арада яшьтәшләрен куып тота. Хәзер Трейси яшүсмер улы һәм дүрт бәләкәй сабые белән Нью-Йорк үзәгендәге фатирда яши һәм һәр көнен шундый искиткеч бүләге өчен Ходайга рәхмәт укудан башлый.

(“The Sun”).

Файдалы ризык

Күп кеше хайванның эч-карынын өнәп бетерми һәм ялгыша. Аларда организм өчен файдалы гына түгел, хәтта зарур матдәләр гаять күп. Кайберәүләр эч-карынны иң югары сортлы билдәмәдән дә файдалырак дип саный. Һәм галимнәрнең тикшеренүе моны раслаган да. Нью-Йорк университеты Медицина үзәге тикшеренүчеләре йорт кошларының бавыр һәм йөрәге түш итеннән күпкә файдалырак булуын дәлилләгән. Эш шунда: эч-карында таурин күп, нәкъ менә ул хәтта канында холестерин микъдары югары булган кешенең дә йөрәгендә ишемия авыруы башлану куркынычын 60 процентка киметергә сәләтле. Таурин икенче типтагы шикәр чире, югары кан басымыннан да саклый. Эч-карында A, E, B төркеме витаминнары, калий, магний, тимер, бакыр, цинк, фосфор кебек микроэлементлар да гаять күп. Мәсәлән, бавырдагы тимер яшелчәдәге тимергә караганда күпкә тизрәк үзләштерелә. Тагын шунысы да игътибарга лаек – хайван һәм кош йөрәк-бавырында калория бик аз.

(“МедНовости.ру”).

Балык аша, җәяү йөр!

D витаминлы препаратлар чынлыкта өлкәннәрнең сөяк һәм мускулларына берничек тә тәэсир итми икән. Окленд һәм Абердин университетлары галимнәре шундый нәтиҗәгә килгән. Алар әйтүенчә, сәламәт кешегә мондый биологик актив өстәмәләр кабул итүнең кирәге юк. Организм D витаминын үзе җитештерә. Витаминлы препаратлар эчкәнче, көн саен 1-2 сәгать саф һавада йөрүең күпкә файдалырак. Анализлар организмда D витамины кытлыгын күрсәтсә генә, махсус препаратлар белән дәвалану таләп ителә. Соңгы клиник тикшеренүләр бу витаминны биологик өстәмә буларак эчүнең йөрәк авыруларына да, онкологик чирләргә дә бернинди тәэсир ясамавын күрсәткән. Байтак кеше D витаминын кышын куллана башлый. Белгечләр исә, синтетик препаратлар кабул иткәнче, майлы балык, сөт, йомырка сарысын күбрәк ашарга куша.

(“ABC News”).

Замана коллары

Бөтен дөньяны яулап алган Apple компаниясенең үз айфоннарын ничек ясавын тикшерә башласаң, моның бик куркыныч һәм зыянлы җитештерү булуы ачыклана. Җиһандагы иң модалы кешеләр кулына барып эләккәнче, телефон бик озын юл үтә. Аның өчен көмешне Apple Боливиядән сатып ала. Көмеш рудниклары Серро Рико тавында урнашкан, аны тагын “кеше ашый торган тау” дип тә йөртәләр. Уналтынчы гасыр уртасыннан бирле Серро Рикода 8 миллионнан артыграк эшченең гомере өзелгән. Хәзер инде тауда казылмалар беткән диярлек, тик җирле сәрхушләр, үзләренә спирт сатып алыр өчен, һаман эзләнә әле. Айфондагы литий батареяләре өчен кобальт Конгодан кайтартыла, аны табучы җирле халык көненә 2-3 долларга, аена 80 долларга бил бөгә. Кобальт чыгаручылар өнгә охшаган базларны күгәргән көрәк белән казый – башка кораллары юк. Африка авылларында мәктәпләр күп түгел, шунлыктан балалар өлкәннәр белән бертигез эшли. ЮНИСЕФ мәгълүматлары буенча, мондый рудникларда 40 меңләп бала хезмәте кулланыла. Кытайдагы айфон җыела торган заводларда да хезмәт шартлары искиткеч авыр, анда бик аз эш хакы түләнә. Дөньядагы иң кәттә, иң кыйбатлы телефон компания хуҗаларына гына гаять зур табыш китерә, ә гади хезмәткәрләр тиеннәр хакына тир түгә.

(“The Local”).

Кигисез тәгәрмәч

Биеклеге 145 метрлы, дөньяда беренче кигисез күзәтү тәгәрмәчен инженерлык могҗизасы дип атыйлар. Әлеге футуристик корылма Кытайның көнчыгышындагы Вэйфан шәһәрендә Байланг елгасы аша салынган 540 метрлы күпердә урнаштырылган. Ул җиһанда иң зур тәгәрмәч тә: диаметры 125 метрга тәңгәл. Тәгәрмәчтә һәркайсы унар кеше сыйдырышлы 36 кабина бар. Аттракцион 28 минутта тулы әйләнеш ясый, туристларга әйләнә-тирәне фотога төшерергә бу вакыт рәхәтләнеп җитә. Интернет та бар, фотоларны шундук социаль челтәрләргә куеп була. Тәгәрмәче төзүгә 4,6 тонна корыч киткән. Архитекторлар әйтүенчә, кабиналар тирәсендә үрелеп, корыч конструкцияләр “аждаһа умырткасы” формалаштыра, бу кигиләрсез һәм колонналарсыз дизайн тәгәрмәчнең үзәген тулысынча бушата. Вэйфан – Кытайдагы экологик яктан иң чиста шәһәрләрдән берсе, анда территориянең 40 проценты яшеллеккә күмелгән. Әлеге кала “очыргычлар шәһәре” буларак та дан казанган – аларны биредә җитештереп кенә калмыйлар, бәлки ел саен тематик фестивальләр дә үткәрәләр. Яңа уникаль аттракцион Вэйфанны туристларны иң кызыктыра торган урынга әйләндергән.

(“Синьхуа”).

Сәбәбе – эшеңне яратуда...

Быел апрель аенда Британиянең Ист-Райдинг-оф-Йоркшир графлыгындагы Кингстон-апон-Халл шәһәре картлар йортында Роуз Фезерстоун үзенең йөз яшьлеген бәйрәм иткән һәм шундый озын гомеренең сере нидә булуын ачкан – яраткан эшендә һәм актив яшәү рәвешендә икән. Сугыш вакытында ул автобуста кондуктор булып эшләгән, аннары бәби тудыру йортында һәм British Aerospace аэрокосмик компаниясендә хезмәт куйган. Буш вакытында ире белән мотоциклда җилдерергә һәм бәйләргә яраткан. “Минем киңәшем шул – күп эшләгез һәм һичкайчан биреşмәгез. Әмма моннан ләззәт алырга кирәк. Һәм беркайчан да бәхәсләшмәскә тырышыгыз”, – дигән Роуз. Бит өчен яхшы кремга акча кызганмаска һәм юмор хисен җуймаска да өндәгән. Королева Елизавета II Фезерстоунны юбилее белән котлап тәбрикнамә җибәргән, картлар йорты исә аның бөтен туганнары һәм дусларын мәҗлескә җыйган.

(“Hull Live”).

Ә бәлки тыныч холыктадыр...

Шулай ук күптән түгел 101 яшьлеген бәйрәм иткән Дензил Купер исә озын гомерле булу дөрес туклануга бөтенләй бәйле түгел, дип саный. Ул беркайчан да тартмаган-эчмәгән, әмма яшелчәне аз кулланган, диетологлар зыянлыга санаган ризыкларны яраткан һәм гомере буе бөтен теләгән нигъмәтен ашап яшәгән. Озак яшәвенең серен ул үзенең бик тыныч холыклы булуыннан һәм борчу-кайгыларга артык хәсрәтләнмәвеннән дә күрә – стресска ничек тә бирешмәскә тырышу мөһим икән. Дензил Бөекбританиянең Эссекс графлыгында 1921 елның 8 апрелендә туган. Икенче бөтендөнья сугышында катнашкан. Аннары өйләнгән, өч кызы туган. Хәзер аның тугыз оныгы, 15 оныгының баласы бар. Купер Бирмингемдагы Bishops картлар йортында яши, хәзер дә җырларга-биергә ярата. Туган көнендә зур торт пешереп, ветеранның бөтен якыннарын җыеп сыйлаганнар.

(“Metro”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

13 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
6.30 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.30 «Өметеңне өзмә». Рифат Зарипов концерты. 6+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
10.00, 23.30 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.30 «Җиде малай». Фирдүс Тямаев концерты. 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Танцы народов мира». 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Реальная экономика». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.35 «Шаян хәлләр». 12+
6.00 «Җанымда яз булып кал әле». Эльмира Җәлилованың иҗат кичәсе. 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00 «Ватандашлар». 6+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Мирсәй Әмир турында телеочерк. 6+
13.00 «80 яшьлек егет». Наил Дунаевның юбилей кичәсе. 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «СВОИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
10.30, 21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «КУРОРТНЫЙ РОМАН». 16+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Не женское дело». 12+
15.00 «Непростые вещи». 12+
15.30 «Пчелка Майя: Медовый движ». 18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
23.00 «СВОИ-2». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
6.10 «Россия от края до края». 12+
6.35 «ТОТ, КТО ЧИТАЕТ МЫСЛИ» («МЕНТАЛИСТ»). 16+
8.20 «ПОЛОСАТЫЙ РЕЙС». 12+
10.15 «Как развести Джонни Деппа». 16+
11.20, 12.15, 15.15, 18.20 «ЗНАХАРЬ». 16+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.55 «Леонид Кравчук. Повесть о щиром коммунисте». 16+

«РОССИЯ»

5.35 «ЛЮБОВЬ НЕЖДАННАЯ НАГРЯНЕТ». 12+
9.20 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 15.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.05, 15.15 «ЛИКВИДАЦИЯ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
21.05 Вести. Местное время.
21.20 «НЕБО». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Мультфильмы.
8.00 «ДОБРО ПОЖАЛОВАТЬ, ИЛИ ПОСТОРОННИМ ВХОД ВОСПРЕЩЕН».
9.10 «Обыкновенный концерт».
9.40 Исторические курорты России. «Сестрорецк».
10.10 «Я ШАГАЮ ПО МОСКВЕ».
11.25 «Я шагаю по Москве». Летний дождь и его последствия».
12.05 Гала-концерт всероссийского фестиваля «Народное искусство детям».
13.10 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.15 «НЕИСПРАВИМЫЙ ЛГУН».
15.30 XIV Международный конкурс артистов балета. Гала-концерт лауреатов.
17.10 «Тихий Дон». Как он был казак, так казаком и останется».
17.50 «ТИХИЙ ДОН».
23.25 «Шаболовка, 37».

«НТВ»

5.30 «Морские дьяволы. Смерч. Стихия героев». 16+
6.10, 8.20, 10.20 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ДАЛЬНИЕ РУБЕЖИ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
13.10 «ПОСЛЕДНИЙ ГЕРОЙ». 16+
15.00, 16.20 «ЧЁРНЫЙ ПЁС». 12+
19.40 «ЧЁРНЫЙ ПЁС-2». 16+
23.40 «Прорыв». Фестиваль экстремальных видов спорта.

Сишәмбе

14 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
6.30, 7.10, 8.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Теймә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Казанның кадерле кичләре». Зөһрә Сәхәбиева концерты. 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Гомәр Бәширов турында телеочерк. 6+
13.00 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
10.30, 21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «КУРОРТНЫЙ РОМАН». 16+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Не женское дело». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Неизвестные сражения Великой Отечественной (Патриот 8)». 12+
16.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗАКЛЮЧЕНИЕ». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.15, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Почему Луна не из чугуна».
8.20, 15.50 «ЦЫГАН».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 XX век. «Мастера искусств. Юрий Соломин. Народный артист СССР».
12.20 «Забытое ремесло».
12.35, 21.40 «МОЯ СУДЬБА».
13.50 75 лет Алексею Погребному. Острова.
14.30 «Три «О» Ивана Гончарова».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Передвижники. Илья Репин».
17.35 Мастера скрипичного искусства. Гидон Кремер.
18.35 «Древние небеса».
19.45 Главная роль.
20.05 «Я шагаю по Москве». Летний дождь и его последствия».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Искусственный отбор.
22.50 Цвет времени. Карандаш.
23.00 «Запечатленное время».

«НТВ»

5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.05 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АКУЛА». 16+
23.25 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

15 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
6.30, 7.10, 8.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктә йөрткән сүзләр». Резидә Шәрәфиеваның юбилей концерты. 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Җир белән күк очрашканда». Зөлфирә Зарипова турында телеочерк. 6+
13.00 «Җаным җырда». Фердинанд Сәлахов концерты. 12+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
10.30, 21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «КУРОРТНЫЙ РОМАН 2». 16+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Молодая наука». 12+
15.00 «Угрозы современного мира». 12+
15.30 «1812-1815. Заграничный поход». 12+
16.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗАКЛЮЧЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Древние небеса».
8.35, 16.30 «ЦЫГАН».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 «Юрий Никулин. Цирк для моих внуков».
12.25 Цвет времени. Надя Рушева.
12.35, 21.40 «МОЯ СУДЬБА».
14.00 «Отсутствие меня».
14.30 «Три «О» Ивана Гончарова».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.50 Мастера скрипичного искусства. Владимир Спиваков.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытие Международного конкурса пианистов, композиторов и дирижеров имени С.В. Рахманинова.
23.00 «Запечатленное время».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.05 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АКУЛА». 16+
23.25 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

16 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
6.30, 7.10, 8.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Яшик сөенеп кенә». Рифат Зарипов концерты. 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Хәйдәр Бигичев турында телеочерк. 6+
13.00 «ҮКСЕЗЛӘР». 12+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
10.30, 21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «КУРОРТНЫЙ РОМАН 2». 16+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Молодая наука». 12+
15.00 «Меганаука». 12+
15.30 «1812-1815. Заграничный поход». 12+
16.20 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+

10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗАКЛЮЧЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Древние небеса».
8.35, 16.30 «ЦЫГАН».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 XX век. «Муслим Магомаев. Встреча друзей по случаю 50-летнего юбилея».
12.30, 21.40 «МОЯ СУДЬБА».
13.50 «Исповедь фаталистки».
14.30 «Три «О» Ивана Гончарова».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Музыкальные инструменты народов севера».
15.45 «2 Верник 2».
17.50 Мастера скрипичного искусства. Виктор Третьяков.
19.45 Главная роль.
20.05 «Небесные ласточки». Моя милая Бабетта! Странно это, странно это!»
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Энигма. Юлия Лежнева».
23.00 «Запечатленное время».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.05 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АКУЛА». 16+
23.25 «Взлётный режим». 12+

Җомга

17 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
6.30, 7.10, 8.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 0.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Родная земля». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 6+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Олы юл әйтте...» циклыннан. Үткәннәрне барлап... Айдар Фәйзрахманов. 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Улым». Гүзәл Уразова һәм Илдар Хәкимов концерты. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Родная земля». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
10.30, 21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «РАЗВОД ПО-АМЕРИКАНСКИ». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «1812-1815. Заграничный поход». 12+
16.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.40 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
23.25 К 80-летию Пола Маккартни. «The Beatles в Индии». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Исповедь детей Жириновского». 16+
23.25 «КТО Я». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.15 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Древние небеса».
8.35, 16.30 «ЦЫГАН».
10.20 «ПУТЕВКА В ЖИЗНЬ».
12.10 «Забытое ремесло».
12.25 «ЩЕДРОЕ ЛЕТО».
13.50 Острова. Варлам Шаламов.
14.30 «Три «О» Ивана Гончарова».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Юлия Лежнева».
16.15 «Первые в мире».
17.55 «Билет в Большой».
18.40 «Дягилев и Стравинский. Поединок гениев».
19.45 Искатели. «Загадка «Дома под рюмкой».
20.35 «Жизнь и судьба».
21.25 «КОМИССАР».
23.35 «КРОВОПИЙЦЫ».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
20.00 «АКУЛА». 16+
23.05 «Своя правда». 16+

Шимбә

18 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 Спектакль «Шулай булды шул». 12+
16.00 «Сабантуй маҗаралары». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.10 «СЧАСТЛИВОГО ПУТИ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Минем йөрәк сиңа эндәшә. Мансур Мозаффаров». 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Спектакль «Кодача». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Серләреңне миннән яшермә». Ринат Мөслимовның иҗат кичәсе. 6+
23.10 Спектакль «Хуҗа Насретдин». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Научные сенсации». 12+
5.45 «Молодая наука». 12+
6.00 «Меганаука». 12+
6.30 «Один день в городе». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Эпидемия». 12+
8.30 «ЛЮТЫЙ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЗА ПРОПАСТЬЮ ВО РЖИ». 16+
15.00 «Планета собак». 12+
15.30 «КОМАНДА Б». 16+
17.15 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЖЕНА СМОТРИТЕЛЯ ЗООПАРКА». 16+
23.10 «КЛАН КЕННЕДИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15 «Чип внутри меня». 12+
11.30, 12.15 «Видели видео?»
13.30 «ДЕТИ ДОН КИХОТА».
15.15 «ВЕРНЫЕ ДРУЗЬЯ».
17.10 «Кто хочет стать миллионером?»
18.20 «На самом деле». 16+
19.25 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.00 Лига Бокса. Россия - Африка.

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.05 «КАТЕРИНА. СЕМЬЯ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «С НЕБЕС НА ЗЕМЛЮ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.10 «ОДНАЖДЫ В ДЕКАБРЕ».
9.25 «Обыкновенный концерт».
9.50 Исторические курорты России. «Марциальные воды».
10.20 «СТАКАН ВОДЫ».
12.30 «Узбекистан. Тепло и щедрость дастархана».
13.00 Черные дыры. Белые пятна.
13.40 «Затерянный мир острова Биоко и его короли».
14.40 «ЗА ВИТРИНОЙ УНИВЕРМАГА».
16.10 V Международный конкурс молодых оперных режиссеров «Нано-Опера».
18.20 «КОРАБЛЬ ДУРАКОВ».
20.45 «Петр Великий. История с французским акцентом».
21.30 «МЕДНЫЙ ВСАДНИК РОССИИ».
23.10 Кристиан Макбрайд на фестивале Мальта Джаз.

«НТВ»
5.05 «Хорошо там, где мы есть!»
5.50 «ОРУЖИЕ». 16+
7.20 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «По следу монстра». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.15 «Ты не поверишь!» 16+
21.15 «Секрет на миллион». 16+
23.10 «Международная пилорама». 16+
23.55 «Квартирник НТВ у Маргулиса». 16+

Якшәмбе

19 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Җырлы-моңлы Сабантуй». 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Тархан». 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 Республиканский конкурс «Врач года - Ак чәчәкләр-2022». 6+
15.00 Чулпан Әхмәтҗанова концерты. 6+
16.00, 0.45 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ДИКАЯ ЖИЗНЬ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.00 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Ватандашлар». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «КӨТЕГЕЗ, БЕЗ КИЛӘБЕЗ». 12+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Илдус Әхмәтҗанов турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.30 Спектакль «Әлепле әртистләре». 12+
15.40 «Ел табибы - Ак чәчәкләр-2022». 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 Спектакль «Әни килде». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Научные сенсации». 12+
5.45 «Молодая наука». 12+
6.00 «Не факт». 12+
6.30 «Один день в городе». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Планета собак». 12+
8.30 «КОМАНДА Б». 16+
10.15 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЖЕНА СМОТРИТЕЛЯ ЗООПАРКА». 16+
15.10 «Не женское дело». 12+
15.30 «ЛЮТЫЙ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЗА ПРОПАСТЬЮ ВО РЖИ». 16+
22.50 «РЕКА ПАМЯТИ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
6.10 «ТОТ, КТО ЧИТАЕТ МЫСЛИ» («МЕНТАЛИСТ»). 16+
7.45 «Играй, гармонь любимая!» 12+
8.25 «Часовой». 12+
8.55 «Здоровье». 16+
10.15 «Украина. Когда открываются глаза». 16+
11.00, 12.15, 15.15, 18.20 «ЗНАХАРЬ». 16+
19.25 «Призвание». Премия лучшим врачам России.
21.00 «Время».
22.35 «Биологическое оружие лаборатории дьявола». 16+
23.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.40 «ОТЕЦ ПОНЕВОЛЕ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.05 «КАТЕРИНА. СЕМЬЯ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Кот Леопольд».
7.45 «МЕДНЫЙ ВСАДНИК РОССИИ».
9.25 «Обыкновенный концерт».
9.55 «ПРЕДЛАГАЮ РУКУ И СЕРДЦЕ».
11.15 Острова. Николай Гринько.
12.00 Письма из провинции.
12.30 Диалоги о животных.
13.10 Невский ковчег. Теория невозможного. Александр Беггров.
13.40 «Коллекция».
14.10 «Ну, погоди!»
15.50 «Алла Осипенко. Исповедь фаталистки».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Первые в мире».
17.25 «Пешком...» Москва царская.
17.55 «Долгое эхо Роберта Рождественского».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «СТАКАН ВОДЫ».
22.20 Вечер балета. Памяти Игоря Стравинского и Сергея Дягилева.
23.55 «ЗА ВИТРИНОЙ УНИВЕРМАГА».

«НТВ»
5.00 «ПОСТОРОННИЙ». 16+
6.40 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.15 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер! 60+». 6+
23.00 «Звезды сошлись». 16+

Авыл афәтләре вәхшәте

Авыл җирләрендә эшсез калып эчеп йөрүчеләр шактый булса да, алар күбесе - зыянсыз сәрхушләр. Ләкин араларында хәвеф-хәтәр китереп чыгарырга сәләтле вәхшиләр дә очрап куя.

* * *

Чүпрәле районындагы Яңа Уби авылы кешесе Николай Смирнов шундыйлар рәтеннән. 1985 елгы ошбу ир-ат Чүпрәле генә түгел, Саба районы һәм Ульянов өлкәсендәге судлар тарафыннан күп тапкыр хөкем ителгән. Урлау, талау, кыйнау, үтерү белән янау кебек җинаятьләре өчен җиңелрәк җәза белән котылган чаклары да, колониягә озатылганы да булган. Күрәсең, рәшәткә артына эләккәч үзен тәртипле тоткан, шул сәбәпле ике мәртәбә вакытыннан алда азат ителгән, шулай да җиде ел гомерен япкынлыкта уздырган. Ышанычсыз кеше туган якларына кайткач та, административ күзәтүгә куелган, ләкин кәттә егет аның ирекне чикләүче таләпләрен, әйтик, полициягә барып күренеп йөрү, төнлә белән өйдә булу кебек шартларын үтәүне кирәк санамаган, бу һәм башка законсыз гамәлләре өчен соңгы бер елда гына 18 тапкыр административ җаваплылыкка тартылган, башлыча, унар тәүлеккә зинданга ябып тотылган, узган ел азагында ярты еллык шартлы хөкем дә алган әле.

Чүпрәле якларындагы чуаш авылларында аның кебекләр шактый. Смирнов – эчке эшләр бүлеге подвалындагы камерада шундыйларның берсе, Алешкин Саплык кешесе Анатолий Ясонов белән бергә утыра. Николайдан өлкәнрәк әлеге абзый да үз гомерендә төрмә юлын күп таптаган, иректә чагында 1989 елгы бердәнбер кызы Татьяна (исеме үзгәртелә) гаиләсе белән гомер иткән. Былтыр август аенда өзлексез эчеп йөрүче агай, якыннары белән тынышмыйча, каршы йорттагы 1955 елгы ялгыз күршесе һәм шешәдәше В.Портнов белән бер түбә астында тора башлаган.

Быел 31 гыйнварда Алешкин Саплыкка Николай Смирнов та килеп чыга. Ул анда «крестная мать» дип йөртелгән ханым белән көмешкә эчеп утырганда, иш янына куш дигәндәй, күрше Матак авылыннан Юрий Одиноков дигән тагын бер төрмәче пәйда була. Анысы төрмә сәндерәсендә бергә яткан дусты, ягъни «крестная»ның «сожителе» В.Ефимовны күрергә дип килгән була. Хуҗа шабашкада чак туры килә, димәк, хәмерле мәҗлес аннан башка дәвам итә. Искәртеп үтик, Одиноков белән килгән тагын бер ир-ат, Н.Смирновны күргәч тә, шул ук таксига утырып китеп бара, чөнки аның холык-фигылен яхшы белә һәм зур күңелсезлекләрдән котылып кала.

Ә тегеләр, кем әйтмешли, хәмернең мичкәсенә төшә, әйтүләренә караганда, шул авылдагы «самогонщик» янына дүрт тапкыр барып кайталар һәм төн уртасы якынлашканда Портнов белән Ясонов яшәгән йортка керәләр. Бу исә бер өстәл артында йомшаграк итеп әйткәндә, бик ышанычлылардан булмаган дүрт сәрхуш, иң хәтәре, котырынкы Смирнов та утыра дигән сүз.

Алешкин Саплыкта шаукым 1 февральдә төштән соң күтәрелә. Ясоновның кызы янына күз төпләре күгәргән В.Портнов килеп керә, узган төндә өендә булган мәхшәрне сөйләп биреп, аңсыз килеш идәндә яткан әтисенә ярдәм чакыртырга куша. Татьяна өйгә авыл табибәсе белән бергә керә, әтисенең җансыз икәнен күрү белән урамга чыгып полиция килгәнне көтә. Одиноков белән Смирнов «крестная» йортында тоткарлана. Аларның беренчесе шаһит итеп калдырыла, икенчесе исә, чынлыкта, бик озакка ябып куела. Тиздән суд карары белән кулга алына, чөнки үтерүченең ул икәне шик уятмый.

Тикшерү барышында ачыкланганча, Портнов йортына явыз нияттән керми алар, үзләре белән «төнлә туган» эчемлекләре дә була. Ызгыш сыйлаучы, ягъни стаканнарга салучы Одиноков Ясоновның савытын буш калдыра башлагач чыга. Ошбу гамәлен Ясоновның 4 мең тәңкәлек бурычын кире кайтармавы белән аңлата ул. Әлбәттә, мондый кимсетү Ясоновка да ошамый, үзара тарткалашу башлана, әйтүләренчә, яшьрәк, ләкин кечерәк гәүдәле Юрий агайга башы белән тондырмакчы булып талпына, ләкин буе җитмәү сәбәпле эләктерә алмый. Һәм Н.Смирнов дигән «текә» егеткә көч-куәтен күрсәтергә җай чыга. Кыскача гына әйткәндә, Ясоновны ярсып типкәләп, кыйнап кына калмый, идәндә чалкан яткан кешенең күкрәгенә дә менеп сикерә. Нәтиҗәдә, кабыргалар сына, эчке әгъзаларга зыян китерелә, баш җәрәхәтләре ясала.

Смирнов арага кереп маташкан Портновка да сугып авыз-борынын каната, үзе үк ишегалдына чыгып бер көрәк кар алып керә һәм Одиноков белән аңсыз яткан Ясонов битендәге канны сөрткәндәй итеп чыгып китәләр. Әле шуннан соң да үзләре кебекләр рәтендәге бер абзый өендә иртәнге сәгать 5 кә кадәр эчеп утыралар. Административ күзәтү шартлары буенча Н.Смирновның кичке сәгать 10 да өендә булырга тиешлеген искәртеп үтик.

В.Портнов дустының хәле мөшкел икәнен күрә, әлбәттә. Ләкин теге явыздан куркып тавыш чыгарырга базмый, күрәсең, могҗизага өметләнә. Әйтүенчә, иртә белән бусага төбендә яткан күршесе исән була, бары тик төш вакытында аның җансыз икәнен күргәч кенә, Татьянага хәбәр итә ул. Мәрхүмнең энесе һәм дүрт кыз туганы була, ләкин алар тайгак юлдан киткән Анатолий белән күптән аралашмыйлар, аны җирләргә берсе дә кайтмый.

Тикшерү комитетының Буа районара бүлеге җитәкчесе урынбасары Дамир Әскаров Н.Смирновка кеше сәламәтлегенә авыр зыян китереп саксызлык белән үтерү һәм административ күзәтү кагыйдәләрен бозу дигән ике гаепләү белдерә. Н.Смирнов киресен сукалап тормый. Апрель аенда җинаять эше район суды карамагына тапшырылды.

* * *

Лаеш районының Урта Девятово авылында яшәүче Владимир Русанов карап торырга явыз кешегә охшамаган үзе. Яшь чагында армиядә дә хезмәт иткән, аннан кайткач шактый вакыт җирле совхоз һәм урман хуҗалыгында эшләгән. Дөрес, шул елларда урлашкан һәм тыелган ысул белән балык тоткан өчен дүрт тапкыр хөкемгә тартылган, ләкин төрмәгә утыртылмаган, ирегеннән шартлы рәвештә мәхрүм ителгән яисә штраф түләп котылган.

Беркайчан да өйләнмәгән 45 яшьлек карт буйдак төп нигезләре янәшәсендә, чынлыкта, ата-анасы салып биргән барлык уңайлыклары булган йортта яши. Соңгы җиде-сигез елда эчүе аркасында очраклы эшләргә генә йөргән. Аның 69 яшьлек әнисе декабрь азагыннан февраль ае башына чаклы туктаусыз исереп йөрүен әйтә, әмма В.Русанов ошбу галәмәтен кыш көне эш булмау белән аңлата, үзен ташланып эчүче сәрхуш дип санамый.

Чыннан да, 7 февральдә аек була ул. Кич белән янәшә йорттагы ата-анасы янына кереп тамак туйдырып чыгып китә. Әлбәттә, аны даими рәвештә исерек килеш күреп һәм эчмәскә кушып әрләп-тирләп торган картлар өчен куанычлы хәл була бу. Ә икенче көнне алар өендә бөтенләй башка Николай пәйда була һәм коточкыч ерткычлык эшләп куя.

Мәгълүм булганча, 7 февральдә ата-ана йортыннан чыгып шактый вакыт узгач, аның янына Н.Горбунов дигән дусты килеп керә. Буш кул белән түгел, тулаем исәпләгәндә, 9 литр сыра һәм литр ярым самогон күтәреп килә. Шул рәвешле, сәрхушләр төн буе сыйланып утыралар, иртәнге сәгать 5 тә генә йокларга яталар, төш җиткәндә уянгач, кунак чыгып китә, ә хуҗа калган хәмерне эчеп баш төзәтеп утыра, исерүе җиткәч, картлар янына барып керә.

Сәрхуш башында нинди уйлар кайнавы билгесез. Әнисе Галинаның әйтүенә караганда, аңа: «Давай, разберемся», – дип ни хакындадыр сөйләшергә теләвен белдерә ул. Ләкин әни кеше исерек белән әңгәмә корасы килмәвен әйтеп, түр бүлмәгә кереп китә, ә кухня ягында әтисе Вячеслав кала. Күп тә үтми хатын-кыз иренең кычкырганын ишетеп йөгереп чыга һәм аны янындагы диванга таянып идәнгә тезләнгән хәлдә күрә, ә Владимир юкка чыккан була.

1952 елгы В.Русанов шул тирәдә генә яшәүче фельдшер Г.Кузьмина килеп җиткәндә үк үлгән була инде. Ул мәрхүм күкрәгенең сул ягында пычак җәрәхәте булуын әйтә. Соңрак үткәрелгән экспертиза пычакның йөрәкне, сул бавыр һәм башка әгъзаларны җәрәхәтләвен белдерә.

Хуҗабикә моның Владимир эше икәнен белә, әлбәттә. Кухня өстәлендәге пычакның юкка чыгуын да күрә, полиция хезмәткәрләре килеп җиткәнче, уртанчы улы өенә керергә курка. В.Русанов погонлы кешеләргә әтисенә бер тапкыр пычак чәнчүен шунда ук әйтә һәм алардан атасының үлүен ишетә, җинаять коралын бәдрәфендәге унитаз артына яшерүен дә күрсәтә.

В.Русанов гаебен таный, әлбәттә. Әйтүенчә, әтисе инде ике ай буе эчүен, сәрхушлеккә чыгуын белдереп орыша башлагач, пычакка ябыша ул. Тикшерү комитетының Биектау районара бүлегеннән юстиция подполковнигы Марсель Фатыйхов аңа аңлы рәвештә кеше үтерү дигән рәсми гаепләү белдерә. 1976 елгы В.Русанов хәзергә тикшерү изоляторында хөкем көтә.

* * *

Азнакай якларындагы Тымытык авылында яшәүче Рафис Харисов та эчә торгач явыз кешегә әйләнгән. 1960 елгы ошбу абзый да артыгын эчәсең дип телләнә башлаган 25 яшьлек туганын пычак белән җәрәхәтли һәм үзе дә картаймыш көнендә олы бәлале була. Югыйсә, рәсми кәгазьләрдә яшәү урынында уңай бәяләнүче кеше дип күрсәтелә, бары тик эчкече буларак исәптә торуы гына әйтелә. Аның кебекләр турында, гадәттә, эчү дигән бер генә кимчелеге бар диләр. Ләкин көтелмәгән явызлыкларга этәрә торган яман кимчелек шул ул.

Рафис абзый узган елның 8 декабрендә дә салмыш була. Кичкә таба күршедә яши торган сеңлесенең 25 яшьлек улы Дәвит Харисов килеп кергәч, тагын эчәргә җай чыга, чөнки егет литр ярым сыра тотып керә. Низаг тәнәфес вакытында, ягъни ирләр верандада тәмәке көйрәткән чакта чыга. Яшь кешенең соңгы вакытта күп эчәсең дип акыл өйрәтергә керешүе ошамый агайга, шул рәвешле, сүз артыннан сүз чыга, сүгенү, кимсетүләр дә ишетелә башлый. Ахыр чиктә, лаякыл исерек абзый өенә кереп пычак алып чыга да Дәвитнең күкрәгенә кадап ала.

Туган-тумача ашыгыч ярдәм чакыра, ярадан аккан канны чүпрәк каплап туктатып азаплана. Соңрак кайбер табиблар пычак бер см тирәнрәк яисә түбәнрәк кадалса егетне коткарып та булмас иде диләр. Шөкер, Д.Харисов тиз тернәкләнә, 11 көннән сырхауханәдән чыгарыла, тагын 3 көннән яраны теккән җепләр алына. Шулай да эксперт аның сәламәтлегенә авыр зыян китерелгән дип белдерә. Тикшерү комитетының Азнакай районара бүлегеннән өлкән тикшерүче Э.Р.Мусина Рафис Харисов гамәлләренә кеше үтерергә омтылыш ясау дигән бәя бирә, ягъни ул үтерергә дигән ниятен ахырына кадәр җиткерә алмаган булып чыга.

Зарар күрүче Д.Харисов моңа кадәр дустанә мөнәсәбәттә булган туганында үтерү нияте булуы белән килешми, үтерәм дисә тагын кадаган булыр иде, мине куркытырга гына уйлагандыр дип саный. Әлбәттә, гаепләнүче Р.Харисов та шундый ук фикерне алга сөрә, ягъни авыр тән җәрәхәтләре ясаган өчен җиңелрәк җәза алырга тели. Ләкин гаепләү ягы кешенең йөрәк тирәсенә чәнчегән 1960 елгы Р.Харисов кырыс җәзага лаек дип саный.

Наил ВАХИТОВ.

Комета күренгәнче өлгерик



Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында Санкт-Петербургта яшәп иҗат итүче яшь драматург Полина Коротыч пьесасы буенча режиссер Тимур Шәрәфетдинов куйган «Тимур һәм комета» спектаклендәге хәлләр саташулы төшне хәтерләтә. Тимур исемле малай, яшәгән өеннән китеп, ташландык ИКЕЯдә үз куышын кора һәм үз җырын җырлау мөмкинлеген эзли. Юлында очраган ата мәче, песнәк һәм Ләйсән исемле кыз аңа үз көен табарга ярдәм итә.

Шуннан соң малай, күңеленә тынычлык табып, кабат өенә әнисе янына кайтып ирешә. Песнәк белән ата мәче кыланмышларыннан бөтенләй башың китәрлек. Песнәкнең холкы чебен тимәс черт итәр. Мәче, киресенчә, артык пошмас. Песнәк – үз биюен бию турында хыялланса, ата мәче хатыны һәм ун баласы өчен җылы куыш табарга тели. Сәхнәдәге арткы пәрдә зурлыгында таш диварга караганда һәм үз көем, үз җырым, үз өем турындагы сүзләрдән чыгып кына тамашаның ялгызлык, адәм баласының дөньяда үз урынын таба алмавы турында дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин.

Чыннан да, пьеса авторы социаль челтәрләрдә актив аралашса да, кеше ялгыз, интернет дөнья ул – бары тик иллюзия, бәхет өчен кешегә кеше кирәк һәм миллионлаган тавышлар арасында үз җырыңны табу гаять авыр дигән фикерләрне ирештерергә теләгән. Әмма шундый җитди темалар күтәреп тә, театр яшүсмерләр белән ник нәни балалар телендә сөйләшә соң? Песнәк һәм ата мәчене сурәтләүдәге театральлек, киемнәрендәге җете төсләр игътибарны үзенә ала һәм мөһим темалар читтә кала лабаса. Чынлыкта, ата мәче геройның матди ихтыяҗларын, песнәк исә рухи омтылышларын гәүдәләндерә түгелме? Адәм баласының рухи һәм матди арасында бәргәләнүе, гомумән, балалар, яшүсмерләр театры темасымы? Җитмәсә, әсәрнең теле болай да буталчык куелган тамашаны тагын да катлауландыра. П.Коротычның яртылаш шигъри жанрда иҗат ителгән әсәренең әнә шул үзенчәлеген сакларга теләүләре нәтиҗәсендә спектакльне иҗат итүчеләр уңышсызлыкка дучар булган. Әллә әсәрнең теле авыр килеп чыккан, әллә актерларның шигъри телдәге репликаларын җиренә җиткереп әйтергә осталыгы җитенкерәмәде, әллә телдән бизә барган замана балаларының аңлау дәрәҗәләре бик түбән булганга, байтак сүз-җөмләләрне аңламаулары яшь тамашачыларның йөзенә чыккан иде.

Спектакльдәге вакыйгаларны Җиргә якынлашкан комета тизләтеп җибәрә. Куркыныч алдында калгач Тимур үзен таба. Әҗәл каршында битлек киеп ясалмаланунын хаҗәте юк шул. Үлем алдында барысы да үз асылына кайта. Социаль челтәрләрдәге ясалма дөнья да юкка чыга. Яшүсмер Тимур да иң газиз кешесе әнисе янына әйләнеп кайта.

Бериш театрларга да, Җиргә комета яки бүтән төрле бәла-каза якынлашканны көтмәстән, иллюзия дөньясыннан чыгып, чын балалар темаларына әйләнеп кайту кирәк. Кариев театрында, мәсәлән, бер иҗат фасылында куелган өч спектакль – «Камыр батыр», «Алтынчәч» һәм «Тимур һәм комета» нык борчуга сала. Һәр өчесендә сәхнәләштерүчеләрнең заманчалыкка, дөньядан артта калмаска омтылулары, иҗади эзләнүләре әйбәт булса да, шулар арасында бала онытылып калуы бик яман.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 10.06.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2730 данә

Заказ 2756

16+